Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы
Башкарма комитетының мәгариф идарәсе
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының
Зеленодол муниципаль районы җирле оешмасы
«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының
3 нче номерлы гимназия»
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

Татары прославившие народ

Куренекле татарлар

# исемендәге II төбәкара фәнни-гамәли конференциясе материаллары

**Яшел Үзән, 2017**

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Мәгариф идарәсе Башкарма комитетының редакцияләү, нәшер итү советы карары нигезендә басыла.

**Редакторлар**:

**Сәлахова Р.Ә.,** Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе укыту-методик булегенең милли мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методисты; югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;

**Ильина М.А.,** «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы 3 нче номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе директоры, югары категорияле тарих укытучысы;

**Минһаҗева М.К.,** «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы 3 нче номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли мәгариф буенча директор урынбасары, I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Әхмәдова Э.Ә.,** «Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы 3 нче номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Җыентык «Күренекле татарлар» исемендәге II төбәкара фәнни-гамәли конференциясе материалларын эченә ала.

Җыентык укучылар һәм укытучылар өчен.

**ЭЧТӘЛЕК**

*Мөсәгыйтов Рәмис Рафис улы.* АВЫЛЫБЫЗ ГОРУРЛЫГЫ.......................................................3
*Хәмидуллин Илһам Азат улы* Чын укытучы булу – ул талант. (Байсаровлар династиясе)............7
*Сундурова Александра Владимировна.* Легенда о Птице по имени Свобода……………………..10
*Манвелян Кишмиш.* Свияжские узники. Великий татарский поэт Хасан Туфан………………...15
*Исхакова Асия Фанисовна.* «Лучший фотограф среди прокуроров и лучший прокурор среди фотографов»……………………………………………………………………………23
*Мөхәммәтшин Айназ.* "Без тарихта эзлебез" *(Тарихчы – галим Җүдәт Миңнуллин).....................28*
*Валиуллина Алия Фанисовна.* Командир из нашей деревни. ………………………………......33
*Галимуллина Эльвина Тәбрис кызы.* «Үз халкын данга күмгән татарлар»……………………..…39
*Мустафина Алина Равилевна.* «Какая безмерная тяжесть на женские плечи легла...»…………..…47
*Шәрәфетдинова Эльмира Рифат кызы.* Мәгърифәтле туган ягым……………………………..…49
*Гилязова Ризаля.* «Я живу, чтобы делать добро»……………………………………………….....54
*Гилязова Ризаля.* «Тапшырылмаган хатлар»……………………………………………………..58
*Храмова Анастасия Андреевна.* Известные татары моего края: поэт - Лилия Газизова…………59
*Туранова Дарина Алексеевна.* Врач от бога. ……………………………………………………...64
*Фәйзуллин Илдар Рәшит улы.* Якташ шагыйребез – Мансур Крыймов.........................................66
*Низамиева Айсылу Рамисовна.* «Я снова здесь, в краю родном»……….......................................72
Баймяшкина Анна Алексеевна. « Близко к сердцу» (о Ренате Сулеймановиче Акчурине )……..73
*Камалеева К.Р.* " Ренат Харис- тынычлык җырчысы"....................................................................77
*Мухамедзянова Яна Эдуардовна.* Роль Зинатуллина Габдульхамита хазрата в воспитании подрастающего поколения нашего города……………………………………..….80
*Гайфуллина Айсылу Илсур.* Якташыбыз композитор Риф Гатауллин иҗаты................................80
*Вертячих Роман Максимович.* Село Агзегитово в истории становления образовательной и воспитательной системы татарского народа……………………………………...………...83
*Сибгатова Ландыш Роберт.* Туган ягымның күренекле татарлары……………………………...86
*Васильева Гөлинә Ильвир.* Тукай эзләре уйлап……………………………………….............91
*Сираҗиева Әдилә Илшат кызы, Гимадиева Ләйлә Айрат кызы.* Фәүзия Бәйрәмова – татар милләтенең легендар шәхесе.............................................................................................95
*Хайруллина Инзиля Рамисовна.* «Оборванная пулей песня…»(Жизнь и творчество выдающегося татарского композитора Фарида Яруллина)…………………….. ………………100
*Харизова Рузиля Рамилевна.* Виль Ганиев-мастер литературного перевода............................105
*Титова Екатерина Анатольевна.* «Асгат Галимзянович Галимзянов – великий благотворитель»……………………………………………………………………. …111
*Зәйнуллина Камилә Шәһит.* Туган ягым әдибе Туфан Миңнуллин - гаҗәп талант иясе..........................................................................................................................112

# АВЫЛЫБЫЗ ГОРУРЛЫГЫ

(Советлар Союзы Герое Хәбибулла Ибраһимовның тууына 105 ел)

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр урта гомуми белем бирү мәктәбенең VIII сыйныф укучысы Мөсәгыйтов Рәмис Рафис улы*

*Фәнни җитәкчесе: I квалификацион категорияле тарих укытучысы Мөсәгыйтова Гөлниса Рамил кызы*

## I. Кереш

Үзең турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

Ф.Кәрим

Хәтер...

Бары тик кешеләргә генә хас изге хис. Ул безнең аңда мәңге яши. Яшәп кенә калмый, ә яңадан – яңа буын кешеләрен батырлыкларга өнди, хәзерге гамәлләрне элекке каһарманлыкларга тиңләргә чакыра.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм канкойгыч 1418 көне һәм төне кешелек хәтереннән мәңге чыкмас. Бу көрәштә илебезнең миллионлаган намуслы һәм батыр ул – кызлары җирдә тынычлык һәм бәхет өчен гомерләрен бирделәр, шуның аркылы алар үлемсезлеккә атлады. Аларның батырлыклары бүген дә яши һәм мәңге яшәячәк.

Авылыбыз горурлыгы булган Советлар Союзы Герое ИбраһимовХәбибулла Ибраһим улына 2017 елның 18 нче январендә 105 яшь тулуга багышланган кичә үткәрүгә хәзерлек эзләнү – эшемнең башлангычы булды. Әлеге эзләнү эшемнең максаты - Советлар Союзы Герое Хәбибулла Ибраһимов тормышы турында тулырак мәгълүмат туплау. Максатыма ирешү өчен үз алдыма түбәндәге бурычларны куйдым.

- Якташыбыз Хәбибулла Ибраһимовның тормыш юлын өйрәнү.
- Авылыбызда яшәгән туганнары, авылдашлары, сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашу.
- Бу тема буенча әдәбиятны өйрәнү.
- Аның турында мәктәп сайтына мәгълүматлар бирү.
- Җыелган материалларны системага салу.

Эзләнү эшемнең актуальлеге: һәр кеше туган ягының тарихын, батырларын белергә, өйрәнергә, сакларга тиеш.

## II.Төп өлеш

### 1.Туган йорт – тәүге адымнар

Моннан нәкъ бер гасыр элек, 1912 нче елның 18 январендә Куныр авылының гади крестьяны Ибраһим һәм Һадия гаиләсендә ир бала дөньяга аваз сала. Балага Хәбибулла дип исем бирәләр. Тырыш, үз көнен үзе күрүче гаиләдә 6 малай – Әхмәтсафа, Сәфиулла, Гафиулла, Хәбибулла, Галимулла, Камал һәм иркәлеге өчен “Ак песи” кушаматы алган бердәнбер кыз үсә. Болар янына Ибраһим абыйсының ятим калган өч малае да уенга килеп кушылганын исәпкә алсак, бу бер көтү малай – шалайныңниләр майтарырга сәләтле икәнен күз алдына китереп була.

Һәр авылның баласына хас гөнаһсыз шуклыклар, балык тотулар, уеннар белән балачак үтеп бара. Тиктормас малайларның үскән бере әти – әнисенең кул арасына керә торалар. Гаилә башлыгы Ибраһим абзый үзе дә гаярьлеге, үткенлеге, булдыклылыгы белән дан алган Ногманның 11 улының берсе була.

Ногманныкылар авылда бердәм, абруйлы нәсел санала. Алар кирәк урында өздереп үз сүзләрен дә әйтә беләләр, бер – берсен башкаларга кыерсытырга да юл куймыйлар. Ибраһим абзый да авылда турылыгы, җорлыгы белән дан алган кеше була. Шуның өстенә киң күңеллелеге һәм юмартлыгын да исәпкә алсак, аны авылның Әлмәндәре булган дигән фикергә килергә була. Менә шундый гаиләдә үскән Хәбибулла 1928 нче елда мәктәпнең 5 классын тәмамлый, җәй көне колхозда, кышын агач хәзерләүдә эшли.

**2. Зур тормышка аяк басу**

Яшь колхозчысы Хәбибулла Ибраһимовны 1934 нче елны армиягә алалар. Ул башта гади кызылармеец булып хезмәт итә, аннары полк мәктәбендә укып, отделение командиры һәм взвод командиры ярдәмчесе була, ә 1938 нче елны, курслар тәмамлагач, кече лейтенант званиесе ала. 1939 нчы елның октябрендә Ибраһимовны 86 нчы мотоукчы дивизиянең өйрәтү батареясы командиры итеп билгелиләр, һәм ул шул батарея белән фин компаниясендә катнаша. Яхшы коралланган һәм хәзерлекле дошманга каршы көрәштә, үтә салкын һәм тирән карлы кыш булуга карамастан, батареячылар беренче көннәрдән үк үзләренең хәрби белемнәрен һәм осталыкларын күрсәтәләр. Алар пехотага һөҗүм вакытында да, оборонада да орудиеләренең төз атылган залплары белән зур булышлык күрсәтәләр, дошманның орудиеләрен һәм ныгытмаларын юк итәләр.

Сугышның соңгы ун көне - дивизиянең Выборг янындагы Фин култыгы бозы аша героик поход ясап, дошманның тылына чыгу көннәре Ибраһимовның хәтерендә бигрәк тә нык саклана. 3 мартта батареяны майор Зашиболовның укчы полкына ярдәмгә бирәләр. Инде сугышка керешкән бу часть позицияләренә тизрәк барып җитәргә ашыккан артиллеристлар әле бил тиңентен карга бата – бата, әле боз өстеннән шуышып баралар. Гәрчә орудиеләр чаналарга куелган булсалар да, аларны тарткан тракторларга өзлексез булышырга туры килә. Артиллеристлар көчләрен кызганмыйлар, чөнки алар тоткарлыкларның һәр минуты урманлы тау каршында финнарның көчле уты астында калган безнең пехотаның зур югалтуларга дучар итәчәген аңлыйлар иде.

Кече лейтенант тракторчыларны:

-Тизрәк, тизрәк! -дип ашыктыра торды.

Финнар артилериясе аткан снарядлар ярыла торган җиргә җиткән, Ибраһимов батареяны позициягә урнаштырды һәм дошманга җавап уты ача. Ул ике орудиедән финнарның артилериясенә, калган икесенә – урман аланындагы өйгә төбәп атарга приказ бирә. Бу өйдә фин пулемётчылары урнашкан була. Сугыш караңгы төшкәч тә тукталмый. Финнар атканда күренгән очкынга ориентир ясап, батарея атуын дәвам итте һәм аларның ут ноктaларын юк итә. Шуннан соң пехота алга китә. Икенче көнне иртә белән батарея сугышчылары, майор Зашибалов приказы буенча боздан чыгып, урманлы калкулыкта позициягә урнашалар. Алар анда ике тәүлек буена, залпка залп белән җавап биреп, дошман белән атышалар.

Яңа һөҗүм 7 нче мартта башлана.Полк алдына Выборгтан 18 километр көнбатыштарак урнашкан Вилла – Йоки дигән авылны алу һәм финнар группировкасың тылына чыгу бурычы куела. Ибраһимов бер взводны резервта калдырып, ике орудие белән авылга һөҗүм итүче батальонга булышлык күрсәтә. Совет сугышчыларына кар каплаган тирән үзәнлек аша үтәргә кирәк була, аның икенче башында авыл урнашкан , ә авыл артындагы урманлы таудагы валуннары арасыннан финнар өзлексез атып торалар . Фронт яклап һөҗүм итүчеләргә бигрәк кыен була. Алар карга ятарга мәҗбүр булалар. Агач башындагы дошман снайперлары – “күкеләр”, бу моменттан файдаланып, карда яткан совет сугышчыларын берәм-берәм сафтан чыгара башлыйлар. Йортларның чарлакларыннан һәм биеклектән пулемётлар оча башлый. Пехота атакага күтәрелгән саен, дошманның уты тагы да көчәя.

Килеп туган хәлгә тиз генә бәя биреп Ибраһимов бер орудиене алга чыгарырга карар бирә. Бу - укчыларны дәртләндереп җибәрә. Бер төркем сугышчылар, орудие тагылган тракторга ышыкланып, алга үтәләр. Фин пулемётлары уты пехотаны карга сыендыргач, артиллеристлар орудиене позициягә урнаштырып ата башлыйлар һәм берничә снаряд белән ут ноктасы юк итәләр.

Шул рәвешчә, совет сугышчылары, һәр адымны зур авырлык белән үтеп, авыл читенә якынлашалар. Сугыш икенче көнне дә дәвам итә. Һәр йорт штурм белән алынды. Артиллеристларның ярдәме һәркайда сизелде. Алар дошманга терәп аттылар. Туктаусыз атудан орудиеләрнең көпшәләре кызды, аңа төшкән кар шундук парга әйләнә иде.

Батарея командиры, сугыш барышын өзлексез күзәтеп, пехота үзенә юл сала алмаган урыннарга артиллерия утын юнәлдерә торды. Аңа орудие расчётларына җитәкчелек итү һәм цельләрне күрсәтү белән генә чикләнеп калмыйча, үзенә дә атарга туры килде. Төз атылган снарядлар белән ул каршылык күрсәтүнең соңгы нокталарының берсе булган таш сарайны җимерде һәм чаңгычылар отрядының алга баруына комачаулаган дошман пулемётын сафтан чыгарды.

Култык бозы аша поход һәм совет гаскәрләренең ныгытылган Выборг районының тылына чыгуы, шәһәр-крепость Выборгның алынуы Финляндия белән сугышта соңгы зур операцияләрнең берсе булды. 12 мартта Финляндия белән вакытлы солых төзелде.

Вилла-Йоки авылы өчен сугышта катнашучылар солых төзелгән көнне хөкүмәт бүләкләре алдылар. Сугышчылар һәм командирларның бер төркеменә, шулар арасында кече лейтенант Ибраһимовка күрсәткән батырлыклары өчен 1940 нчы елның 21 нче мартында Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

### 3. Дәһшәтле еллар

1941 нче ел. Хәбибулланың тынгысыз, җаваплы хәрби тормышы дәвам итә. Шул чорда аның Ленинградта хезмәт итүче энесе Галимулланың армия срогы тулырга якынлаша. Ике туган Ленинградта очрашалар, бергә фотога төшәләр. Ләкин ил өстенә ябырылган афәт – канлы сугыш бөтен планнарны җимереп ташлый. Ил 4 ел буена сузылачак сугыш чоңгылына кереп китә.

Дәһшәтле сугыш бер генә гаиләне дә читләтеп узмый. Фронт сызыгы сугыш позицияләре генә түгел, миллионлаган совет кешеләре йөрәге аша да уза. Безнең Куныр авылыннан гына да 304 кеше изге яуга, дошманга каршы көрәшкә күтәрелә.

Ибраһим карт белән Һәдия әби дә фронтка 6 улларын озаталар. Гомерен хәрби хезмәткә багышларга уйлаган Хәбибулла һәм армия хезмәте срогын тутырып өйгә кайтырга җыенгач, кабат сугышка кереп киткән Галимулла янына калган йөрәк җимешләре Әхмәтсафа, Сафиулла, Гафиулла һәм Камаллар да өстәлә.

Тыл авырлыкларын күтәрү белән бергә көн туган саен фронттан хат көтүче өмет белән билгесезлек арасында бәргәләнүче эти – әни йөрәген кем генә аңламас икән.

Хәбибулла Ибраһимов та сугышның эчендә кайный, үз өлешенә тигән авырлыкларны кичерә. Ул бронепоездлар отрядына командалык итә, үзйөрешле артиллерия полкы командиры урынбасары була. Күп кенә бәрелешләрдә бу отряд хәлиткеч роль уйный. Ибраһимов сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Ленин, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, күп санлы медальләр белән бүләкләнә.

Озакка сузылган, бөтен ил халкын йончыткан сугыш тәмамлана, җиңү таңы ата. Шул җиңү өчен бик күпләр, шул исәптән Куныр авылының 162 ир
егете башын сала. Европа буйлап сибелгән солдат каберләрендә безнең авылдашлар да ята. Аларның якты истәлеген бары тик һәйкәлләр генә саклый.

Әкренләп илгә солдатлар кайта башлый. Ибраһим карт белән Һәдия әби дә 5 улларының җиңү белән өйгә кайтуын күрү бәхетенә ирешәләр. Камал исемле кече уллары гына эти – әнисе өчен гомер төзәлмәс җәрәхәт булып сугыш кырында ятып кала. Аның истәлегенә Сафиулла абыйсы сугыштан соң туган улына Камал дип исем бирә.

Сугыштан соң Хәбибулла Ибраһимов чит илләрдә хезмәт итә. Кайда гына булса да, аңа намуслылык, тырышлык, тыйнаклык сыйфатлары юлдаш була.

### 4. Гадилек – батырлык юлдашы

1958 нче елда, отставкага чыккан соң, Хәбибулла абый хатыны Хатирә апа белән Казанга кайтып урнаша. Туган авылында өй салып, җәйләрен авылда, күп санлы туганнары, күршеләре, авылдашлары белән аралашып яши. Авылда беренче булып матур бакча үстерә. Тоташ яшеллеккә, чәчәкләргә күмелгән ишек алды, үзенең игелекле, киң күңелле хуҗасы кебек авыл яме булып тора.
Хәбибулла абый үзенең гадилеге, намуслы, ярдәмчел кеше булуы белән һәркем күңеленә юл алган, бервакытта да үзенең Герой исеме белән мактанмаган, ул ,исемгә ышыкланып, өстенлекләр даулап йөрмәгән. Мәктәп укучылары белән очрашуларга йөри, бөтен республика “аҗаган” уеннарын оештыруда актив катнаша.

Казанда Хатирә апа белән бер бүлмәле квартирда яшәгәндә, аларга 3 бүлмәлене тәкъдим иткәч: “Безнең икебезгә бер бүлмәбез, җәен яшәргә авылда өебез бар - шул җитә, мохтаҗрак кешегә бирегез”,- дип аннан баш тарткан.
Үзе белән тормыш юлларын, дәһшәтле елларны бергә узган Хатирә апа белән матур итеп яшәгәннәр, Хатирә апаның апасы кызын да үз балаларыдай якын күреп тәрбияләп үстергәннәр.

1975 нче елның октябре зур югалту алып килде – данлыклы авылдашыбызның йөрәге тибүдән туктады. Иртә, бик тиз иртә китте ул безнең арадан. Бары 63 яшь иде аңа. Хәер, 93 яшькә җиткән булса

да иртә булып тоелыр иде. Яхшы кешеләрне ничәдә булса да, “их, иртәрәк китте” дип уфтанабыз бит. Советлар Союзы Герое Хәбибулла Ибраһимовның исеме
дә онытылмый. Шундый батыр якташыбыз, авылдашыбыз булу авылга дан – дәрәҗә, ә безнең күңелләребезгә горурлык хисе өсти.

**III. Йомгаклау**

Халыкның тирән фәлсәфи сүзе бар: “Һәр вакыйгадан яшәү өчен
гыйбрәт ал”, – дигән ул. Якташыбыз Хәбибулла Ибраһимов күрсәткән батырлыкларын, үрнәк тормыш юлын гыйбрәт дими, ни диясең?

- Әйе, чыннан да, әлеге эзләнү эшемнең нәтиҗәсе булып һәркемнең йөрәгенә үтеп керердәй оештырылган кичә генә дә зур мисал булып тора.
- Хәбибулла Ибраһимовның тормыш юлы буенча зур альбом төзелде, презентацияләр эшләнде, мәктәбебездә эшләп килүче музеебызга бәяләп бетергесез зур байлык тупланды.
- Бик күп шул чордагы фотокарточкалар табылды, яңартылды.
- Батыр якташыбызның туганнары, күршеләре,авылдашлары белән очрашулар уздырылды.

Әйе мин максат – бурычларыма ирештем дип уйлыйм. Әлеге эшем мине яңадан – яңа эзләнүләргә этәрде генә. Тырышлыгым бушка китмәде: мин Хәбибулла Ибраһимовның нәсел шәҗәрәсен һәм балалар белән очрашудагы аудиоязмасын таптым, үземнең Советлар Союзы Герое Хәбибулла Ибраһимов белән нәсел җепләребез тоташканлыгын белдем. Бу эшемне алга таба тагын да баетырга, киңәйтергә телим. Билгеле, әлеге хезмәтне укучы үзе генә башкара алмый. Тарих укытучыбыз Мөсәгыйтова Гөлниса Рамил кызы кебек эзләнүчән, максатчан мөгаллимебез булганга авырлыклар җиңел чишелде.

Тормыш ыгы – зыгысыннан туктап,
Мәшәкатьләреңне ташла да,
Әй, туганым, үткәнеңә кара,
Анда синең нәселең башлана.

Ерак бабалардан аваз киләː
“Тамырыңны өйрән и бала!
Оныта күрмә, нинди җепләр белән
Кеше заты җирдә саклана”.

Тугры калыйк изге васыятькә,
Тамырларны барлыйк һәм белик,
Киләчәккә күперләр салучы
Нәсел агачларын тергезик.

Әйе, тамырларыбызны белсәк, кадерләсәк кенә ныгырбыз без киләчәктә. Ә киләчәк ул бүген башлана.

Бүген без шушы изге җиңү өчен гомерләрен биргәннәргә, үзләренең
каны белән, сәламәтлеге белән, аяусыз хезмәте белән Җиңү көнен якынайтучыларга, шәһит булганнарга һәм исәннәргә – һәрбере алдында баш иеп рәхмәт хисләребезне ирештерәбез. Рәхмәт сезгә, изге җаннар, рәхмәт сезгә җиңүчеләр.

**IV. Кулланылган әдәбият**


1. Балтач энциклопедиясе/ Г.С.Мөхәммәтшин – Казан: ПИК Идел – Прес, 2006. – 416 б.
2. Герои Советского Союза – наши земляки (Сборник документальных очерков и зарисовок в трех книгах). Книга вторая. – Казань: Татарское кн. из – во, 1985. – 248 с. с ил.
3. Книга Героев. – Казань: Татар. кн. изд – во, 2000. –395 с.
4. Они вернулись с Победой, Балтасинский район Республики Татарстан. – Казань: Книга Памяти, 2007. – 368 с.
5. Хәтер. – Казан: Хәтер китабы нәшрияты, 1994. – 548 б.


## Чын укытучы булу – ул талант.
## (Байсаровлар династиясе)

*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы*
*«Афзал Шамов исемендәге Татар Танае гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Башкарды: 8 сыйныф укучысы Хәмидуллин Илһам Азат улы*
*Җитәкче: георгафия укытучысы Мөхетдинова Алсу Билал кызы*

**Чын укытучы булу – ул талант**.

**Байсаровлар династиясе**.

Мамадыш авылында 1896 елда Байсаров Хикматулла семьясында ир бала туа. Аңа **Сөнгатулла** дип исем кушалар. Үсеп егет булгач, 1924 елда Акъегет авылы кызы Өммегөлсем белән тормыш корып җибәрәләр. Икесе дә Зөя өязендә укытучылыкка укып кайталар, һәм Бакырчы авылында укыта башлыйлар. Бу мәктәптә 1933-37 елларда балаларга белем биреп, янәдән Мамадышка кайтып, укытучылык хезмәтен дәвам итәләр. Ул вакытларда Мамадыш мәктәбе укытучыларга кытлык кичерә торган була.Бу мәктәптә алар бик аз, 1937-1939 елларда эшләп калалар, чөнки 1940 елда Сөнгатулла вафат була. 4 бала ( 2 ул һәм 2 кыз ) белән **Өммегөлсем Кәлимулла кызы** тол кала. Иң кечкенә кызлары бары яшь ярымлык кына була әле. Бу укытучылар гаиләсе авылда абруйлы, хөрмәткә лаек була, шуңа күрә дә Сөнгатулланы җирләгәндә мылтык атып салют бирәләр.

Бөек акыл ияләре дә, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән каһарманнар да, ачышлары белән дөньяга танылган галимнәр, исемнәре халыклар тарихына алтын хәрефләр белән язылган әдәбият, мәдәният, сәнгать әһелләре дә, ирешкән уңышлары турында сүз чыккач иң беренче нәүбәттә үзләрен хәреф танырга өйрәткән, зур тормыш юлына чыгарган укытучыларын, остазларын олы хөрмәт һәм ихтирам хисләре белән искә алалар. Байсаров Сөнгатулла белән Өммегөлсем дә шундыйлардан була.



Өммегөлсем оста тегүче булуы белән дан тота:авыл халкына өс киемнәре, күлмәкләр тегә. Шулай итеп гаиләне авыр сугыш елларында ачлыктан, ялангачлыктан саклап кала.

Өммегөлсем Байсарованың **Галия** исемле сеңлесе һәм **Хәлимә** апасы да укытучылар булалар.

**Кәлимулла кызы Галия Мадыйгулова** 1902 елда Акъегет авылында дөньяга килә.Тимершин Илгизәрнең “Акъегет авылы тарихы сәхифәләре” китабыннан күренгәнчә, Галия Кәлимулла кызы 1930-1940 елларда мәктәптә башлангыч сыйныфларда укытучы булып эшләгән. “Авыл халкы алдында укытучы Әлмиев Хәйрулла һәм Галия Мадыйгуловалар еш кына концертлар белән чыгышлар ясадылар, спектакльләр куйдылар”, - дип языла ул китапта. Шулай ук, Галия апа, шул чордагы укытучылар белән берлектә, авылда мәдәниятне үстерүдә зур эшләр башкаралар.

Галия Мадыйгулова соңрак Бакырчы, Наратлы, Карашәм авылларында башлангыч сыйныфларда укытучы булып эшли. Балаларга белем бирүче, гыйлем нуры чәчүче, күңелләренә яхшылык, рәхимлелек, сафлык орлыкларын салучы кешеләрнең берсе була ул. Хезмәт дәверенең соңгы елларында туган авылы Акъегеттә башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә.Үз хезмәтен тырышып башкара, укучыларга белем бирү өстендә армый – талмый эшли. Галия Кәлимулла кызының эш стажы - 34 ел .



**Хәлимә Кәлимулла кызы Мадыйгулова** (1899-1957) Акъегет авылында дөнъяга килә. Заһидулла Шәфигуллинның җәдит мәктәбендә укып белем ала. 1920-21 елларда Акъегет авылындагы балалар йортында тәрбияче булып эшли. 1922-1933 елларда Акъегеттә башлангыч сыйныф укучыларына белем бирә. Бала күңеле ап-ак кардай чип-чиста, ә Хәлимә Кәлимулла кызы – шул аклыкка тирән юллар сызучы була. Төн йокысын йокламыйча әзерләнгән дәресләр, сыйныфтан тыш чаралар – укытучының тирән белем, әхлак тәрбиясе бирергә тырышуы белән аңлатыла. Чынлап та, ул үзенең хезмәтендә күп төрле матур сыйфатларын ача: укымышлылык, җаваплылык, ихласлык, сабырлык, хезмәт сөючәнлек, ватанпәрвәрлек һәм башкалар. Билгеле, шундый мөгаллим генә үзенең фәненә ярату, кызыксыну хисе уятырга сәләтле.Хәлимә Мадыйгулова шундыйлардан була. Авылда беренчеләрдән булып, спектакльләр, концертлар куеп, халык алдында чыгышлар ясый. Алдынгы авыл яшьләрен мәдәни чараларга тартып, “Галиябану”, “Хаҗи әфәнде өйләнә” кебек спектакльләрне сәхнәләштерәләр.



Татарстанның халык артисты У.Әлмиев “Еллар һәм җырлар” китабында “Мәктәптә укыганда, ни өчендер укытучым Хәлимә Мадыйгулова – бу егет артист булыр, дия иде”- дип искә ала.

1933 елларда Хәлимә апа үзенең тормыш иптәше Әхмәтов Харун Әхмәт улы белән Норлат мәктәбендә укыту эшен дәвам итә. Башлангыч сыйныф балаларына тирән белем һәм тәрбия бирүдә зур эш башкара. Балаларда мөстәкыйльлек һәм белемгә омтылыш тәрбияли. Стажы 34 ел.

Харун Әхмәтов 1899 елда Күгеш авылында туа. 1923-33 елларда Акъегет мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли. Харун Әхмәт улы, тирән белемле, абруйлы укытучы була. Мәктәптә уку – укыту эшләре буенча мөдир урынбасары булып эшли.

1933 елдан Норлат урта мәктәбендә рус теле укыта.Үз эшенең остасы, гаять тирән белемле бу укытучының дәресләре мавыктыргыч, аңлаешлы, тирән эчтәлекле була. Харун Әхмәт улын укучылары бүген дә тирән ихтирам, хөрмәт белән искә алалар. Аның хезмәте район мәгариф бүлеге тарафыннан югары бәяләнә һәм ул дәүләт бүләкләренә лаек була.Стажы -34 ел.

Сөнгатулла белән Өммегөлсемнең олы кызлары – **Нурия** (1925 -2014) әти – әнисе юлыннан китеп, укытучылык һөнәрен сайлый.

Саф күңелле кечкенә бала, мәктәпкә аяк басу белән, беренче укытучысының җылы карашын тоя, ягымлы тавышын ишетә.Укытучы алда торган максатына ирешү юлларын ача: сабыйларга белем һәм тәрбия бирә. Уйлап карасаң, укытучы һөнәре – бик катлаулы, авыр һөнәр. Укытучыдан һәр балага игътибарлы булу сорала. Сыйныфтагы укучының психологик һәм яшь үзенчәлекләрен белү һәм аңа шәхси якын килү – бик җитди эш. Дәресләрне оештыру - укытучының әйтеп бетерә алмаслык зур хезмәте. Моны яшь мөгаллимә бик яхшы аңлый. 1947 – 1951 елларда читтән торып Казан педагогик училищесында укып, укуның тәмен, кирәклеген белеп, киләчәк хыялы – балалар укыту, аларны дөньядагы иң яхшы кеше итеп күрү теләге белән башлангыч мәктәп укытучысы дипломы ала. 1947-1952 елларда Акъегет мәктәбендә башлангыч классларда укыта.

1952 елда Мамадыш авылы егете Әкрам белән Нурия тормыш коралар. Сугыш ветераны Сабитов Әкрам абый (1924-2012) гомер буе мал табибы булып эшләп пенсиягә чыкты. Ялга чыккач та, авыл халкы Әкрам абыйны тик тотмый, әледән әле маллары авырган чакта аңа мәрәҗәгать итә. Хөрмәткә лаек бу гаилә 3 кыз тәрбияләп үстерәләр, хәзер инде һәркайсының үз гаиләләре, оныкларын сөеп яшиләр.

Нурия Сөнгатулла кызы 1952-1956 елларда Наратлы, Күгәй, Бузай авылы мәктәпләрендә укыта. Шул ук вакытта башлангыч мәктәптә завуч васыйфасын да башкара.

1957 -1967 елларда Мамадыш мәктәбендә башлангыч класс укучыларына белем бирә.

1947-1967 еллар аралыгында Нурия апа тәрбияләгән, укыткан укучылар йөзәрләгән. Һәр елны дистәләгән баланы кабул итеп алган ул. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учрежденияләре булмаган



заманнарда, урамнан кергән балаларга хәреф таныту, нәни кулларыннан тотып язарга өйрәтү, әдәп кагыйдәләренә төшендерү җиңел бирелмәгәндер.... Махсус сәнгать түгәрәгенә йөрмәсәләр дә, менә дигән биючеләр, җырчылар, сөйләм теле бай булган, иҗади фикерле, заман белән бергә атлый торган укучылар була аның укучылары. Сабый күңелендә якты эз калдырган укытучыларын гомер буе хөрмәт-ихтирам белән хәтерендә саклаучылар бихисап. Үзенә тормыш бүләк иткән, тудырган ата- анасына бер бурычлы булса, дөньяны танып- белергә өйрәткән укытучыларына мең рәхмәтле булырга тиешлеген яши-яши төшенә кеше!!!. Укытучы үз тәҗрибәсен, белемнәрен балаларга тапшырырга тиеш. Укытучыларга исә укучылары ирешкән уңышларны күрү – бик күңелле. Укучыларының рәхмәте исә укытучылар өчен иң зур бәхет.



20 ел укыту – тәрбия эшендә булган, шул еллар эчендә никадәр сөенечләр, көенечләр, борчулы көннәр, йокысыз төннәр, дәресләр, тикшеренүләр, тикшерүчеләр булуны Нурия апа үзе генә белгәндер. Хөкүмәт, район тарафыннан , бәлки, хезмәте бәяләп тә бетерелмәгәндер Нурия Сөнгатулла кызының. Әмма гомеренең соңгы көннәренә кадәр аны онытмыйча, саулыгын – исәнлеген сораучы укучыларның, авыл халкының ихтирамын тоеп яшәде ул, бәхетле гомер кичерде.

Сөнгатулла белән Өммегөлсемнең Айрат исемле улларының балалары Рафис Байсаров (1957 -2006) һәм Радис Байсаров (1964- 2006) та әби – бабалары эшен дәвам итүчеләр.

Укытучы балага белем биреп кенә калмый, ул аны мәрхәмәтле, олыларга ихтирамлы булырга да өйрәтә. Әлбәттә, белем бирү һәркайсыбызның олы ихтирамына лаек, дөньядагы барлык яхшы сыйфатларга ия булган, белем юлын күрсәтүче маякларыбыз – укытучыларга, мәктәп җитәкчеләренә барып тоташа.Түбәндәгеләре мәктәптә җитәкче булып эшлиләр.

**Байсаров Рафис Айрат улы** – 1978 елны КДПИның физика һәи математика факультетын тәмамлагач, 1978-1979 елларда Рус Әҗәле урта мәктәбендә математика укыта. 1980 елда Күгеш урта мәктәбенә директор итеп билгеләнә.

1985 елга кадәр мәктәптә директор вазыйфасы башкару белән беррәттән математика да укыта. Стажы 7 ел.

**Байсаров Радис Айрат улы** – 1981-1985 елларда КДПИ тәмамлаганнан соң, Урысбага мәктәбенә физика һәм математика укытучысы итеп билгеләнә һәм шунда 1988 елга кадәр эшли.
1989-1990 уку елларында Татар Танае авылында яңа заманча мәктәп ачыла.
Моңа кадәр эшләгән Мамадыш мәктәбенең директоры Фатыйхов Илтөзәр Сафа улы Татар Танае урта мәктәбенә директор булып китә.
Ә Мамадыш мәктәбендә 1988-1990 елларда директор булып **Байсаров Радис Айрат** улы эшли. 2005 елга кадәр Мамадыш балаларына математика һәм физика укыта. Эш стажы – 20 ел.
Байсаровлар династиясенең гомуми эш стажы -127 ел.

Табигать берәүне дә буш итми. Укытучы булып вөҗдан, намус белән янәшә туарга кирәк. Чын укытучыга хас зирәклекне, бала җанын аңлый, кичерә белә торган сизгер йөрәк, акыл, киң күңеллелекне тумыштан юлдаш иткәннәр генә Укытучы дигән олы исемгә ирешә ала.

Без еш кына укытучыларны тәнкыйтьләргә яратабыз, әмма тәнкыйтьне һәрвыкытта үзеңнән башларга кирәклеге турында онытып җибәрәбез. Укытучы нинди булырга тиеш дигән уйлануларым

мине укучы үзе нинди булырга тиеш дигән сорауларга этәрә. Чөнки әлегә безнең төп эшебез уку бит. Минем әлеге эшемдә, ягъни укуымда алдынгы буласым килә.

# Легенда о Птице по имени Свобода

*МБОУ «Ульянковская основная общеобразовательная школа Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан"*

*Выполнила: Сундурова Александра Владимировна , ученица 9 класса*

*Руководитель: Низамутдинова Савия Тауфиковна,учитель татарского языка и литературы*

## Глава I

## Жизненный и творческий путь Рудольфа Нуриева

### 1.1 Легенда о Птице по имени Свобода

Весна 1961 года. Рудольф Нуриев в составе труппы Ленинградского академического театра оперы и балета им. С.М.Кирова (так называлсяя советское время Мариинский) готовится к гастролям в Европу. Нуриев работает над репертуаром - Солор в "Баядерке", Альберт в "Жизели", "Дон Кихот", Андрий в "Тарасе Бульбе", Голубая птица в "Спящей красавице". К пследнему образу Рудольф относится особенно трепетно - именно в нем он видит отражение своей сущности, идеи жизни, своего характера. В точности исполняя хореографию, созданную Мариусом Петипа около 100 лет назад, Рудольф хочет немного изменить тот рисунок, который повторяли десятилетиями. "Я хотел изобразить не птицу, медленно взмахивающую крыльями, как бы парящую в некоем грациозном, но бесцельном полете..., а птицу, обуреваемую сильным желанием вырваться на свободу, улететь и увидеть мир... Я хотел показать птицу, искушаемую таинственным соблазном", - напишет Рудольф потом. В сущности, в этом танце он хотел изобразить самого себя - гордого, сильного, жаждущего свободы и ставящего свою свободу превыше всего.

### 1.2.**Гнездо**

Рудольф Нуриев  родился 17 марта 1938 года. Сами обстоятельства рождения заставляют поверить в значение знаков судьбы. Рудольф появился на свет в поезде, где-то в районе Иркутска. Возможно, поэтому всю жизнь провел в движении и никогда не привязывал себя к какой-либо местности. Тогда семья - мама Фарида ханум, сестры Роза, Лилия и Резеда - ехала к отцу во Владивосток, где Хамит Фазлыевич Нуриев, кадровый военный, служил политруком в артиллерийском дивизионе.
В Иркутске старшая из девочек Роза побежала дать телеграмму - обрадовать отца, который, хотя и очень любил дочерей, все же не терял надежды обрести сына, наследника. Имя мальчику дали Рудольф. Рудик, как его потом все стали называть.
Татары любят имена с красивым, глубоким смыслом, наверное  поэтому Нуриевы своих девочек назвали, как цветы -Роза, Лилия, Резеда. А имя Рудольф для сына выбрали за звучность .
Через три года отец ушел на войну. Фарида ханум с четырьмя детьми была эвакуирована из Москвы в Башкирию, где они стали жить в маленькой башкирской деревушке. Здесь многодетную семью подстерегали голод и холод, бесконечная нужда заставляла Фариду ханум работать не покладая рук и искать все возможности прокормить семью. Сестра Рудольфа Нуриева Резеда Евграфова, проживающая сейчас в Москве , вспоминает: "Однажды зимой мама одна пошла за продуктами к родственникам - в деревню за 30 км. Возвращаясь ночью по пустынной дороге, она увидела странные желтые огоньки - и не сразу смогла понять, что это волки! Мама сняла с себя шаль и подожгла ее - так спаслась от голодной стаи". Эта история характеризует Фариду ханум как женщину отважную и сильную, хотя дети запомнили маму "маленькой, худенькой, хрупкой на вид", всегда ласковой, в то же время умеющей, не повышая голоса, быть очень строгой. А отец, наоборот, был человеком суровым и властным, с волевым подбородком, выдающим жесткость характера.

### *1.3. Проба крыла*

Когда Рудольфу было 5 лет, семья переехала в Уфу - к брату отца. Именно в этом городе будущая звезда впервые познал радость танца. По воспоминаниям сестры Резеды, Рудик рос очень подвижным мальчиком, еще совсем маленьким любил прыгать на кухне с одной табуретки на другую. А музыкальный руководитель детского сада, где воспитывался Нуриев,  вспоминала, что Рудик в свои 5-

6 лет не мог ни секунды спокойно усидеть или устоять на месте - энергия выплескивалась из него фонтаном. Чтобы как-то отвлечь мальчика и найти применение бушующей энергии, приходилось наигрывать на фортепиано популярную плясовую мелодию "Апипа". Это был первый танец в жизни Нуриева .
Танец и музыка - две вещи, пленившие сердце Рудольфа с юных лет. Он мог часами, не отрываясь, сидеть у радиоприемника, откуда между сообщениями Совинформбюро лилась музыка. "Я знал только, что с ее помощью могу вырваться из комнаты, спастись от собственного детского одиночества. С самого начала я видел в музыке друга, религию, путь к лучшей доле. Тогда я и не предполагал, что вскоре музыка породит единственную страсть, переполняющую мою жизнь -танец", - вспоминал Нуриев в своей автобиографии.
Шестилетним Рудольф попал на спектакль Башкирского театра оперы и балета "Журавлиная песнь". История благородного юноши, бедняка Юман-гула и красавицы Зайтунгуль, рассказанная музыкально-пластическим языком, подняла в маленьком сердце волну ранее не испытанных ощущений необыкновенной радости и восторга. Театр навсегда покорил сердце мальчика.
Он записался в танцевальный кружок Дома пионеров, где работали опытные педагоги, по разным причинам до и во время войны попавшие из Ленинграда в Уфу. Одна из них - семидесятилетняя Анна Удальцова разглядела в Рудольфе природный дар. Умноженный на упорство и неудержимую страсть к танцу, он мог принести к великолепным результатам. Все педагоги были единогласны во мнении, что Рудольфу необходимо продолжить обучение в Ленинградском хореографическом училище.
Но неожиданно желание танцевать встретило сопротивление со стороны отца. Вернувшись с войны, Хамит, кажется, так и не нашел общего языка с восьмилетним сыном. Отец хотел видеть Рудольфа военным или инженером, а профессия танцовщика, "балерины", как он говорил, никак не подходила для настоящего мужчины. И когда начался сбор детей Башкирии для обучения в Ленинградском хореографическом училище, Рудольфа в этом списке не оказалось. Правда потом, спустя годы, отчаянная обида на отца сменилась пониманием: Рудольф узнал, что у отца попросту не оказалось денег на билет до Ленинграда.

**1.4. Полет**

В заветное училище Рудольф все же попал. Правда, намного позже своих сверстников - ему уже было семнадцать лет. В 1955 году Нуриев в составе Башкирского театра оперы и балета, куда его пригласили после заметных успехов в художественной самодеятельности, участвовал в Декаде Башкирии в Москве. Нуриеву удалось упросить педагогов Ленинградского хореографического училища, которые в те дни тоже оказались в столице, испытать его на профессиональную пригодность.
Результат превзошел ожидания. Просмотревший Рудольфа известный московский педагог заключил, что у юноши профессиональные и природные данные есть, но необходима учеба для совершенствования мастерства и приобретения академических навыков в хореографии. "Если бы Нуриев пожелал поступить в Московское хореографическое училище, то его можно было взять в 8-й класс". Но окрыленный Нуриев выбирает Ленинград - город мечты, который манил с детства.
Так началось восхождение будущей звезды балета. В Ленинградском хореографическом училище он попал в класс талантливого педагога Александра Пушкина, который видел в учениках все их преимущества и недостатки, умел развивать их возможности до совершенства, не жалея для этого своих про- фессональных и душевных сил. Приступивший к изучению азов академической хореографии намного позже, Нуриев отличался среди остальных воспитанников Пушкина особой жадностью к знаниям, цепкостью и трудолюбием.Он, амбициозный танцовщик из провинции, не хотел оставить ни малейшего сомнения в том, что достоин этого прекрасного учебного заведения, в стенах которого обучались легендарная Павлова, Уланова, Фокин, Нежинский, Баланчин...
Успех пришел уже через три года. В 1958-ом случилось два события, сыгравших большую роль в жизни Рудольфа Нуриева. Он отлично станцевал на выпускных экзаменах, самостоятельно подготовив для них три разноплановых партии. А его выступление во Всесоюзном смотре молодых исполнителей в Москве произвело настоящий фурор. С юной балериной Аллой Сизовой, выпускницей своего же училища, Рудольф исполнил па-де-де из балета А.Адана "Корсар". Это выступление было снято на кинопленку для фильма о русском балете, и Рудольф был особенно счастлив, узнав, что его танец

увидели дома. Сестра потом написала ему, что даже в мечтах не представляла себе, как замечательно он будет танцевать. "Полагаю, мать тоже была горда и счастлива, но в нашей семье существовало неписаное правило никогда не говорить вслух о том, что нам дорого. Однако инстинктивно я чувствовал: она любила и понимала то, что я делал". Вскоре понимание пришло и со стороны отца. Сестра Резеда Евграфова вспоминает: "Родители приехали в Ленинград на спектакль с участием Рудольфа. Он выступил прекрасно, публика бурно аплодировала. А когда по громкоговорителю объявили, что в зале присутствуют родители Нуриева, думаю, и суровое сердце отца наполнилось гордостью и любовью".

### 1.5.Гроза

Итак, свершилось чудо! За три года прежде мало кому известный танцовщик из провинции Рудольф Нуриев стал первым солистом Ленинградского театра оперы и балета имени Кирова. Но взаимоотношения с руководством театра не дают полностью насладиться триумфом. Еще с малых лет, с училища привыкший идти своей дорогой, принимать решения по своему усмотрению, Нуриев не может со-гласиться  со многими вещами, навязываемыми ему "сверху". Особенно с ограничением его личной свободы.

Учитывая ожесточенную кампанию, развернутую против него, Рудольф и не надеялся попасть на гастроли в Европу. Но снова произошло чудо. Организаторы тура с парижской стороны захотели видеть на сцене молодое поколение танцовщиков. Старый состав "звезд" Кировского, многим из которых уже за 50, для них был непривлекателен. Нуриеву передают репертуар ведущего танцовщика и главного балетмейстера театра Константина Сергеева. И хотя за рубежом "непокорный" Нуриев мог создать массу проблем, престиж совет ского балета был дороже.

На сцену Парижской оперы Нуриева выпустили только на пятый день. Он танцевал "Солора" в Баядерке. Успех молодого танцовщика был ошеломляющим. Затихшая после дня премьеры французская пресса вновь заговорила о русском балете. А для Рудольфа, кроме выступлений и славы, эта поездка была возможностью общения с коллегами из французекого балета. Он успел познакомиться со многими.В наказание Нуриева решили не пускать в Лондон, где труппа должна была продолжить гастроли, а отослать обратно на родину.

И вот он, решающий момент, миг, который разделит жизнь Нуриева на две части. Там - родина, родные, друзья, учителя, здесь - возможность работать и жить по своему, возможность расти и добиться славы. Нуриев выбирает последнее. И снова молодое сердце Рудольфа бьется, желая вырваться на свободу: "Птица должна летать, видеть соседский сад и то, что лежит за холмами, а потом возвращаться домой, расцвечивать жизнь рассказами о том, как живут другие, новыми возможностями своего искусства".

## Глава II
## *Жизнь Рудольфа Нуреева в эмиграции*
### 2.1.  Новые просторы

"У новой свободы был суровый вид". Нуриев, поначалу ожидавший, что на него со всех сторон посыпятся предложения, вскоре понимает, что их и не будет. Опального артиста приютила частная балетная труппа маркиза де Куэвоса, который предложил контракт на полгода. В первое время коммунисты пытались сорвать выетупления Нуриева, устраивая манифестации в зале и кидая на сцену кусочки стекла. Но им не удавалось остановить танец, публика, очарованная талантом Рудольфа, сама наводила в зале порядок. Из дома приходили неутешительные вести. Друзья осуждали его поступок, были убеждены, что на "загнивающем" Западе его талант пропадет. Папа, бывший политрук, истинный коммунист, не мог поверить в поступок сына. Одна мама понимала сына, ее волновала лишь, есть ли у него деньги, неголодает ли он. Родных к Рудольфу не пускали. Сестра Резеда вспоминает: "Нам говорили: хотите увидеть Рудольфа -зовите его обратно.

Рудольф не голодал. Наоборот, удача, кажется, вновь улыбнулась ему. Из Франции он летит в Копенгаген, знакомиться с известным датским танцовщиком Эриком Бруном. После этой встречи Эрик для Рудольфа становится не только кумиром, но учителем и другом. Другая встреча - со звездой мирового балета Марго Фонтейн, стала началом их совместного творчества на много лет. Марго было уже больше сорока, и карьера актрисы, в прошлом прима-балерины Королевского балета Великобритании, близилась к завершению. Фонтейн дала сценическую жизнь Нуриеву на Западе, а Рудольф вдохнул в Марго новую жизнь, продлив молодость на сцене. Вместе они танцевали почти 700 раз, и дуэт "Нуриев-Фонтейн" называли самым романтическим дуэтом нашей эпохи.

Нуриев, теперь уже солист Королевского балета Великобритании, хотел танцевать и танцевал всё-классику, неоклассику, "модерн"... Он был молод, красив, прекрасно обучен, владел высокой техникой танца, замечательными природными данными, фан-тастической работоспособностью -таких на западе в то время не было. Нуриев обладал огромным сценическим темпераментом, удивительной, совершенной музыкальностью. Он как бы физически ощущал музыку, которая, сливаясь с душой артиста, становилась единой составляющей образа, создаваемого им. Он "воодушевил" танец, вдохнул в него живую и трепетную душу Человека и Артиста - этот трепет живой души обволакивал весь зрительный зал, притягивая сердца людей и заставляя их биться чаще..
70-80-е годы - расцвет творчества Рудольфа Нуриева. Он сотрудничает с выдающимся американским балетмейстером, одним из основателей стиля неоклассики Джоржем Баланчиным. Успешно работал в стиле "модерн", хореографы Пол Тейлор и Марта Грехм много ставили специально для Нуриева. Рудольф много снималея в кино и оказался не менее талантливым режиссером, поставив несколько классических балетов для разных компаний.Он поставил»Раймонду» и «Лебединое озеро". "Дон Кихота" и "Спящую красавицу", "Щелкунчика", "Ромео и Джульетгу", "Бурю".
Сбылась мечта, которая когда-то позвала Птицу за собой - он мог
танцевать что хочет и где хочет, мог выступать в самых разных уголках планеты. Голова шла кругом от одного взгляда на его расписание: вечером спектакль в Париже, на завтра с утра репетиция в Лондоне, послезавтра гала-представление в Монреале, еще через двое суток начинаются гастроли в Токио, потом два вечера в Буэнос-Айресе, турне по Австралии, телевизионная съемка в Нью-Йорке...
С 1983 по 1989 гг. он был художественным руководителем балета парижской Гранд-опера. Он успешно ставит балеты классического наследия, в годы его руководства балетная труппа Гранд-опера становится лучшей в мире.
Однажды публика ему аплодировала сорок минут стоя, занавес поднимался 89 раз. Это стало достоянием Книги рекордов Гиннеса. А всего Нуриев исполнил 120 балетных партий, снялся в 29 фильмах и стал в 1983 году Почетным гражданином Австрии. А в ноябре 1992 года министр культуры Франции Джек Ланг вручил Рудольфу Нуриеву орден Командора искусств и литературы. Эта награда присуждается за особо выдающиеся заслуги.

### 2.2 . Дорога домой

Впервые после "побега" на запад побывать на родине Нуриеву удалось только в 1987 году - он приехал попрощаться с **мамой.** И хотя Рудольф уехал с уверенностью, что мама не узнала его, сестра Резеда утверждает, что это не так. "Она узиала его, но не могла объяснить это". На родине Рудольф смог побывать еще два раза: в 89-ом, когда приехал, чтобы выступить на сцене родного Мариинского театра, и незадолго до смерти, в мае 1992-го. В Казань, родной город матери, он приехал, чтобы участвовать **в** балетном фестивале **в** качестве дирижера. Нуриев дирижировал в "Щелкунчике", в симфоническом концерте "Ромео и Джульетта". Казань в нем оставила впечатление как "город 1830-**х** годов", в котором "глаза отдыхают", а публика "замечательная".
Рудольф Нуриев умер 6 января 1993 года в своем доме в Париже. После него осталось состояние, которое, по разным оценкам, составляло около 80 миллионов долларов. Это дома **в** Париже, в Лондоне, в Нью-Йорке и Монте-Карло, ферма в Вирджинии и свой остров в Италии. Дома Нуриева были полны дорогими вещами - все заработанные деньги он вкладывал **в** антиквариат, в настоящие произведения искусства. По словам сестры Резеды, его тяга к дорогим красивым вещам объясняетея просто. "В детстве у нас не было ничего. Не то, что красивых вещей, а просто даже одеть что-нибудь потеплее, и того не было. Поэтому Рудольф уже с первых заработков всегда старался покупать нам что-нибудь".
Почти все свое состояние Рудольф Нуриев оставил двум балетным фондам, учрежденным им в Европе и Америке. Поскольку прямых наследников у него не оказалось, все имуще-ство было распродано в пользу этих же фондов.
Могила великого танцовщика Рудольфа Нуриева находится во Франции, на кладбище в Сент-Женевьев де Буа. Она оформлена в виде« восточного ковра, привлекающего взгляды прохожих блеском многоцветных камней. По утрам над последним пристанищем великого гения летают стаи птиц. И кто знает возможно, среди них есть и душа той Птицы Свободы, наконец-то освободившейся от всех земных оков.

### Выводы

1.Данная исследовательская работа стала для меня интересной и полезной, потому что я познакомилась с великим танцором, изучила его творчество.

2.Его творчество, целеустремленность заставляет задуматься о искусстве в современном мире и о том влиянии, которое она может оказывать на формирование эстетических взглядов зрителя.

3. Также я поняла, что артисты, чьё творчество мы изучаем на уроках литературы, своей жизнью, своим талантом показывают нам, как прожить жизнь достойно, всегда и везде оставаясь человеком.

**Заключение**

Размышляя о судьбе Рудольфа Нуриева, о том времени в котором он жил, понимаешь, что себя он делал сам. Нелегкий жизненный путь, но цель танцевать была им достигнута. Задумываешься о судьбе танца в целом в современном мире – мире прагматиков, рыночников. О таком искусстве как балет сегодня стали мало говорит, но хочется верить, что это пройдёт. **Балет- жестокое искусство... Искусство должно возвышать человека над обыденностью и как-то немножечко тянуть человека к прекрасному к тому, что он видит, но не может осознать. Я надеюсь, что танцы в исполнении Рудольфа Нуриева способствует этому.**

—дип язган иде. Безнең якның кешеләре, үз куллары, үз акыллары, үз фидакарьлекләре белән илебезне бизәгән, районыбызны, авылларыбызны данлаган шәхесләр тудырган җирлек. Аларның эшләре чыннан да сокланырлык. Без алар белән һәркайда, һәрдаим очрашабыз. Инде ерак тарихыбызга караган Батырша, Пугачев яуларында, болгавыр революция, гражданнар сугышы зилзиләләрендә, Бөек Ватан сугышы фронтларында, егерменче гасырның бөек төзелешләрендә-вакыйгаларында…Ерак Америкада һәм Японияядә, эссе көньяк илләрендә һәм салкын төньякта… Сәнәгатьтә, сәнгатьтә, фәндә, әдәбиятта, дини хәрәкәттә, эшмәкәрлектә, спортта… Язмыш җилләре кая гына илтеп ташласа да безнең як кешеләренең үз йөзе, үз фикере, үз сүзе бар. Алар вакыйгаларның уртасында, көрәшнең алгы сафында, иҗатның уртасында кайныйлар.

**Төп өлеш**

Халкыбызның бик тә гыйбрәтле бер сүзе бар. «Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк»- ди ул. Туган ягыбызның киләчәге матур булсын өчен аның үткәнен, хәзергесен, киләчәген бергәләп өйрәник,

бергәләп барлыйк. Шушы төбәктә туып үскән күренекле шәхесләребезне беркайчан да онытмыйк, алар белән горурланып яшик.

Кеше китә — җыры кала, диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә.
Ул җыр җанга шатлык булып керсен,
Кояш булып калсын йөзләргә.
Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк,
Җырда калсын безнең гомерләр.
Безнең дөрләү, безнең януларны
Киләчәккә җырлар илтерләр,

- дип әйтә кебек Альберт абый Әсәдуллин.

Һәр төбәкнең үз җырчысы була. Туган авылының үткәненә гашыйк булган, халкыбызның гореф-гадәтләренә чын күңелдән ихтирам иткән, җырлар җырлаганда алардан илһам тапкан якташыбыз – туган ягыбыз горурлыгы, авыл җырчысы – ул безнең авылдаш җырчы- артистыбыз–Альберт абый Әсәдуллин.

Татар авылының җырчысы бездән бик еракта яши. Ләкин бездә аның кабатланмас рухи мирасы –ул башкарган җырлар яши.

Ирексездән күзләр җырчының җылы эзләрен саклый торган яшел хәтфәгә төренгән, табигатьнең илаһи матурлыгына чумган күрше ишегалдына төшә. Ул йортка кайткан кунаклары арасыннан күңелем белән Аны эзлим. Кулларын артка куеп, бик дикъкать белән әле һаман да тирә-юньне күзәтеп йөри кебек. Хисләр дәрьясында уйларым йөзә дә йөзә һәм Альберт абыйның безнең белән очрашуында: ”Мин кая гына барсам да, авылдашларым белән горурланам, аларның хезмәт яратуларына, эшчән булуларына куанып бетә алмыйм”,- дигән сүзләре әле дә булса колак төбемдә чыңлап тора.

Җырчыбыз юкка гына авылыбыз тарихын, аның безгә үрнәк булырлык, сагынып сөйләрлек шәхесләрен яратмаган икән шул.

“Ор басуы тын, бик тын. Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында әкрен генә моңланып, берүзем басып торам...

Яшәү һәм җырлау өчен авылым суы, авылым һавасы кирәк. Шул басуларының исе кирәк. Миңа көзен сентябрь кояшы астында моңсу камыл басуында тезелеп утырган салам эскертләре кирәк. Шул эскертләрнең баш әйләндергеч исе кирәк. Шуларны исни-исни мин җыр сузам...

Исәнме, туган ягым! Исән – сау тордыңмы? Мин бит әллә ниткән күтәренке романтик хыяллар, куәтле җырлар патшалыгыннан кайтып киләм. Синдә яшәп, синдә җырларга дип кайтып киләм. Тормышның авыр минутларында юатырга онытма мине. Син бит җырларга бик бай. Бик моңлы, бик хәсрәтле алар. Шулай да, миңа авыр булганда, мине юатырга онытма…”

Уйна тальян гармуныңны
Безнең авыл көенә.
Тәрәз саен моңнар тулып,
Керсен авыл өенә.
Уйна тальян гармуныңны,
Яшьлек әрәм узмасын шул;
Моңсызлар да бер моңлансын,

Йөрәкләре сызласын.

Әйе, Альберт абый нәкъ шушы җырдагыча, үзенең туган ягы дип санаган Орны беркайчан да онытмый. Аның әнисенең эзләрен саклаган сукмаклар буйлап йөргәнен карап торсаң, һич кенә дә сокланмый мөмкин түгел. Нәгыймә апа кечкенәдән шушы без атлап йөри торган урамнардан үткән.(Кушымта №1 ) Шушы басу-кырларда җиң сызганып, тир түгә-түгә эшләгән. Аның белән бергә атлый-йөгерә Альберт абый да үткән бу урамнардан. Шушындый олы шәхеснең эзләре безнең якларда

саклануы , үзенең туган ягын беркайчан да онытмавы белән мин горурланып яшим һәм Аны үзебезнең авылдашыбыз дип саныйм.Мин шуңа күрә дә бу эшемне “Шушы яктан, шушы туфрактан без”дип исемләдем.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзебез бер якка.
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Иянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без
Читкә йөрсәк шуңа күрәдер.
Чишмә чыңлап, иянкеләр елап,
Таңнар җырлап төшкә керәдер.

Шушы якта безнең эзләр калсын,
Мираз булып килер яшьләргә.
Шушы яктан, шушы туфрактан без
Шул туфракта язсын яшәргә.

**Әсәдуллин Альберт Нурулла улы** – РСФСРның атказанган артисты, танылган эстрада җырчысы.

1948 нче елның 1 нче сентябрендә Казан шәһәренең Суконная бистәсендә туган. Әнисе Ор, әтисе – Чапшар авылыннан. Альберт үзенең туган җире дип Балтачны атый.(Кушымта №2 ) Казан шәһәренең 43 нче мәктәбендә укый, шул ук вакытта рәсем сәнгате мәктәбенә йөри. 1966 нчы елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый һәм Ленинградтагы И.Е. Репин исемендәге рәсем, скульптура һәм сәнгать институтының архитектура бүлегенә керә. Монда укыган чорда кечкенә балачактан ачылган рәсем сәнгатенә булган сәләте белән янәшә әти-әнисеннән бирелгән җыр-музыкага булган таланты ачыла – Альберт ул чорларда үтә модада булган рок-группада җырлый башлый һәм бик тиз дан ала. Ул «Призраки», «Фламинго» группаларында җырлый. (Кушымта №3)1968 нче елда комсомолның Ленинград өлкә комитеты оештырган «Питер» рок-фестивалендә катнаша һәм яхшы вокалист булып таныла. Укуын дәвам итү белән беррәттән җитмешенче елларда «Невские волны» группасында җырлый. 1974 нче елда институтны тәмамлый. Шушы чорда А. Васильев белән А. Журбин аны «Орфей һәм Эвридика» исемле беренче совет рок-операсында Орфей партиясен җырларга чакыралар. Шушы партия белән Альберт Әсәдуллин бөтен илгә, дөньяга таныла, күп чит илләрдә чыгыш ясый. Аның исеме Бөтендөнья джаз, поп һәм рок музыкасы энциклопедиясенә кертелгән. Халыкара фестивальләр лауреаты.(Кушымта №4)

1989 нчы елда Идел Болгарстанының ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуга багышланган тантаналарда «Мәһди» исемле Коръән сюжеты буенча эшләнгән фолк-рок сюитасында төп партияне башкару аның милли сәнгатькә тирән мәхәббәтен күрсәтте. Ул үзенең дөнья һәм Россия сәхнәләрендәге концертларында татар халык җырларын зур осталык белән башкара, милли сәнгатебезне пропагандалый.

Әсәдуллин репертуарында милли традицияләрне заманча популяр көйләр стиле белән бәйләүче тарихи сюжетка корылган татар җырлары да бар. Казанда Р. Кәлимуллинның «Ерактагы кәккүк авазы» (И. Юзеев либреттасы, 1989 ел) рок-операсында, «Мәһди» музыкаль тамашасында (М. Шәмсетдинова либреттасы һәм музыкасы, 1989 ел) төп партияләрне башкара. Әсәдуллин катнашында Мәскәүнең «Мелодия» фирмасы «Җыр белән гомер итик» («С песней по жизни», 1978 г.), «Орфей һәм Эвридика» («Орфей и Эвридика», 1980 г.), «Мин кайтырмын» («Я вернусь», 1981 г.), «Җырлый Альберт Әсәдуллин» («Поёт Альберт Асадуллин», 1989 г.), «Чагылыш» («Отражение», 1989 г.), «Мәһди» («Магди», 1989 г.) һәм башка дисклар чыгара. Аерым концерт программалары белән чыгышлар ясый. Россия һәм чит илләрдә (Польша, Финляндия, Германия, Һиндстан ...) гастрольләрдә була. Сочи шәһәрендә совет җырларын башкаручыларның бөтенроссия (1 нче бүләк, 1978 ел),

Ленинград шәһәрендә эстрада артистларының бөтенсоюз (1 нче урын, 1979 ел) конкурслары, Болгариядә уздырылган «Алтын Орфей» халыкара конкурсы (1 нче бүләк, 1979 ел) лауреаты.

А. Әсәдуллин – РСФСРның атказанган артисты. 1998 елда Татарстанның халык артисты исеме бирелде. II Бөтендөнья татар конгрессы делегаты.

Хәзерге көндә Санкт-Петербург шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

Санкт- Петербургта яшәп , рус эстрадасында эшләсә дә, Альберт Әсәдуллин үзенең татар икәнлеген онытмый, татарча уйлый, фикер йөртә. “Кызым Алисәгә көн саен иртән татарча эндәшәм, хәерле иртә телим”, - ди җырчы.(Кушымта №5) 1980 нче елларда аның репертуарына да татарча җырлар керә. “ Донецк шәһәрендә концерт куябыз. Программада бер генә татарча җыр да юк. Залдан татарча җыр сорадылар. “Әниемә хат”ны башкардым. Тамашачы җырны әсәрләнеп тыңлады. Мине озак сәхнәдән җибәрмәделәр”- дип искә ала ул бу турыда Балтачка килгәч биргән әңгәмәсендә. “Парижга баргач, “Тәфтиләү” җырын башкардым. Халыкның гаҗәпләнүен, соклануын күрсәгез иде. Мин нинди генә телдә җырласам да татар булып калам”,- дип әйтә ул. Ул үзенең дөнья һәм Россия сәхнәләрендәге концертларында татар халык җырларын зур осталык белән башкара.

Чөнки бу моңнар, бу җырлар аңа шушы туган авылында сеңеп калган бит. Туган як моңы, туган як җырлары һәркем өчен кадерле.(Кушымта №6)

Шуңа күрә һәр кешегә Туган ягы кирәк. Әйе, чыннан да туган яктан башка тормышның яме, ризыкның тәме юк –дип, юкка гына әйтмәгәннәрдер безнең әби-бабаларыбыз. Шушы хис-кичерешләр белән яшәүче ерактагы авылдашларыбыз, үзләренең бала чагын, туган авылын, нигезен, яшьлек елларын, анда үткәргән көннәрен сагынып, еш кайталар безнең якларга. Кайткач, үз сукмакларын гына искә төшереп калмыйлар, үзләренең иҗатлары, уңышлары белән дә уртаклашалар.

40 градуслы эссе җәй көнендә күңелне юата, җаныңны дәвалый, татар булуыңа сөендерә, милләтең белән горурландыра торган концерт карарга насыйп булды безгә. Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллинның хәйрия концерты иде бу.Бу концертларны ул хәзер ел саен диярлек куеп китә авылдашларына. Бу чыгышларны без дә бик яратып тыңлыйбыз. Һәр ел саен аның белән әңгәмәләр үткәрәбез. Бергәләп фотога төшәбез. Үзенең танылган шәхес булуына карамастан, ул безнең белән дә бик теләп аралаша. Әле ул үзенең күрше-күләннәрен, ерак туганнарын җыеп, авылыбыздагы “Ял” кафесында әнисе рухына багышлап дога укыта. Бу эше дә аның туган ягын, туган нигезен, туган туфрагын, әти-әнисен онытмавын искәртеп тора.(Кушымта №7)

Күпләр белмиләрдер әле: Альберт әфәнденең тормышында әнисенең туган авылы – Татарстанның Балтач районы Ор авылы шактый матур бизәк булып тора. Казанда туып үссә дә, тамырларының авылдан икәнен беркайчан да онытмады ул. Әнисенең җирсүен басар өчен һәр ел саен авылга кайтып йөргән малайның киләчәктә зур артист буласын авыл агайлары белде микән? Алар өчен Альберт Нәгыймә улы гына иде. Яшьтән әнисен тирән хөрмәт иткән, кешеләрдән оялмыйча, әнкәсенә җылы мөнәсәбәтен һәрдаим күрсәтеп торган бу егеткә карап, күп аналар көнләшкәндер дә. Чөнки авылда матур хисләрне күрсәтергә адәм баласы никтер ояла. (Кушымта №8)

Гомер буе шәһәрдә яшәгән, бик күп илләрдә йөргән артист татарчаны әйбәт белә. Һәрбер сүзнең тәмен тоеп, мәгънәсен тирән аңлап җырлый, сөйләшә. Моның өчен әнкәсенә рәхмәтле ул. Туксан бергә җитеп, бакый дөньяга күчкән әнисен ярату, сагыну хисе алып кайта бу ирне Орга. Әнкәсе белән бергәләп йөргән сукмаклардан үтте ул, әнкәсе белән аралашкан, ап-ак яулыкларын безнеңчә, татарча бәйләгән авыл әбиләренең хәлен белде. Сәхнәдән Нәгыймә карчыкның ахирәтен, безнең иң кешелекле күршебез – гомер буе балалар укыткан Язилә апаны да туган көне белән котларга онытмады.

Тамашачы “саекты”, аңа җиңел музыка, утырган җирдән сикертә торган җырлар гына кирәк, шундыйларны халык яратып тыңлый, дигән фикерләр очрый. Альберт Әсәдуллин концертын караганнар, аның тамашачысы белән очрашканнар болай дип әйтмәс.

Концертта башкарылган һәрбер җыр үзенең биюе белән үрелеп, тирән эчтәлекле бер спектакль хасил итә. Альберт Әсәдуллинның шушы җәйге челләдә Чаллы шәһәреннән үк килгән иҗатташ дуслары, “Болгар” бию театры коллективы чыгышын карап, халык җырларына да шундый биюләр куеп була икән дип сокланып утырасың. Конферансьеның “Җырчы бүгенге чыгышын әнисенең якты истәлегенә багышлый”, – дигән сүзләрен ишеткәч, тирәбездә утырган тамашачылар концертны карап бетерерләрме, кубып чыгып китмәсләрме – күңелдә шундый шик туган иде. Тамашачының яшь үзенчәлекләрен истә тотып төзелгән концертның ни арада беткәнен сизмәдек тә.

“Сирәк язасың, дип үпкәлисең, әнием,<br>Үпкәләргә син генә хаклысың.<br>Безнең өчен күргән хәсрәт эзләреннән<br>Маңгаеңда сырлар саклыйсың”.

Акапелла башкарылган бу җыр артистның мимикасы, тирән хисләре аша аналарга булган яратуны да, алардан гафу үтенүне дә, тамашачыга җырчының теләк-хисләрен дә аңлатты. Классик җырларга, чын күңелдән башкарылган җырларга сусаган икән халык. Яулык читләре белән сак кына күз яшьләрен сөрткән апаларны күптән күргән булмаган икән инде. (Кушымта №9)

Гел шәһәр халкына тамаша күрсәткән артистларга авылның кечкенә сәхнәсендә концерт кую сәердер. Авыл тамашачысының психологиясе дә үзгә кебек тоела безгә. Сызгырып, кычкырып, залны “куптару” кирәктер инде... Авыл кешесе башка бит ул.

Концертлардан соң Альберт Нурулла улы Әсәдуллин белән әңгәмәләр корылды. Шул әңгәмәне дә язып үтим әле.

Казанда Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Альберт Әсәдуллинның юбилей концерты узды. 2013 елның 1 сентябрендә җырчыга 65 яшь тулды. “Мин үземнең 65 яшемне тоймыйм. Кешенең яше туган елы белән билгеләнми, ә аның күңел халәтенә бәйле, диләр. Бу чыннан да шулай. Өстәвенә, кызларым да картаерга ирек бирми. Олысына - Алисәгә әле 13 яшь кенә, ә кечесе - Алинәгә 11 яшь ярым гына”, - ди Альберт Әсәдуллин.

- Альберт әфәнде, гадәттә зур юбилейлар үткән көннәргә нәтиҗә ясарга этәрә. Сез 65 яшегезне нинди уйлар белән каршы алдыгыз?
- Чыннан да һәр кешенең үз гомерендә үткән тормышына нәтиҗә ясый торган көннәре була. Шушы алтмышынчы дистәне ваклый башлавым миңа да уйланырга сәбәпләр бирде. Иҗади уңышларым, казанышларымны барларга теләк уятты. Узган елларга әйләнеп карасаң, бик күп эшләнгән икән бит... Юбилей уңаеннан концертлар оештырырга дусларым тәкъдим итте. Әлбәттә, бер концертта гына бөтен иҗатымны чагылдырып булмый. Шулай да аларга кызыклы гына программалар төзедем. Юбилей концертларын мин өч шәһәрдә үткәрергә карар кылдым: иҗатташ дусларым, минем иҗатымны белгән һәм яраткан кешеләр яшәгән шәһәрләрдә - Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм Казанда. Мәскәүдәге концерт 5 октябрьдә Светлановский Зур орган залында узды. Төп концерт исә Санкт-Петербургта оештырылды. Мин Казанда туып үссәм дә, артист буларак сәнгатьтә үз урынымны Санкт-Петербургта таптым. Монда инде 46 ел яшим. Концерт “Октябрьский” Зур концерт залында үтте. Тамаша залы шыгрым тулы иде, шәһәрнең бөтен бомонды җыелды. Сәхнәдән дусларым котлап, чыгыш ясады... Пьеха, Боярский, Буланова, Корнелюк...
- Казанлыларга нинди музыкаль программа тәкъдим иттегез?
- Казандагы концерт башкалардан аерылып торды. Концертта татар телендә дә җырлар башкардым. Бәйрәм «Орфей һәм Эвридика» операсыннан увертюра белән башланып китте. Мин бу әсәр белән профессиональ сәхнәдә артист буларак туган кеше. Шулай ук профессиональ музыкага килгәнчегә кадәрге иҗатымны да күрсәттем : рок-н-рол көйләреннән попуррилар яңгыраттым.
- Казандагы концертка кунаклар килдеме соң?

- Казанның М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында концертта танылган татар җырчылары катнашты. Мәсәлән, Илһам Шакиров, Венера Ганиева, Салават, "Зө-Ләй-Лә", "Казан егетләре" чыгыш ясадылар. Татарстанда артистлар арасында эчкерсез мөнәсәбәтләр саклана, дип әйтәсем килә. Мәскәү кебек зур калаларда, әйтик, чын дустанә мөнәсәбәтләрне очратуы инде бик кыен. Анда берәр таныш артист сине туган көнең белән котлап, концертыңда җырлавын теләсәң сүз шунда ук акчага барып терәлә, "йолдызлар" бик зур гонорарлар таләп итә. Югыйсә, бенефис бит ул гадәти концерт түгел, ә тәбрикләүләр кичәсе, эчкерсез бәйрәм булырга тиешле чара. Аллага шөкер, мин юбилей кичәләремне оештырганда андый хәлләргә дучар булмадым.

- Казанның 1000 еллыгы уңаеннан сез татар җырларыннан торган "Энҗеләр" дип аталган диск чыгарган идегез. Концерта андагы җырларны да башкардыгызмы?

- Әйе, "Энҗеләр" дискына кергән биш җырны башкардым. "Энҗеләр" проекты өстендә мин бик теләп, кызыксынып эшләгән идем. Анда иң матур татар халык җырлары да, заманча композиторларның да танылган җырлары урын алды.

Бу дисктагы бер-бер артлы яңгыраган җырлар, минемчә, гомумән алганда, тулы бер әсәрне тәшкил итә. Чөнки анда җырлар арасында бернинди пауза юк, алар сизелми генә бер-берсенә бәйләнеп китә. Дисктагы беренче трек җыр түгел, ә шушы әсәргә кереш өлеш, андагы тавыш-авазлар минем поездга утырып, Санкт-Петербургтан Казанга килүемне тасвирлый. Менә мин вокзалга аяк бастым, янәшәмнән чәчәк сатучы татар апалары узып китә, шул арада дусларым шатланышып мине каршы ала, хәлемне сораша. Шулай мин акрын гына Казан урамнары буенча атлап, әнием өенә кайтам, юлда туктап эскәмиядә утырган әбиләр белән сөйләшәм... Җырлар белән үрелеп барган бу сәяхәт минем сагынып, туган шәһәремә кунакка кайтуым турында. Дискка "Киек казлар", Тәфтиләү", "Күбәләк", "Хуш авылым", "Тала-тала" җырлары керде. Аларны мин концертымда җырладым.

Әйтергә кирәк, минем "Тала-тала" җырында башка төрле милләтләрнең көйләре, музыка уен кораллары да ишетелә. Минемчә, дөньяда милләтләр, мәдәниятләр арасында чикләр булырга тиеш түгел. Без XXI гасырда яшибез. Бүгенге көндә очкычка утырып, берничә сәгать эчендә дөньяның теләсә кайсы иленә барып җитәргә мөмкин. Бөтен мәдәниятләр янәшә яши, "Тала-тала"да шуны аңлатырга теләдем. Мин нинди телдә җырлыйсым килсә, шул телдә җырлаячакмын. Милләтләр үз эченә бикләнеп ятмасын иде. Башка мәдәниятләр белән кызыксыну ул әле үзеңнең милләтеңне оныту дигән сүз түгел. Һәм мин онытмыйм да. Дисктагы "Хуш авылым" җырында әниемнең тавышы яңгырый. Мин аңа: "Әнием утыр әле яннарыма, сөйләшик әле", - дим. Ә ул җавапка: "Әй улым, сөйләшер сүзләр күп булыр, син илеңне, туган нигезеңне, нәселеңне онытма", - дип изге теләкләрен әйтә.

- Концерт программасы бик кызыклы булды. Тагын нинди сюрпризлар әзерләдегез?

- Концертның икенче бүлегендә "Мәгъди" музыкаль проектыннан әсәрләр тәкъдим иттем. "Мәгъди" - 1989 елда Бөек Идел буе Болгарстаны халыклары Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлап, Казанда зур стадионда күрсәтелгән музыкаль фолк-рок опера ул. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин мине шушы проектны тормышка ашырган өчен Шураның данлыклы бүләге - "Аль-Фахр" ордены белән бүләкләде. Әлеге музыкаль проект турында сөйләшергә мин беренче булып аңа килгән идем. Равил хәзрәт бик куанып: "Альберт, Аллаһы Тәгалә сине үзе җибәргәндер, - диде. - Бу музыкаль әсәр мөселман халкы өчен зур бүләк булачак", - диде һәм аны тормышка ашырырга зур ярдәм күрсәтте.

- Казанда туып үстем, Санкт-Петербургта үземне артист буларак ачтым, дидегез. Төньяк башкаланы яуларга нәрсә этәрде?

- Кеше бер төбәктә туып, тормыш юлын икенче төбәктә, икенче шәһәрдә дәвам иткән, анда үз урынын тапкан очраклар бик күп алар. Мин балачакта Казанда сәнгать мәктәбендә укыдым, аннары сәнгать училищесына кердем. Каникулларда безне Ленинградка Югары политехника институтына һәм Сәнгать академиясенә экскурсиягә алып баралар иде. Мин андагы иҗади мохиткә хәйран калып кайттым. Нәтиҗәдә училищены ташладым, кичке мәктәпне тәмамладым да, Сәнгать академиясенә укырга киттем. Студент чакта музыка белән ныклап кызыксына башладым, дуслар белән үз рок төркемебезне оештырдык... Шул чордан бирле музыкадан аерылганым юк.

Читтә яшәсәм дә мин Казанга бик еш кайтам, сагынырга өлгерәм, дип тә әйтә алмыйм. Кызганычка, әнием инде вафат. Ул минем Казанда яшәвемне бик тели иде. Соңгы елларда күренекле

жырчы үз ягына еш кайта. Ор урамында да очратырга була аны. Әнисе ягыннан туганнары яшәгән авылны якын күреп, ӘНИСЕ йөргән урамнарны сагынып кайтадыр ул.(Кушымта №10)

Безнең татар халкы борын-борыннан җырга-моңга хирыс халык. Шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә ул. Татар халкы моңнан яралгандыр, ахрысы. Шулай булмаса, халкыбызның "Кара урман", "Шахта", "Гөлҗамал", "Тәфтиләү", "Әллүки", "Зиләйлүк"ләре булмас иде. Әйтерсең, җырларда бөтен үткән фаҗигале татар халкының күңелен нечкәртеп, җанына рәхәтлек бирүче аһәң булып яңгырый, аның йөрәгенә барып җитә дә күңелендәге изге хисләрне уята, тетрәндерә.

Җырлар бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале мирастыр. Җырларның җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бер нәрсә булганы өчен аларга зур әһәмият бирергә кирәк. Аларны кадерләргә, югалтмаска, буыннан буынга тапшырырга кирәк.

Кеше, үзенең көндәлек тормышында, сагыш, кайгыдан арынасы, яки, киресенчә, эченә сыймаган шатлыгын, куанычын белдерәсе килсә, җырлап җибәрә. Күптән ишетелгән, күңелендә сакланган, үзенең хис – тойгыларына туры килә торган көйне суза.

Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда – җыр мәңге яши. Җыр ул – яшәү чарасы. Җыр – ул халыкның җаны. Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек, үзенең җыры, музыкасы һәм музыка уен-кораллары булмаган халык та дөньяда юк.

Татар халкының гасырлар буе тудырган бай җыр культурасы үсеп килүче яшь буынга музыка тәрбиясе бирүнең нигезен тәшкил итә. Кешенең туганнан алып бөтен гомере җыр һәм музыка белән тыгыз бәйләнештә уза. Ул иң элек бишек җыры тыңлап үсә. Соңрак кеше тормышында уен, хезмәт һәм көнкүреш җырлары киңрәк урын алып бара.

Җыр – ул рухлану, җыр – ул матурлыкка соклану. Җыр кешенең юлдашы. "Җырсыз кеше – канатсыз кош" – ди халык.

Җыр – кешенең балачагыннан алып соңгы гомеренә кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ул нечкә күңелле, мәрхәмәтле була. Ә нечкә күңелле, матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул кешеләрне ярата, чит җирләрдә яшәгәндә дә туган ягын сагынып яши, йомшак бәгырьле кешеләргә ярдәмчел, мәрхәмәтле була.

Җырларны, халыкның милли көйләрен, уен җырларын бөтен нечкәлекләре белән оста һәм матур итеп башкару – ул үзе бер сәнгать.

**Йомгаклау**

Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен аның гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, әкият-дастаннарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия тәртипләрен ана сөте белән сендереп үсү кирәк. "Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс" – дип халык юкка гына әйтми.

Танылган педагог В.А.Сухомлинский үзенең "Чын кеше тәрбияләү" хезмәтендә: "Музыка лирик поэзия белән тыгыз бәйләнгән һәм аны кешенең рухи үсешендә алдагы этап дип әйтергә була. "

Җыр – халыкның иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше.

Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге һәм киләчәк көннәр аһәңен дә ишетәбез.

Халык җырны юлдаш һәм сердәш дип, сабак һәм васыять дип атый. "Җыр – эшнең камчысы", "көй-күңелнең моңы" дигән әйтемнәр яши.

Татар халкының җыр чишмәсе чал гасырлар түреннән агып килә. Юлында карурманнар, биек тау-кыялар очраса да, туктамаган ул чишмә, үзенең сихерле моңнары, тылсымлы авазлары белән

кешеләргә куаныч, юаныч, дәрт биреп һаман аккан, һаман җырлаган. Яңа тормыштан матур аһәңнәр алып ул чишмә бүген дә чылтырап ага.

Җыр чишмәсе чылтырап аксын өчен, бүгенге көндә безгә илһам биреп торучы якташыбыз, авылдашыбыз булуы белән, без һәрвакыт горурланып яшибез. Альберт абый Әсәдулинның моңнарын, җырларын һәркөнне үзебезгә девиз итеп кабул итәбез, шул җыр- моңнар белән дәртләнеп яшибез, тормышны, дөньяны таныргa өйрәнәбез.

Яшь буында татар халкы иҗатына мәхәббәт тәрбияләүдә җырлар әһәмиятле роль уйный. Җыр мирасы – татар халкының бетмәс-төкәнмәс рухи хәзинәсе, күңел көзгесе ул. Үзендә тарихи шигърият һәм көй-моңны берләштергән булуы белән җыр элек-электән халыкның рухи таләпләренә җавап биреп, эстетик ихтияҗын канәгатьләндереп килгән һәм килә.

Мин бу эзләнү эшемне әле күп елларга дәвам итәргә уйлыйм. Чөнки Альберт абыйның эшчәнлеге, аның иҗаты әле һаман да дәвам итә, һәм ул дәвамлы булсын. Аның тормышының, иҗатының ничек булуын күрсәткән материалларны, аның белән үткәргән интервьюларны барлап,авылыбыз музеена тапшырсам, мин бик бәхетле һәм кирәкле эш башкарган булыр идем. Безне сөендереп, дәртләндереп ел саен авылыбызга эзен суытмасын иде. Мин дә аннан үрнәк алып, аның җырларын тыңлап, үземнең язмышымны җыр, музыкага бәйләргә уйлап торам әле. Минем дә хыялларым тормышка ашсын иде. Һәм бу урында “ Амин, амин, амин” диясем генә килә.

**Кулланылган әдәбият**


1. Фатих Урманче. Татар халык иҗаты. Казан - Мәгариф, 2005 – 383 б.
2. Хрестоматия. Татар халык иҗаты. Казан – Мәгариф, 2004 – 479 б.
3. К. М. Миннулин, Ф. И. Урманче. Татар халык иҗаты. Казан–Мәгариф, 2001–183 б.
4. Р. Х. Шәймәрданов, Ә. Н. Хуҗиәхмәтов. Татар милли педагогикасы. Казан – Мәгариф, 2007 – 399 б.
5. Ә. Н. Хуҗиәхмәтов. Педагогика. Казан – Матбугат йорты, 1998.
6. Ягъфаров Р. Ф. Йомгак таптым: Балалар фольклоры. Казан – Мәгариф 2000 – 159 б.
7. Надиров И. Н. Татар халык иҗаты. Казан – Татарстан, 1980 – 319 б.
8. Орлов Ю. М. Психологические основы воспитания. Москва Издательство – Московского университета, 2000 – 80 с.
9. И. Алмазов. Бишек җырлары. Казан, 2000.
10. З. Мансуров. Җырларыбыз. Казан, 1989 – 542 б.
11. З. Мансуров. Җырлап ачыла күңел. Казан, 1993.
12. “Тәрбия” газетасы. Яр Чаллы, 1999 ел № 12 (34)


## «Какая безмерная тяжесть на женские плечи легла...»


*МБОУ «Татарско-Танаевская СОШ имени Афзала Шамова» ЗМР РТ*

*Выполнила: ученица 11 класса Мустафина Алина Равилевна*

*Руководитель: учитель истории Мирхатуллина Гульназ Рафгильевна;*

*учитель начальных классов Галиева Гульгана Гарафовна*


В мир приходит женщина, чтоб свечу зажечь,
В мир приходит женщина, чтоб очаг беречь,
В мир приходит женщина, чтоб любимой быть.
В мир приходит женщина, чтоб детей родить.
В мир приходит женщина чтоб цветком цвести.
В мир приходит женщина чтоб мир спасти.

Женщина и война. Оба эти слова женского рода. Но они не совместимы.

Женщина и война

Да разве об этом расскажешь-
В какие ты годы жила!
Какая безмерная тяжесть
На женские плечи легла!

Великая Отечественная война была огромным испытанием для советского народа. Все достижения экономики в военный период были бы невозможны без подлинного героизма людей, которые работали не жалея сил, не считаясь со временем и в тяжёлых условиях, делая всё для Победы. Подвиг на фронте смыкался с подвигом в тылу. Усилия тех, кто сражался с оружием в руках, сливались с усилиями тружеников тыла.

Женщина грозных сороковых спасли мир. Они защищали Родину, шли в бой с оружием в руках. Сражались с врагом в небе перевязывали раненых, уходили в партизаны, стояли у станка, рыли окопы, пахали, сеяли, растили детей.

Война не обошла стороной и деревню Карашам Зеленодольского района. С первых же дней на фронт ушло все трудоспособное население, все кто мог держать оружие, всех собрала война. В тылу остались старики, женщины, дети и подростки. Вся работа легла на плечи этого населения. Из книг, документов я узнал о женщинах, которые оказывали непосильную помощь фронту, работая в сельском хозяйстве. Женщины овладели профессиями, раньше считавшимися исключительно мужским. На место трактористов за руль сели женщины и за годы войны доказали, что женщина за рулем не отстает от мужчин, а многие работают лучше чем мужчины.

С этого и началась моя поисково-исследовательская работа о женщинах трактористах. Из рассказов моей бабушки я узнала, что Саттарова Магмура Муталлаповна в годы войны освоила профессию тракториста и 38 лет проработала на тракторе.

Меня это заинтересовало и я начала исследовательскую работу.

Актуальность исследовательской работы.

В 2017 году наша страна отмечает 72-летие Победы над фашистской Германией и данная работа является воспоминанием о Саттаровой Магмуре Муталлаповне.

Задачи исследовательской работы:

1. Из бесед с местными жителями, из газет узнать о трудовой жизни М.М. Саттаровой.
2. Встретиться с сестрой Фирдаусой Сагдиевой и записать воспоминания.
3. Дополнить материалами школьный музей.

Саттарова Магмура Муталлаповна родилась в 1926 году в деревне Карашам. В семье их было 6 детей Хаерлебанат, Галия, Магмура, Зулайха, Фирдауса, Миляуша.

Окончила в Карашамской школе 4 класса. В 14 лет она поступила на курсы трактористок в Нурлатскую МТС. То было суровое военное время. На разных машинах пришлось трудиться Магмуре Саттаровой за 38 лет своей трудовой жизни. В сороковые годы пахала землю на Харьковских колесницах. Помнила Магмура Муталлаповна и пятидесятые годы, когда наравне с мужчинами водила мощный дизель. Тогда же в 1953 году вступила она в партию коммунистов. Шли годы и с ними росло и мастерство старательной трактористки. Ежегодно она пахала, сеяла, обрабатывала почву ни в чем не уступала мужчинам трактористам.

Магмура Муталлаповна неоднократно участвовала на районных и республиканских соревнованиях пахарей и занимала призовые места.

Нередко обращались к ней с различными просьбами специалисты, товарищи по работе. И всегда приходила на помощь это отзывчивая, трудолюбивая женщина. Она делала все возможное, чтобы выполнить работу быстро и хорошо.

В колхозе знали за трактористкой Саттаровой проверять качества работы не нужно. У ней очень высоко развито чувство ответственности за порученное дело. Будь она на весеннем севе или поднимают зябь. Она всегда шла впереди соревнующихся.

За добросовестный труд по итогам восьмой пятилетки Магмура Муталлаповна награждена орденом Трудового Красного Знамени, а за самоотверженный труд в 1973 году передавая трактористка колхоза «Комсомолец» Зеленодольского района коммунистка М.М. Саттарова удостоена самой высокой правительственной наградой – орденом Ленина. Магмура Муталлаповна имеет 5 грамот

Республики Татарстан. 12 районных грамот, 15 колхозных грамот. Она ветеран труда. За доблестный труд она награждена медалями и нагрудными знаками.

Магмура Муталлаповна была депутатом двух созывов Городской Думы Республики Татарстан. Она удостоена звания Почетной гражданки г. Зеленодольска.

Россия всегда была богата героями. Они жили и умирали за нее во все времена, не афишируя свои подвиги на войне и в ратном труде. И мы обязаны внимательно относиться к людям, вынесшим на своих плечах все тяготы, лишения и ужасы Великой Отечественной. С каждым днем все меньше и меньше остается участников тех страшных событий. Но жизнь продолжается. Саттаровой Магмуры Муталлаповны уже нет в живых. 28 августа 2015 года Магмура Муталлаповна умерла. Я считаю, что Магмура апа и все те, кто помогал приблизить победу на трудовом фронте - настоящие герои. Ведь они не жалели ни своих сил, ни своего здоровья, чтобы наши солдаты на фронте не знали нужды в хлебе.

А это всего лишь одна история трактористки Саттаровой Магмуры Муталлаповны , а ведь таких женщин –трактористок не мало. Я испытываю гордость, что такая женщина была среди моих односельчан.

Своё выступление я хочу закончить стихотворением моего дяди Альберта Ильмухаметова

Еракларда калды данлы юлың,
Моңлы җыры корыч атыңның.
Ару-талу белмәс кызы идең
Сөеп туймас бөек халкыңның.

Төшләреңдә генә күргән сыман
Калды синең ул чак түзгәннәр.
Белә аны күктә ходай гына,
Бер үзең дә, янә үзәннәр.

Яшьлегеңнең чәчәк аткан чагын
Илгә дошман кереп утырды.
Бирешмәдең, тырыш хезмәтләрең
Дошманнарның көчен сындырды
Кырык еллап гиздең басуларны,
Илаһи көч табып җаныңа.
Синдәй көчле рухлар ярдәмендә
Сыйлар тулы булды табында
Мендең җырлап корыч атың белән
Кешелекнең бөек тавына.
Кеше өчен мондый бәхеттән зур
Нәрсә булыр икән тагын да.
Маңгаенда тирән сырлар бүген
Язмышларың алда, узганың.
Һәр сырында хезмәт даның юлы
Рәхмәт сиңа, Мәгъмүрә апа,
Тикмәгә син гомер узмады

## Мәгърифәтле туган ягым

*Гомуми белем бирү бюджет учреждениесе*
*“Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районы*
*Чүти урта гомуми белем бирү” мәктәбе*
*Эшләде: 9 нчы сыйныф укучысы*
*Шәрәфетдинова Эльмира Рифат кызы*

*Фәнни җитәкче: татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Козлова Раилә Навафил кызы*

## Төп өлеш

### 1.1.Чүти авылы тарихына кыскача күзәтү

Моннан якынча 400 - 500 еллар элек авылга нигез салынган. Хәзерге Аксубай районының Иске Кармәт (Хәсән Туфанның туган авылы) авылыннан ике туган Тутый кош елгасы буена килеп утырган (хәзерге мәчет урыны). Шуларның берсе - Чүти исемле булган (Болгар халык исеме). Чүти - чүт-чүт итеп ялтырый торган нур дигәнне аңлата. Авылыбызның атамасы шуннан килеп чыккан. Килеп урнашкан ике туган тирә – яктагы урманнарны кисеп, үзләренә чәчәргә җир ясаганнар. Тиздән бу җиргә Сергачтан отставкадагы офицер Кариевлар гаиләсе дә килеп урнаша. Дүртенче гаилә булып алпавыт - морза нәселеннән бер бик булдыклы кеше килеп төпләнә. Шулай итеп, авылга нигез салына. Дүрт гаиләнең җирләрендә дүрт тамга пәйда була: сәнәк, чүкеч, урак, өзәңге (иярнең аяк белән баса торган урыны).

Д. А. Корсаков җыентыгында да Чүти авылы турында мәгълүмат бар. Анда 68 йомышлы, 28 керәшен татары теркәлгән (Сборник 1908, № 194, б.324). А.Артемьев Чүти хакында түбәндәгеләрне яза. Андагы 145 хуҗалыкта 497 ир – ат һәм 503 хатын – кыз көн күргән. Авылда бер тегермән булган (Список 1866, №2745, б.138). 1898 елгы китапта Чүти авылында татарлар яшәгәнлеге искәртелә (Список 1898, №196, б. 66). К. П. Берстель хезмәтләрендә күрсәтелгәнчә, авылда барлыгы 1876 татар кешесе исәләнгән (Список 1908, №14,б.138).

### 1.2. Мәхәлләләр тарихы

Без Татарстан Республикасының милли архивыннан алып кайткан “Ведомость о магометанских приходах” дигән тарихи кулъязмадан Казан губернасы Цивиль өязенең Чүти авылында 1880-1903 елларда ике мәхәллә булганын төгәл белдек. Аның берсендә Шәрәфетдин Таҗетдин улы Бәширов имам торса, икенчесендә аның улы Габдрахман мулла - хатиб вазыйфасын башкара.

Аңа кадәр дин сабакларын аларның әтисе Таҗетдин алып барган була. Ул үзенең мәхәлләсендә җәдид мәдрәсәсе ачкан. Икенчесендә Мөхәммәтзариф Җәләлетдинов мулла була.

1903нче елны Чүтидә Акъегет авылыннан атаклы хәйрияче – сәүдәгәр Заһидулла Шәфигуллин яңа мәчет төзетә, үзе төзеткән мәдәрәсә каршындагы мәхәлләне ул дәресләр өчен кирәкле уку әсбаплары белән тәэмин итеп тора.

Әлеге уку йортында, дин сабакларыннан башка, арифметика, география һ.б.укыталар.

Мәдрәсә мәктәп бинасы составында 1994 нче елга кадәр укучы балаларга хезмәт итте. Анда 1- 3нче сыйныф балалары укыды.

Чүтидә 1996 нчы елда ике катлы, заман таләпләрен күздә тотып төзелгән яңа мәктәп бинасы ишекләрен ачты. Язын мәктәп алмагач чәчәкләренә күмелсә, җәен күз явын алырлык бакча гөлләренә төренә.

### 1.3.Мөгаллимнәр нәселе.

1880 елда агачтан беренче мәчет бинасы салына. Анда Таҗетдин Бәширов муллалык вазифасын башкара. Мәчет янына ук мәдрәсә дә ясап куялар. 1885 нче елда икенче мәчеткә дә манара күтәреп, авылда ике мәчет эшли башлый. Аның берсендә Шәрәфетдин Таҗетдин улы Бәширов имам –хатиб хезмәтен үти, икенчесендә аның улы Габдрахман имам - хатиб вазыйфасын башкара. Шәрәфетдин, Габдрахман - икесе дә белемле,читтән мәдрәсәдә белем алып кайткан муллалар булалар.

Бәшировлар нәселеннән (халык теленә мулла нәселе дип кереп калган) гомер - гомергә халыкны белемле итүгә күп көч куючы бик күп мөгаллимнәр чыккан. Алар нәселнең тарихы мәхәллә тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Авыл халкы биргән белемнәре өчен аларга бик рәхмәтле.

## II бүлек. 2.1. Шәрәфетдин Бәширов нәселе

Икенче мәчетнең мулласы киләчәктә булачак шагыйрь, язучы-прозаик, мәгърифәтче – педагог Зариф Бәширинең әтисе - Шәрәфетдин Бәширов була. Чүти мәдрәсәсе губерна хакимиятендә борчу тудырган. Анда еш кына тентүләр булып, берничә тапкыр ябарга тырышканнар. 1911 нче елның 17 нче октябрендә Бәширов Шәрәфетдин Таҗетдин улы имам –хатип вазифаларыннан читләштерелә.

### 2.2.Тукай чордашы,татар халкының күренекле мәгрифәтчесе, шагыйрь, язучы, әдәбиятчы Зариф Бәшири

Зариф Шәрәфетдин улы Бәширов (Зариф Бәшири) егерменче йөз башында татар көндәлек милли матбугаты барлыкка килгәннән соң әдәбият мәйданына күтәрелеп чыккан дистәләрчә яңа исемнәрнең күренеклеләреннән берсе. Шагыйрь, язучы - прозаик, мәгърифәтче педагог Зариф Бәшири 1888 елның 5 маенда Чүти вылында туа.

Зарифның әтисе Шәрәфетдин хәзрәт, авылда рухани вазифаларын алып барудан һәм мәдрәсә мөдәррисе булудан тыш, ул заманның барлык авыл имамнары кебек, крәстиян хезмәте белән дә шөгыльләнгән – җан башына тигән имана җирен сукалап иген чәчкән, урган, урман кискән, ат, терлек асраган. Зариф та абый –энеләре белән бергә кече яшьтән шушы мәшәкатьле авыл тормышында чыныгу ала.

Зарифның укуга сәләте, әдәбиятка омтылышы да бик иртә уяна. “Мин җиде яшемдә чагымда укырга – язарга өйрәнгән идем. Минем бөтен бирелеп укыганнарым “Таһир-Зөһрә”, “Бүз егет”, “Мәгъшукнамә”, “Кәҗә бәете”, “Килен бәете” кебек нәрсәләр була торган иде”, - дип яза ул истәлекләр китабында. Аеруча аңа “Йосыф китабы” (“Кыйссаи Йосыф”) һәм “Ярым алма” шикелле әсәрләр сөйкемле күренешләре белән җанланалар; аларның һәрбер юлы мине яктылыкка алып барган юл булып, һәрбер битләре аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән бакча мәйданнарына охшап торалар иде”, - дип яза ул.

Чүти -Тау ягының Гөбенә елгасы буена урнашкан һәм Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле зур авыл булып, тирә-ягында чуваш авыллары да күп булганлыктан, төбәк халкы милли яктан бер - берсе белән якыннан аралашып, “тел-лөгать алмашып” яшәгән. Шуңа күрә булачак язучы балачактан ук чуваш телен һәм гореф - гадәтләрен тирәнтен белеп үсә, һәм аның әдәби иҗатында да чуваш темасы аерым бер урынны били.

Зариф Бәшири 1906 - 1907 нче елларда Чүти авылы мәдрәсәсендә балаларга белем бирә. Аннан соң илебезнең күп төбәкләрендә яшәп һәм эшләп, күп халыкларның мәдәниятен өйрәнгән, тугыз телдә сөйләшкән . Чуваш, уйгыр, үзбәк әдәбияты турында фәнни хезмәтләр яза.

Чуваш,үзбәк, уйгур телләрен өйрәнеп кенә калмый, аларның тормыш – көнкүрешләрен гореф – гадәтләрен чагылдырган әдәби әсәрләр дә яза. “Ефәк корты”,Чуваш кызы Әнисә” повесте шуларның ачык дәлиле. Башкортстандагы сәнәкчеләр хәрәкәтен яктырткан "Каракош явы”дип аталган повесте дөнья күрә.

Зариф Бәширинең “Чуаш кызы Әнисә” повесте 1910 нчы елда басылып чыга, ләкин әсәр дөнья күргәч, авторга күп кенә үтенеч хатлары килә, укучылар бу әсәрне яңадан тулырак язуын үтенеп сорыйлар. “Бигрәк тә чуашларның үзләренә генә хас тормыш гадәтләрен киңрәк итеп күрсәтүемне үтенәләр”,- ди әдип, үзенең “Замандашларым белән очрашулар” китабында. Бу хатларны алганнан соң Зариф Бәшири әсәрен тулыландыра. Сюжет араларында чуашларның гореф - гадәтләрен, көнкүреш тормышларын, татар һәм чуаш халыклары арасында үзара җылы мөнәсәбәтләрен күрсәтә. Бу әсәр күршедә яшәүче халыклар арасындагы көчле дуслыкны күрсәтүе белән кыйммәтле.

Зариф Бәшири безгә бөек Тукайның, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави һәм ул вакыттагы башка күренекле кешеләрнең чордашы буларак та кадерле. Аның бу истәлекләре "Замандашларым белән очрашулар” дигән баш астында 1968 нче елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.

Зариф Бәширинең иҗаты лаеклы бәяләнмәсә дә, аны туган ягында онытмыйлар. Кайбыч районы үзәгендә Чүти авылында әдипнең 100, 110, 120 еллык юбилейлары зурлап билгеләп үтелде. Мәктәбебез бинасында әдипкә истәлек тактасы (авторы – сынчы Фәһим Фәсхетдин) куелды. Чүтидә үткәрелгән юбилей тантанасында улы Сизгернең һәм оныгы Эдуардның әйткән сүзләре дә күңелгә уелды. Эдуард бабасының эшен дәвам иттерүе, эзләнү эшләре белән шөгыльләнүе,Чүти авылына нигез салучы Чүти бабайдан башланып киткән татар ыруы Бәшировлар нәселенең тулы булмаган шәҗәрәсен төзү турында сөйләде.

## 2.4. Шәрәфетдин мулланың кызлары, оныклары

Кызлары Хәлимә, Рокыя абыстайда укыйлар.

Зариф Бәширинең бертуган сеңлесе Хәлимә Бәширова - Шыгырдан авылында туган телгә хөрмәт тәрбияләгән атказанган укытучы, бөтен гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган олы мөгаллимә. Аның хәсрәт, гыйбрәтле үткәне, туган ягын сагыну хисләре тулы шигырьләре укучылар күңелендә үз урынын тапты.

Гөбенә буе булган чиксез матур,
Тирә – якны ямьгә тутырган.
Менә шунда инде безнең нәсел -
Чүти бабай килеп утырган.
Уң як ярда булган яшел болын,
Суң як ярда куе тарлыклар.
Гөбенә суларында йөзеп йөргән
Елтыр түшле көмеш балыклар.
(Х.Бәширова)

**III бүлек.**

**3.1.Габдрахман Бәширов нәселе**

Габдрахман 1907 нче елда Буада рус мәктәбен тәмамлап кайта. Шул ук елны беренче мәхәлләдә имам тора, мәдрәсәдә дә укыта башлый. Ә кызларны аның хатыны Рокыя абыстай укыта.

Габдрахман мулланың беренче улы Фатыйх абый башта мәдрәсәдә дин сабагы укыта, аннары ул мәдрәсәдә үк дөньяви белемнәрне дә өстәмә рәвештә укыта башлый. Мәдрәсә ябылып, бу бина башлангыч мәктәпкә әйләнгәч тә, Фатыйх абый анда укытучы булып эшли башлый һәм авылның беренче укытучысы булып тарихка кереп кала.

Икенче улы Вәгыйз абый Бәширов. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә сугышка алына. Җиңү язын Польша җирендә каршылый.

1965 -1982 нче елларда Чүти урта мәктәбендә математика фәнен укыта. Мәгариф өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәте өчен дәүләт бүләкләренә лаек була.

Габдрахман мулланың кызы Әсма апа - РСФСР ның атказанган укытучысы,Чувашстан Республикасы, Комсомол районы, Тукай авылы мәтәбендә озак еллар мәктәп директоры булып эшли.

**3.2 Габдрахман кызы Мәрьямбану нәселе**

Габдрахман мулланың кызлары Мәрьямбану, Әсма, Мөнирә әнисеннән дин сабагы алалар, кече яшьтән укырга - язарга өйрәнәләр.

Мәрьямбану апа өч бала тәрбияләп үстерә. Уллары Памир, Наил,
династиягә тугры калып, мөгаллимлек юлын сайлыйлар.

Памир Мөдир улы Салихов – РСФСР ның атказанган укытучысы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы мәктәбендә математика, физика фәннәре укыта.

Лаеклы ялга чыккач, Памир абый татар халкы тарихы белән кызыксына башлый. 2010 нчы елда аның татар һәм чуаш халкының килеп чыгышы, Шыгырдан авылының тарихы буенча фәнни әһәмияткә ия булган “Шыгырдан” исемле китабы дөнья күрә.

Наил Мөдир улы Шыгырдан авылы мәктәбендә 40 ел математика, физика фәннәре укыта.
Эшендәге уңышлары өчен ул “РФСР ның Халык мәгарифе отличнигы” исеменә лаек була

Оныгы Изамиева Римма Наил кызы хәзерге вакытта Шыгырдан мәктәбендә физика, информатика фәннәрен укыта.

Кызы Гөлинәнең олы улы - Ркаил Зәйдулла - безнең горурлыгыбыз. Аның исеме шигърият сөючеләргә шактый таныш. Ул шигъриятькә беркемгә дә охшамаган гаять үзенчәлекле иҗаты, темалары һәм иҗат алымнарының яңалыгы белән килеп керде. Ркаил абый 1962 нче елда Чувашстанның Комсомол районы Чичкан авылында укытучы гаиләсендә туа. Кечкенәдән кызыксынучан, зирәк бала була ул. Инде биш яшьтән укый-яза белә. Сигез яшьләр тирәсендә шигырь чыгара башлый. Икенче сыйныфта чакта ук аның кечкенә хикәяләре "Яшь ленинчы”, "Татарстан яшьләре” газеталарында, "Ялкын” журналы битләрендә дөнья күрә. Унынчы сыйныфны тәмамлар алдыннан аны Татарстан язучылар союзына чакырып алалар һәм, шигырьләрен тикшереп, В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт универстетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керергә рекомендация бирәләр. Ул чакта ук инде Ркаил абый шактый кызыклы, үзенчәлекле шигырьләрнең авторы була. Казан дәүләт университетын уңышлы тәмамлаганнан соң,ул төрле редакцияләрдә эшли. Хәзер ул Казанда яшәп иҗат итә.

Соңгы елларда " Ел җырчысы”, " Ел китабы”, " Иң яхшы хикәя” конкурслары үткәрелә. Г. Камал исемендәге татар дәүләт театры оештырган " Яңа татар пьесасы” конкурсында Ркаил абыйның " Хөкемдар” пьесасы өченче урынга лаек булды. Ркаил абый бер үк вакытта өч – дүрт жанрда иҗат итүе

белән 21 гасыр әдипләре арасында күренекле урын алып тора. Ул Фатих Хөсни, Муса Җәлил, Габдулла Тукай премияләре лауреаты.

-Һәркем шигырь яза...
Һәм Тукайга
Мөрәҗәгать итә чор аша.
Һәр кешенең үз Тукае!
Мин дә үз Тукаем белән очрашам.
("Кояшлы күзләр" китабыннан)

Күптән түгел аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелде. Аның пьесалары Г. Камал, К. Тинчурин, Буа, Әлмәт театры сәхнәләрендә куелып тамашачының мәхәббәтен яулады. Ркаил абыйның төрле елларда дистәләгән китаплары дөнья күрде: "Кояшлы күзләр", "Күрәзә", "Урыс кышын озату", "Ил", "Татар тажы", "Мәгарә", "Ташка ордым башны"…

Ркаил абыйның аерым әсәрләре инглиз, төрек, үзбәк, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителеп, төрле басмаларда дөнья күргән. Шулай ук аның башка телләрдән татарчага үз шигъри тәрҗемәләре дә байтак кына.

Гөлинә апаның кызы Рамилә дә татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайлый. Менә 30 ел Чувашстанның Чичкан авылында укучыларда туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли. Яшь буынга белем бирүдә уңышлары өчен "Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен" күкрәк билгесенә лаек була.

### 3.2 Габдрахман кызы Мөнирә нәселе

Мөнирә апаның балалары Гиният абый, Нажия апа, Зарифа апа - өчесе дә гомерләрен яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган укытучылар булдылар.

Мотыйкова Зарифә 1934 – 1935 нче елларда мәдрәсә каршында оештырылган мәктәпнең беренче укытучыларының берсе була.

Мотыйков Гиният Мотыйк улы - Бөек Ватан сугышы ветераны. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз Ордены һәм икенче дәрәҗә Дан Ордены белән бүләкләнә.1935 – 1972 нче елларда Чүти мәктәбендә математика фәнен укыта.

Хәйрулина Нажия апа1948 -1979 нчы елларда Чүти урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбиятын укыта. Фидакарь хезмәте өчен дәүләт бүләкләренә лаек була.

Нажия апаның улы Хәйруллин Ринат абый табиб һөнәрен сайлый. Берничә ел Алабуга шәһәрендә хирург булып эшләгәннән соң, аны шәһәрнең медицина училищесына укытучы булып эшләргә чакыралар. Монда эшләү дәверендә ул директор вазифасын үти башлый. Алабуга медицина училищесында 30 елга якын фидакарь хезмәт куя, ола дәрәҗәләргә ирешә.

### Йомгаклау

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: без үз Туган төбәгебез тарихын ныграк өйрәнәбез икән, аның киләчәге турында да тирәнрәк уйланырбыз дигән нигез бар. Үткәнебез турында мәгълүматлар табарга, тарихи фактларны ачарга һәркемнең кулыннан килә. Мәктәпләрдә Туган якны өйрәнү эшен тагын да киң җәелдерсәк, әлегә исән булган өлкән яшьтәге кешеләр белән очрашсак, аларның истәлекләрен һәм сөйләгәннәрен язып алсак, Туган ягыбыз безгә үзенең кабатланмас тарихы һәм матур үзенчәлекләре белән тагын да тирәнрәк ачылыр иде. Аны белү, тарихи истәлекләрне бергә туплау, саклау безгә тормышта үз урыныбызны табарга, Ватаныбызга файдалы булып үсәргә ярдәм итәр. Һәрбер яңа буынның язмышы үткән заман белән аерылгысыз бәйләнештә тора. Бүгенге материаль һәм рухи культурабызның, барлык казанышларыбыз һәм җиңүләребезнең чыганагы әнә шуннан килә.

Авылым тарихын төрле яклап өйрәнгәннән соң, мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем: Һәр авылның тарихы булган кебек,Чүтинең дә үткәне, бүгенгесе, гыйбрәтле язмышы, истәлекле урыннары бар. Ил күләмендә барган бер генә вакыйгадан да минем авылым халкы читтә калмаган.

Чүти авылының мәгариф тарихын өйрәнгәннән соң, Бәшировлар нәселенең татар әдәбиятына Зариф Бәшири, Ркаил Зәйдулла кебек олы шәхесләрне һәм халыкны белемле итүгә зур өлеш керткән мөгаллимнәр биргән авыл икәнлеген ачыкладым.

### Файдаланылган әдәбият

1. Гарипова Ф. Авылларны сөям жаным-тәнем белән. – Казан:Тат. кит. нәшр., 1998

2. Г.Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар//Г.Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. - Казан, 2011
3. Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар. - Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. - 291 б.
4. Зарипов Р.С. Үткәннәр эзеннән.// Мәгариф.-- 1998.- №7.
Станок артында торып шигырьләр иҗат итә. Үзенең шигырьләрендә яңа стройга дан җырлый.
Яшьлегемне бирдем
Мин көрәшкә,
Кызганмадым йөрәк канымны,
Гомерлеккә минем йөрәгемдә
Кайнар көрәш уты кабынды.
Станоктан килдем
Җырчы булып,
Шагыйрь булып сезнең арага,
Дару таптым
Көрәш кочагында
Иске көннән килгән ярага, -
дип язган шагыйрь үзенең “Җырларымны бирәм күмергә” шигырендә. Ул ярлы халыкның киләчәген аларның хезмәтендә күрергә тырыша, иске дөнья киртәсен җиерергә кирәклеге турында әйтә.

Шагыйрь үзенең иҗатында совет иле дошманнарына ачулы нәфрәт белдерә, яңа авыл тормышына, техникага, артта калган илне яңабаштан коруга дан җырлый. Эшчеләр арасында танылა, аның шигырьләрен яратып укыйлар. Мансур Крымов пролетар шагыйрь дигән исем ала.

Балалар өчен дә әсәрләр иҗат итә. Мәсәлән, “Бал корты һәм Бала” шигырендә Бал корты Балага ялкаулык – ачлык, ирену – мохтаҗлык булуын әйтә. Әгәр дә син тырыш икән, киләчәгең яхшы булачагын искәртә.

“Мәктәп – умарта,
Баш миең - кәрәз,
Китап – тәмле бал,
Белем – зур тәрәз...
...Алгы көнеңә
Белем – зур азык...”

” Ике туган”, “Болында” һәм башка шигырьләрендә дә ялкауланмаска, тырышырга, ярдәмчел, белемле булырга өнди.

Шагыйрь Г.Тукай, М. Гафури, Ш. Бабич кулланган шигъри үлчәмнәрдән үрнәк ала. Рус поэзиясенә дә мөрәҗәгать итә, аларның күп кенә үрнәкләрен татарчалаштыра, алардан файдаланып

маршлар, җырлар яза. Аеруча Демьян Бедный иҗаты белән кызыксына, аның шигырьләрен үрнәк итә. Ләкин аның иҗатына күп кенә очракларда конкретлык җитмәгән.

Мансур Крыймов 20 еллар ахырында илебездә барган сыйнфый көрәш мәсьәләләрен чагылдырган. Шагыйрьнең лирик герое халык массаларының героик көрәшеннән аерылгысыз. Ул аларның күркәм сыйфатларын үзендә туплаучы образ булып күз алдына килеп баса. “Тракторчы кыз” кебек әсәрләрендә бу сыйфат бик ачык чагылган. “Җырларымны бирәм күмергә” җыентыгында эшчеләр темасы чагылдырыла. “Кызыл бәдәвам”, ”Яңа көннәр алдында”, ”Кызыл лачыннар”, “Онытылган җырлар”, “Партизаннар кебек” әсәрләрендә авыл тормышының яңабаштан корылуын революциягә күтәрелгән миллионлаган массаларның совет власте дошманнарына каршы героик көрәшен, эшчеләр һәм шахтерларның каһарманлыкларын гәүдәләндергән.

Шагыйрьнең шигырьләре үткен, ләкин кимчелекле яклары да бар. Ул кимчелекләр геройның, кешенең бай рухи дөньясын, эчке кичерешләрен сурәтләүдә игътибар итеп җиткермәү. Геройның бай рухи дөньясын, эчке кичерешләрен җылы лирик планда сурәтләүдә игътибар җитмәүдә, лирикага каршы чыгу фактлары да булгалаган. Тәнкыйтьче Гомәр Гали “Совет әдәбияты” журналында Мансур Крыймов иҗатындагы кимчелекләрне “Мансур Крыймовка ачык хат” мәкаләсендә каты тәнкыйтьләгән. Мансур Крыймов поэмаларында тормыш күренешләре, вакыйгалар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр берьяклы гына чишелә.

Озак еллар авыру сәбәпле 30 елларның яртысында сәламәтлеге начараю һәм матбугатта тәнкыйть сүзләре ишәю сәбәпле, аның иҗат активлыгы шактый сүлпәнләнә. Ул Мәскәүдән Уфага күчеп (Афзал Таһиров чакыруы буенча), гомеренең соңгы айларын шунда яшәп уздыра. Ләкин НКВД тырнагыннан качып котыла алмый. А.Таһиров кулга алынганнан соң, М.Крыймовка да чират җитә. Гөлшаһидә Сәйдәш истәлекләрендә шагыйрьнең гомере 1938 нче елның Октябрь бәйрәмендә өзелүе хакында әйтелсә, Рафаэль Мостафин язмаларында аның 1938 елның 1 августында Башкортстан Югары Суды карары нигезендә Уфа төрмәсендә атып үтерүләре турында мәгълүмат бирелә. М. Крыймовның “Шигырьләр һәм поэмалар” китабында 1940 нчы елны Мәскәү шәһәрендә үлүе турында язылган.

Мансур Крыймовның әсәрләре күп кенә җитешсезлекләренә карамастан, бүгенге көн өчен үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар. Аларда заман белән бергә атларга омтылган, җиңеп чыгу өчен көрәш белән илһамланган шагыйрьнең ялкынлы йөрәге тибүе сизелә. Ул әсәрләр туктаусыз алга, якты киләчәккә бару рухы белән сугарылганнар.

**Мансур ага Крыймов турында истәлекләр**

Мин Мансур ага Крыймов язмышы белән кызыксынып, өлкән яшьтәге абый – апалардан аның турында сораштым, музей материалларын өйрәндем.

“Мансур абый безгә туган тиешле кеше. Чури - Бурашка кайткан саен безгә кермичә калмый иде. Без дә эти - эниләр белән көлешә - көлешә чәй эчеп утырганнары исемдә... Ә кайчагында сөйләшеп утырган җиреннән, кисәк кенә тукталып калып, өйнең бер почмагына текәлер иде... Һәм бер - ике мизгелдән, барыбыз да кычкырып көләрлек, шаян юллар сөйләп җибәрер иде. Бик шаян, тапкыр,үткен телле кеше иде ул! Аның авылда дуслары да күп булган. Алар Гали абый, Насрулла Сәйдәшев, Миңнулла Газиев,” – дип искә ала Абдрафиков Вәлиулла абый.

“Мансур абыйны бик яхшы хәтерлим, - дип башлап җибәрде сүзен Исламшин Хәмит абый, - чөнки безнең күршебезгә генә кунакка кайта иде. Ул озын гәүдәле, матур кеше булып хәтеремдә калган. Дөрес, мин ул чагында әле бәләкәй генә малай. Хәтердә бигрәк тә иртәнге таңда бергәләп балыкка баруыбыз истә калган. Якын итеп сөйләшеп, башымнан сыйпап, итәгендә утыртып көлдергәннәре истә әле.”

Ә Кәшаф ага Хаммадов үзенең истәлекләр дәфтәренә мондый юллар теркәп куйган: “Мансур безнең Крымов бабай тәрбиясендә үсте. Укыган чакта Кәримов фамилиясендә йөреп, соңыннан Крымовка алыштырды. Мин аның беренче яза башлаган вакытын хәтерлим. Ул миңа үзенең язган шигырьләрен күрсәтә, әмма анда шигърият юк иде. Һәрвакытта да үз өстендә эшләгәнлектән, язган шигырьләре һаман камилләшә барды. Без Крыймов белән җәй көне урманнарга һәм балык тоту өчен Зөягә бара идек. Ул русчадан үзе тәрҗемә иткән “Кирәшчики”не җырларга ярата иде. Мин ул дәвердә фольклор әсәрләре язу белән шөгыльләндем. Мәсәлән, “Албасты”, “Яшен” исемле мин язган һәм матбугатка чыккан әсәрләрне Мансур бик яратып укый иде. “Албасты”ны хәтта күңелдән сөйләде. Шулай да, ул фольклор әсәрләр язу белән шөгыльләнмәде. Мансур тормышка оптимистларча караучы,

һәрвакыт шат күңелле, мәзәк сөйләргә яратучан кеше иде. Мансур, апасы гармун алып кайтып биргәч, бер дә төлке тотканнан ким булмады: бик шатланды. Мансурда музыкага да талант бар иде. Бер – ике ай эчендә тальянкада татарның милли, моңлы көйләрен башкарырга өйрәнде.” Аңа багышлап “Яшә Кәшаф”исемле шигырен иҗат иткән.

**Яшә Кәшаф!**

Кәшаф дустым син бәләкәй идең,
Бураш суын бергә эчкәндә,
Такыялы тауның аланында
Җир җиләге җыеп үскәндә,
Дубәлдәшта алмын бодайларның
Караганда бөдрә балетын,
Без яшь идек, кем уйлаган иде
Карарбыз дип метрополитин.
Мин рәсемеңне күрдем газетада,
Батырларча төшкән ул рәсем.
Беркөнне алган Буденныйдан,
Син дә батыр булып күренәсең.
Бүген кичтә уйлар экраныннан
Бергә булган һәрбер истәлек
Мин сагынам Зиннәт нанымнарны,
Гарифларны бүген искә алып.
Алтын яшьлек Бураш кырларында
Бергә үткәнгәдер күрәсең.
Мин аларның бүген барысын да
Батыр итеп килә күрәсем.
Син беләсең мине, җырлар язам
Кирәгеннән артык калышмыйм.
Ударник син метрополитиндә
Җырларым да сиңа багышлыйм.

Музей материалларыннан да бер истәлек тәкъдим итәм:

“1918 нче елда Казанда татар - башкорт хәрби мәктәбен тәмамлый. Гражданнар сугышында политрук булып эшли. Казанны саклаганда, Мулланур Вахитов полкында хезмәт итә. Шигырьләрен үзе җыеп, үзе бастыра. Шул елларда Казанга “Татарстан” газетасына бастыру өчен шигырьләрен җибәрә. Шулай ук Уфага да җибәргәли. Театр эшләренә актив катнаша. Сәхнәдә кую өчен әсәрләр яза. 23 брошюрасы чыга. Шулар 4 том итеп бастырыла.

Мәҗит Гафури белән Башкортсанда курортта була. Башкорт эшчеләре тормышы белән таныша. Донбасста, Магнитогорскида, Надеженда, Свердловск, Уфада туристик командировкаларда була. Эшчеләр арасында таныла, аның шигырьләрен яратып укыйлар. Мансур Крыймов пролетар шагыйрь дигән исем ала. Композитор Александр Ключарев белән Магнитагорскида 2 айлык туристлык командировкасында була. Мәскәү язучылар союзында торган.

1933, 1934, 1937 нче елларда туган авылы Чури - Бурашка кайтып киткән. Бу вакытта язган шигырьләрен Апас районында чыга торган “Таң” газетасында бастырган. Үзенең шигырьләрен авыл сәхнәсендә укый. Авылдашлары шат күңелле, мәзәкчән Мансурны һаман искә алалар. (Мансур Крыймовның тормышы авылдашлары Газиев Миңнулла, Гыйсмәтуллин Мотыйк һәм апасы Хәят истәлекләреннән файдаланып язылды.)

**Мансур Крымов шигырьләренең халык телендә калган өзекләре.**

Әчкелтем җил - кышның хәбәрчесе
Агачларның башын идерде.
Кыш килде дә, ипләп танышкач та,
Башларыма бүрек кидерде.
Нигә соң син алай шаярасың,
Якалардан карлар кертәсең.

Нигә соң син,чалбар балакларыма
кысылып,
Тәннәремне зәһәр чеметәсен.
Ә мин инде күптән бөрешкәнмен.
(Чури-Бураш.Сиражов Низамнан язып алынды)
.......................................................................
Серле күзле кебек күлләрең дә,
Шадраланды матур йөзләре,
Төн төренде болын юрганына.
Җемелдәми төннең күзләре.
Менә тиздән...
Төңге рәссам -кырау
Тәрәзәгә гөлләр бизәкләр.
Шуннан үрнәк алып
Рәсем ясар
Нәфисәләр, нәни Гыйззәтләр.
(Чури- Бураш. Айсин Гобәйдә сакланган)
Яратам ла туган авылымның
Салкын чишмә, такыя тауларын.
Җырларыма кушып, кушып җырлыйм
Сөзәк җыпкы,Граньстауларын.
Чури - Бураш авылы гражданы Шәфигуллин Хәертдин дәфтәреннән язып алынган истәлек.

**Йомгаклау**

Апас районы – күпләр өчен бик кадерле як. Мин дә бу төбәктә яшим һәм үземнең әлеге язмам белән якташым, авылдашым Мансур ага Крыймовның эшчәнлеген яктыртырга омтылдым. Аның иҗаты белән уртаклашасым килде. Шигъриятебезгә, халкыбызга мондый җаннар бик кирәк. Алар милләтебез рухиятенең сагында торалар, олы әдәбият белән халык, укучы арасында илче вазифасын үтиләр..
Апас төбәге үстергән, иңнәренә очар канат куеп, ил киңлекләренә озатучы минем кебек күп яшьләр Татарстан, Россия тарихында зур роль уйнар дип ышанам.

**Кулланылган әдәбият**

Г. Сәйдәш “Иманлы гомерем юллары”, Казан, 2008 ел
“Йолдыз”, “Таң” газетасы материаллары
Мансур Крыймов “Шигырьләр һәм поэмалар”, 1961 ел
Музей материаллары
Чури – Бураш авылы кешеләреннән язып алынган истәлекләр

## Мини - сочинение
## «Я снова здесь, в краю родном»

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение*
*«Набережно-Морквашская средняя общеобразовательная школа»*
*Верхнеуслонский муниципальный район*
*Республика Татарстан*
*Выполнила ученица 8 класса Низамиева Айсылу Рамисовна*
*Руководитель: Григорьева Гульфия Акрамовна,*
*учитель начальных классов*

Тянут нас к себе родные
Детства нашего места,
Как обители святые,
Если в душах пустота.
Манят ягоды лесные

И медовый запах трав,
Деревень огни ночные,
Палисадники в цветах…
В. Гужев.

Это стихотворение В.Гужева о деревне Кызыл Байрак я недавно прочитала в группе «Кызыл Байрак», в контакте, которая специально создана для тех, кто когда-нибудь был в этом прекрасном месте. Село Кызыл Байрак ( Красное знамя) находится в Верхнеуслонском районе Республики Татарстан. Расположено оно на берегу реки Волга, на высоком яру под вековыми соснами. Это место изумительно красивое, тихое и умиротворённое.

Ежегодно в летние каникулы я приезжаю туда к своей бабушке Мадина апа. Село Кызыл Байрак известно тем, что там ежегодно проводится день памяти композитора и музыканта Салиха Сайдашева. Кызыл Байрак называют второй родиной Салиха Сайдашева. На поляне красивого берега Волги, недалеко от мечети, стоит памятник великому композитору в виде огромного мраморного камня-монолита. Сюда Салих Сайдашев приезжал постоянно в поисках вдохновения, отдыха. Здесь он написал и свое знаменитое произведение - «Марш Советской Армии».

К празднику «Путешествие в Сайдашстан», который проводится ежегодно в Кызыл Байраке, местные жители готовятся очень тщательно: убирают дворы, красят заборы, приводят в порядок палисадники. Музыка Сайдашева близка и дорога не только татарскому народу, но и другим народам, вот почему на праздник в Кызыл Байраке собираются люди разных национальностей. Я каждый год посещаю этот праздник, не стал исключением и нынешний. Количество участников праздника увеличилось, и он получился насыщенным и интересным. В этом году организаторы праздника связали творчество Салиха Сайдаша с творчеством Габдуллы Тукая. Неоднократно со сцены говорили, что «если Габдулла Тукай - классик татарской литературы, то Салих Сайдашев – классик татарской музыки». На концерте звучали стихи Г. Тукая, музыка композиторов Сары Садыковой, Рустама Яхина. Салих Сайдашев написал музыку к 60 спектаклям, поэтому выступления артистов театра имени Г. Камала оставляют неизгладимое впечатление, особенно для бабушек и дедушек села. Сама я люблю петь, и когда на сцене выступают известные исполнители песен Искандер Биктагиров, Эмиль Замалетдинов, Хамдуна Тимергалиева, с удовольствием подпеваю им.

Каждый год Кызыл Байрак становится местом общения любителей музыки нашего великого композитора Салиха Сайдашева. Проходит праздник в удивительно теплой, дружественной обстановке. Вот уже и солнце практически скрылось за горизонт, раскрашивая последними лучами воду, деревья в красный и желтый цвета, но музыка Салиха Сайдашева все еще звучит в этой прекрасной тишине над гладью реки Волга, как будто сам великий татарский композитор обращается к нам: «Я снова здесь, в родном краю…».

## « Близко к сердцу» (о Ренате Сулеймановиче Акчурине )

*Муниципальное образовательное учреждение «Основная общеобразовательная школа №17 Зеленодольского района Республики Татарстан»*

*Выполнила: ученица 8 класса Баймяшкина Анна Алексеевна*

*Руководитель: учитель татарского языка и литературы Миндибаева З.Т.*

**Глава 1. Страницы биографии Рената Сулеймановича Акчурина**

Ренат Сулейманович Акчурин (род. 2 апреля 1946, Андижан) — советский и российский кардиохирург, академик Российской академии медицинских наук (РАМН) (1997) и Российской академии наук (2011), академик Академии наук Республики Башкортостан (1997), почётный член Академии наук Республики Татарстан (1998), руководитель отдела сердечно-сосудистой хирургии Института клинической кардиологии имени А. Л. Мясникова Российского кардиологического научно-производственного центра РАМН, руководитель государственной программы развития медицины высоких технологий с 1998 года. **Академик Российской академии медицинских наук, доктор медицинских наук, профессор, лауреат Государственной премии СССР.**

Родился 2 апреля 1946 года в городе Андижане Узекской ССР, в семье педагогов. Отец - Акчурин Сулейман Сафиевич (1909 г. рожд.). Мать - Акчурина Тазкира Киямовна (1912 г. рожд.). Супруга - Акчурина Наталья Павловна (1946 г. рожд.), работает в НИИ глазных болезней имени Гельмгольца. Сыновья: Максим Ренатович (1973 г. рожд.), Андрей Ренатович (1978 г. рожд.).

В 1964 году Р.С. Акчурин окончил среднюю школу № 1 в городе Андижане и поступил в Андижанский медицинский институт. В 1968 году он перевелся в 1-й Московский медицинский институт имени И.М. Сеченова. В 1970 году в составе студенческого медицинского отряда участвовал в ликвидации последствий землетрясения в Перу.

После окончания института с августа 1971 по сентябрь 1972 года работал участковым врачом-терапевтом в Реутовской городской больнице Московской области, после чего был переведен на должность врача-травматолога, проработав в ней до сентября 1973 года. По совместительству работал хирургом в 70-й больнице города Москвы и травматологом в Балашихинской районной больнице.

В 1973 году Ренат Акчурин был зачислен в клиническую ординатуру по хирургии Всесоюзного научно-исследовательского института клинической и экспериментальной хирургии Минздрава СССР, которым руководил академик Б.В. Петровский. В марте 1975 года после ее окончания его приняли на должность младшего научного сотрудника в отдел микрососудистой хирургии ВНЦХ АМН СССР. В 1978 году он защитил кандидатскую диссертацию на тему "Организация и показания к микрохирургической реплантации пальцев" и был переведен на должность старшего научного сотрудника отделения микрохирургии сосудов.

В 1984 году по предложению Е.И. Чазова Ренат Акчурин стал специализироваться в области кардиохирургии и был направлен на стажировку в клинику известного американского хирурга Майкла Дебейки (Хьюстон, США). После возвращения его назначили руководителем отдела сердечно-сосудистой хирургии Института клинической кардиологии имени А.Л. Мясникова Российского кардиологического научно-производственного центра РАМН. В этом качестве Р.С. Акчурин работает по сей день.

Известен как авторитетный специалист, развивший уникальные направления в восстановительной, сосудистой и кардиохирургии. Работает над такими направлениями, как реконструктивная и пластическая микрохирургия, реконструктивная и пластическая хирургия конечностей, реконструктивная микрохирургия коронарных артерий, хирургическое лечение ишемической болезни сердца, хирургическое лечение нарушений ритма, защита миокарда, лазерная ангиопластика, вопросы трансплантации сердца и комплекса сердце-легкие. Стал соавтором первых в стране операций по реплантации пальцев, пересадке пальцев стопы на кисть, сложносоставных пластических операций по восстановлению беспалой кисти и др.

В ноябре 1996 года выполнил операцию коронарного шунтирования сердца первому президенту РФ Б. Н. Ельцину.

В 2012 году избран членом Общественной палаты Центрального федерального округа.

Автор более 300 научных публикаций. является инициатором и одним из основных разработчиков Федеральной программы «Медицина высоких технологий». Избран членом совета директоров Международного хирургического общества имени М.Дебейки (1995), членом научного совета Всемирного общества ангиологов (1994), членом президиума Российского общества по сердечно-сосудистой хирургии (1994), членом Европейского общества сердечно-сосудистой хирургии (2000), членом Попечительского совета Государственного академического Малого театра России.

Женат. У него двое сыновей: Максим Ренатович (1973 г. рожд.) и Андрей Ренатович (1978г.).

Р.С. Акчурин является соавтором первых в стране операций по реплантации пальцев, пересадке пальцев стопы на кисть, сложносоставных пластических операций по восстановлению беспалой кисти, пересадке кожно-мышечных лоскутов взамен мышечных и кожных дефектов шеи, предплечья, нижних конечностей. В 1982 году за работу по реплантации пальцев и кисти с микрохирургической техникой ему была присуждена Государственная премия СССР. Работая в Кардиоцентре, он впервые в Европе внедрил операционный микроскоп и микрохирургическую технику в коронарную хирургию, микрохирургические операции на ветвях почечных артерий, позвоночных артериях.

В Кардиологическом научно-производственном центре профессор Р.С. Акчурин возглавляет работы по теме "Реконструктивная микрохирургия коронарных артерий". Он разработал в

эксперименте и клинике основные принципы коронарной микрохирургии и обосновал необходимость их внедрения в широкую медицинскую практику. Под его непосредственным руководством выполнялись все научно-технические исследования по основным и смежным проблемам данной работы. Впервые в стране он создал школу отечественной коронарной микрохирургии и обучил многих ведущих специалистов. Неслучайно в 1995 году именно он был назначен руководителем бригады хирургов, успешно прооперировавших Президента РФ Б.Н. Ельцина.

Высокую оперативную активность (6-8 операций в неделю на открытом сердце) Р.С. Акчурин успешно сочетает с преподавательской и научной деятельностью. Им подготовлено 6 докторов и более 20 кандидатов медицинских наук в области кардиологии и сердечно-сосудистой хирургии.

Р.С. Акчурин - автор более 300 публикаций по различным вопросам современной медицины (физиология и патофизиология, экспериментальные модели, микрохирургия сосудов, пластическая и реконструктивная хирургия, анестезиология и реанимация, кардиология). Он является инициатором и одним из основных разработчиков Федеральной программы "Медицина высоких технологий", которая была всесторонне изучена и обработана большинством ведущих научных и лечебных учреждений как Минздрава России, так и Российской академии медицинских наук.

Фактом широкого признания выдающихся заслуг профессора Р.С. Акчурина является его избрание действительным членом Российской академии медицинских наук, а также членом совета директоров Международного хирургического общества имени М. Дебейки (1995), членом научного совета Всемирного общества ангиологов (1994), членом президиума Российского общества по сердечно-сосудистой хирургии (1994), членом Европейского общества сердечно-сосудистой хирургии (2000).

Р.С. Акчурин награжден орденом Почета (1996), орденом Командора (Перу, 2000), а также орденом Орла III степени (1997) и международным орденом имени Пола Харриса неправительственной организации Rotary International (1998).

Ренат Сулейманович увлекается музыкой, спортом, охотой, рыбалкой, туризмом. Окончивший русскую школу, он свободно говорить на татарском языке и даже пишет. Для него важно, люди говорили на нескольких языках, понимали собеседника, были толерантными и успешными.

Живет и работает в Москве.

**Глава 2.Звание и награды**

Государственная премия СССР 1982 года в области науки и техники (28 октября 1982 года) — за разработку экстренных микрохирургических операций при травматических ампутациях пальцев и кисти.

Почётная грамота Правительства Российской Федерации (2 апреля 1996 года) — за большой личный вклад в развитие сердечно-сосудистой хирургии и в связи с 50-летием со дня рождения.

Орден Почёта (2 мая 1996 года) — за заслуги перед государством и многолетний добросовестный труд .

Орден Орла III степени (1997).

Международный орден имени Пола Харриса от неправительственной международной благотворительной организации Ротари Интернешнл (1998).

Командор ордена Заслуг (Перу, 1 июля 2000) .

Государственная премия Российской Федерации 2001 года в области науки и техники (5 августа 2002 года) — за работу «Хирургическое лечение сочетанных сердечно — сосудистых и онкологических заболеваний».

Премия Правительства Российской Федерации 2004 года в области науки и техники (2 мая 2005 года) — за за разработку, организацию производства и внедрение в медицинскую практику аппаратного вакуумного переносного комплекса для операций аортокоронарного шунтирования на работающем сердце «КОСМЕЯ».

Орден «За заслуги перед Республикой Татарстан» (2006 год) — за выдающиеся заслуги в области здравоохранения.

Заслуженный врач Республики Татарстан (2012 год) .

Орден Дружбы (31 марта 2016 года) — за достигнутые трудовые успехи, активную общественную деятельность и многолетнюю добросовестную работу.

Орден «За заслуги перед Кабардино-Балкарской Республикой» (31 марта 2016 года) — за большой личный вклад в развитие здравоохранения Кабардино-Балкарской Республики .
Почетная грамота Российской академии наук (2016) .

**Глава 3. Документальный фильм «Близко к сердцу»**

С 2011 года **Ренат Акчурин** возглавляет в Москве Клуб врачей, созданный при Полномочном представительстве Республики Татарстана. При поддержке Полномочного представительства РТ в РФ к 70-летию **Рената Акчурина** была издана книга об известном кардиохирурге и снят документальный фильм «Близко к сердцу»

Автор сценария фильма, руководитель проекта «Близко к сердцу» Фарида Курбангалеева и режиссер фильма Денис Красильников - уроженцы Казани. Они рассказали, что премьера картины состоялась 28 апреля в Москве , а им особенно приятно показать этот фильм в родном городе.

Фильм длится час. В нем собраны истории девяти пациентов, жизни которых в разные годы спас Ренат Акчурин. Каждая история действительно похожа на чудо. Съемочной группе удалось найти тех, кого врач прооперировал много лет назад. Эти люди живут не только в России, но и на Маврикии, в Перу, Израиле, США. Своего доктора везде помнят и любят. На Маврикии даже есть авеню, которое носит имя профессора Рената Акчурина.

Кстати, самая долгая операция, которую провел Ренат Акчурин, длилась 22 часа. Солдат-строитель из Каракалпакии попал под поезд и лишился кистей обеих рук. Ренат Сулейманович вместе с бригадой врачей руки парню пришил. После операции руки и пальцы у пациента работали нормально.

Талантливому режиссеру, сценаристу, продюсеру, оператору удалось за час показать то, что произошло за 30 лет. А что касается того, что здесь было показано, действительно все так и было. Это не чудеса. Это наша работа. Врач не может отвернуться от людей, он должен быть на острие проблемы, сочувствовать каждому пациенту независимо от его социального статуса, - сказал Ренат Акчурин . Судьбу каждого пациента Ренат Акчурин принимает близко к сердцу, и сам становится близким и родным человеком для спасенных людей.

В фильме принимают участие: летчик-космонавт Александр Александров, вдова первого президента РФ Наина Ельцина и другие.

Понятно, что такой проект не мог осуществиться без поддержки Президента Татарстана. По словам Минтимера Шаймиева, ему очень понравилось название фильма – «Близко к сердцу». «Оно заставляет задуматься. Ренат Акчурин близок нашему сердцу, и картина тоже. Создатели фильма, вы смогли до нас достучаться, это великое мастерство. Такие вещи нужно делать. И вам это удалось», – сказал он.

Бывший министр здравоохранения РТ Адель Вафин подчеркнул, что «Ренат Акчурин является автором словосочетания «медицина высоких технологий». «Благодаря поддержке Президента Татарстана, первого Президента республики модернизация в сфере здравоохранения у нас достигла таких масштабов, что высокотехнологичная медпомощь стала доступной. Наши коллеги из других регионов признают, что преимущество Татарстана – в доступности высоких медицинских технологий», – отметил он.

Как рассказал министр, ежегодно более 20 тыс. жителей РТ бесплатно получают высокотехнологичную медицинскую помощь. За 10 лет проведено 13 тыс. операций с использованием аппарата искусственного кровообращения. «Это наше конкурентное преимущество, которое создано благодаря непосредственной поддержке и при участии академика Акчурина», – сказал он. «Сегодня можно говорить о том, что школа Акчурина есть в Татарстане, и она спасает десятки тысяч жизней. Мы имеем эффективную модель здравоохранения. Несмотря на сложную экономическую ситуацию, можно утверждать, что модернизация здравоохранения РТ продолжается, у нас много талантливых учеников, известных хирургов, и мы с уверенностью смотрим в будущее», – заключил Адель Вафин. Ренат Сулейманович десятки лет поддерживает тесные рабочие связи с Татарстаном. На Медико-инструментальном заводе республики совместными усилиями даже разработали и сделали набор для коронарной хирургии. Он так и называется – «Набор Акчурина» .

Заключение

Когда я решила писать, то ни минуты не сомневалась, что буду рассказывать о Ренате Акчурине. Я убедилась в том, что это человек интересной судьбы, о его жизни и трудовой деятельности должно

знать не только старшее поколение, но и младшее. А ещё это и разносторонняя личность, интересный собеседник, талантливый человек.

Проведенная исследовательская работа позволяет сделать ряд **выводов:**

1.Ренат Акчурин явился для меня ярким примером того, как можно достичь успеха в любой деятельности, опираясь на свои силы и возможности. В результате исследовательской работы я пришла к закономерному выводу: главное ставить цель, а для её осуществления необходимо упорно учиться и самосовершенствоваться.

Однажды ,когда я просматривала статью про Р.С.Акчурина ,то мне понравилось одно из его высказываний :

*«Как-то на вопрос, "что такое врач, каким он должен быть?", Ренат Сулейманович ответил: "Врач - это, прежде всего, сострадалец". Именно так и никак иначе: у человека боль, человеку плохо, значит, ему требуется помощь и сострадание.»*

Если бы каждый врач думал так как Р.С.Акчурин , то в нашем мире стало бы меньше болезней и бед.

Я считаю, что Ренат Акчурин - это Человек с большой буквы. Россия держится на таких людях!

**Использованная литература**

**Интернет ресурсы**

Документальный фильм «Близко к сердцу » Фарида Курбангалеева и режиссер фильма Денис Красильников .

И.К.Комаров «Ренат Сулейманович Акчурин»

Р.У.Акчурин «Из истории рода Акчуриных»

## “ Ренат Харис- тынычлык җырчысы”

*МГББУ “Татарстан Республикасы Буа шәһәре 1 нче номерлы урта гомуми белем мәктәбе”*

*Эшне башкарды: 8 нче сыйныф укучысы Камалеева К.Р.*

*Җитәкче: югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*Хәйретдинова Фәүзия Зариф кызы*

Кереш өлеш

Сез тыңлагыз безне- яшәтегез,
Истәлектән тартып чыгарып.
Мәктәпләргә безне чакыралар.
Җыр җырлыйлар безгә багышлап.

**Р.Харис**

Сугыш! Никадәр кайгы- хәсрәт, югалту, бәхетсезлек китердең син тынычлык халкына. Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Юк, җиңел бирелмәде безгә тынычлык, шуңа күрә дә без аның кадерен беләбез.

Безнең халкыбыз бәхетне туган иленнән, тынычлыктан башка күз алдына да китерми.Сабыйлар күз яше тамган, кешеләрнең канына буялган, аналарның йөрәгенә сагыш- хәсрәт салган, ятимнәрнең бәхетсез язмышлары бәрабәренә яулап алынган байлык, муллык, алтын- көмеш кызыктырмый безне.

Мин дә үземнең эшемдә бүген Ренат Харисның дәүләт эшлеклесе буларак сугышларга мөнәсәбәтен тикшерүне төп максатым итеп алдым. Аның “Кешене мәшәкать йөртә”, “Грозный, 1998 ел”, “Шөкер”, “Җиңүче”, “Бүре күзе” шигырь һәм поэмаларын анализлау , Р.Харисның чын сәясәтче, дәүләт эшлеклесе булуын исбатлау бурычын куйдым.

**Төп өлеш**

Чыннан да, берничә чакырылыш халык депутаты, 1995-1999 елларда Дәүләт Советы Рәисе урынбасары булган чорда Р. М. Харисовның, чын мәгънәсендә дәүләти шәхес буларак, халкыбыз өчен мөһим булган күп кенә мәсъәләләрне хәл итүдә ясаган адымнары бихисап булды.

“Татарстан Республикасы – республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын чагылдыручы суверен демократик дәүләт. Ә дүртенче матдә татар һәм рус телләрен тигез хокуклы дәүләт телләре буларак игълан итте. Төп канунның башка барлык гыйбарәләре әлеге ике матдәдә баян ителгәннәр

белән сугарылды. Бу очракта комиссия әгъзасы Ренат Харис улының әлеге мәсьәләләргә булган тирән уйланылган һәм үзе нык инанган карашларын кирәкле урында һәм нәкъ менә таләп ителгән мизгелләрдә әйтә белүе дә үзләренең кирәкле ролен уйнаганлыгын гадел икърар итәргә кирәк»,- дип язды филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Хисамов.

Татарстан Республикасының дәүләтчелеген торгызуга Р. Харис керткән тагын бер саллы өлеш турында искә төшереп китү зарур. Республика парламенты аңа Татарстанның дәүләт символлары буенча эшче төркемне җитәкләү кебек гаять мөһим һәм җаваплы эшне тапшырды. Дөресен әйткәндә, бу – бик тә дөрес сайлап алынган, шушы эшне тиешенчә башкарып чыгарга сәләте булган иң лаеклы депутат иде. Дәүләт символларын дөрес формалаштыру өчен халыкның тарихын, рухын, ерактагы традицияләрен, бигрәк тә киләчәген шактый ачык күз алдына китерү мөһим. Шуннан башка халыкны канәгатьләндерерлек, аның күңелен яуларлык, алар белән горурланырлык дәүләт символларын булдыру мөмкин түгел. Чөнки бу символлар сәясилек белән хиссилекнең ныклы кушылмасын тәшкил итәргә тиеш. Менә ни өчен бу очракта да Р. Харис әлеге миссияне үтәүгә аеруча җаваплы мөнәсәбәт күрсәтте. Кыска гына вакыт эчендә бик күп тарихи мәгълүматларны барлады, бу өлкәдәге дөнья тәҗрибәсен өйрәнде, галимнәр, бигрәк тә тарихчылар һәм әдәбиятчылар белән кабат-кабат очрашты.

Нәтиҗәдә, азмы-күпме чигенүләргә дә барып, әмма төп карашларга әлләни зыян китермичә, Татарстан Дәүләт флагы, Дәүләт гербы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимны кабул ителә. Әлеге дәүләт символларының дөрес кабул ителгәнлекләрен тормыш үзе раслады. Аларны татарлар гына түгел, җөмһүриятебездә яшәүче башка халыклар да шулай булырга тиеш дип кабул иттеләр. Бу символлар белән халык горурлана, алар төрле рәсми мохитләрне бизи, билгеле бер тантаналы тирәлек тудыра.

Р. Яхин тарафыннан иҗат ителгән гимныбыз яшәешебезне матурлый. Әлеге
тантаналы музыка Татарстаннан тыш та байтак урыннарда һәм очракларда,
бигрәк тә төрле спорт чаралары вакытында яңгырый һәм һәрвакыт күңелләребездә горурлык хисләре уята.

Шагыйрь, дәүләт эшлеклесе буларак, сугышларга ничек карый соң? Берәр ничек үзенең мөнәсәбәтен белдерәме аңа карата? Ни өчен мине бу сорау борчыды соң? Бәлки иремнең Әфган сугышында катнашуыдыр, ә бәлки күптән түгел Чечня канкоешында үлеп калган элеккеге укучыбыз Юнысов Айрат этәргәндер.

Планета температурасын сугышлар күтәрәме, әллә канкоешлар җир температурасы күтәрелгән урында башланамы? Мөгаен, икесе дә дөрестер... Әмма бу мөһим түгел. Иң мөһиме – “кайнар нокта”ларның ничек һәм ни өчен барлыкка килүе, температураның күтәрелү сәбәбе нидә булу. Болар кем эше? Әмма тагын да мөһимрәк нәрсә – температураны ничек төшерергә соң?

Эзләнә торгач, Ренат Харисның “ Хәл- әхвәл” тупланмасындагы “Грозный, 1998” шигыренә тап булдым:

Сугышларны минем күргәнем юк.<br>
Күп күрдем мин ләкин эзләрен<br>
Үз илемдә, ерак Европада...<br>
Бүген менә сугыш күзләре<br>
Күзләремә минем карап тора<br>
Чечен өйләреннән сызланып...

Ренат Харис “ Шөкер” поэмасында да үзенең сугышка карата кискен мөнәсәбәтен, кешеләрнең тыныч тормыш яшәргә теләүләрен белдерә:

Үлемнән дә һәрберебез курка.<br>
Шуңа килә яшәп каласы.<br>
Матур итеп бер үтмәкче кеше<br>
Кендек белән кабер арасын

Мәгълүм булганча, “Илиада”, “Слово о полку Игореве” яки “Идегәй” дастаны чорыннан бирле әдәбият кешелек яшәешенең иң четерекле бу мәсьәләләрен йөзләрчә мең тапкыр төшенергә азапланды. Асылда, бөтен дөнья әдәбиятының үсеш юлы күп очракта – ул сугыш һәм солых проблемаларын аңларга тырышу юлы, һәм әлеге процесста халыкларның иң олуг талантлары катнаша һәм шуның нәтиҗәсендә Лев Толстой, Михаил Шолохов, Эрнест Хемингуэй, Анри Барбюс, Иван Вазов, Алексей

Толстой, Ярослав Гашек һәм башка күп шәхесләр кебек, кешелекнең бөек акыл иясенә әйләнә. Ни өчен алар шул дәрәҗәгә күтәрелгән соң? Барысына да өстәп, тагын шунысы өчен дә – аларның әсәрләре кешелеккә һәм дөньяның көч-куәт ияләренә искәртү, кисәтү булганга да, глобаль акылсызлыклар эшләүдән тыйганга да.
Барлык дәвер һәм халыкларның сугышлар турындагы бөек әсәрләре бүген дә: "Акылга килегез!" – дип чаң суга. Әмма без аларны ишетәбезме соң? Әллә ишетмибезме?.. Хәзерге планета масштабындагы сәяси амбицияләрнең колагы юктыр шикелле, булган очракта да, һәрвакыттагыча, алар затлы металл яңгыравыннан башка бернәрсәне дә ишетмидер... Нәтиҗәдә исә: кичә – бөтендөнья сугышлары, революцияләр, төрле дәүләтләрдә гражданнар сугышлары, Кавказ сугышлары (кайчандыр аларда Лермонтов та, Толстой да катнашкан), ә бүген – Әфганстан, Балкан, Гыйрак, Абхазия, Көньяк Осетия һәм, әлбәттә инде, Чечня, аларда безнең балалар, туганнар, дуслар катнаша...

"Кешене мәшәкать йөртә" шигырендә сугышның кешелексез булуына басым ясый шагыйрь:

Акланырга сүзләр эзләп йөдим.
Таммый ләкин телдән сүзләрем,
Яралы өй миннән эзләгәндә
Кешелеклелек хисе эзләрен...

Моңа бәйле рәвештә Р.Харис соңгы тапкыр Чечняга баруын искә төшерә: "Ике кампания арасындагы сугыш тынып торган чакта мин, Татарстан парламенты вице-спикеры буларак, Грозныйга эшлекле сәфәрем вакытында үземнең күптәнге танышымны – чечен язучысы Мөхәммәд Мусаевны табуда ярдәм итүләрен үтендем. Без аның белән хат алыша идек. Ул Казанда миндә кунак та булгалады, үзебезне дә гел кунакка чакырды. Тыныч вакытта һаман аның янына барып чыгып булмады. Аның иске адресы буенча Иваново тыкрыгындагы 4 нче йортны эзләп киттек. Анда Мөхәммәд Муса улы хатларында сурәтләнгәнчә бик матур йорт булырга тиеш иде, тик без аның урынында әллә бомба, әллә снаряд шартлаудан калган гаять зур чокыр гына күрдек... Әмма белгән кешеләр язучының исән калуын әйтте, ул тауларга киткән булган, аннары кире әйләнеп кайткан, диделәр. Чыннан да, шулай булып чыкты. Без аны икенче көнне могҗиза белән генә исән калган "хрущевка"дагы бер бүлмәле фатирда таптык. Ул ярымбуш фатирда, аягын сындырып, урын өстендә ята иде. Аның архивы, китаплары, басылмаган әсәрләренең кулъязмалары – барысы да янып көлгә әйләнгән." Шагыйрь "Бүре күзе" поэмасында нәкъ шул вакыйганы яктырта:

Чечен карты күзләренә чумдым-
Тау упкыны булса- түнтәрсен,
Диңгез булса, чоңгылына салып,
Күбегенә төреп күтәрсен.

Әмма бүген минем сүзем бу турыда түгел. Ә менә нәрсә турында: әсәрләре мәктәпләрдә өйрәнелгән 80 яшьлек фронтовик–язучы ул чакта ачынып болай дигән иде: "Алар Лев Николаевич Толстойның "Хаҗи Морат" повестен онытты микәнни? Әллә бөтенләй укымадылар микән?.." "Алар" дигәндә, ул илнең һәм Чечен Республикасының ул чактагы җитәкчеләрен күздә тота иде. Ә Мөхәммәд Мусаевның Лев Толстой повестеннан сөзеп алган төп идеясе мондыйрак: командующий Воронцовның эшлексезлеге һәм буш вәгъдәләре русларга Кавказ сугышын тизрәк төгәлләргә булышмакчы булган Хаҗи Моратның мәгънәсез үлеменә китерә. Мусаевның хәтеренә уелып калган тагын бер нәрсә – Хаҗи Моратның икесе дә ач калган ишәк һәм эт турында сөйләгән мәсәле: ишәк этне печән белән, ә эт ишәкне ит белән сыйлаган. Без ул чакта күпмилләтле, күпконфессияле Русиядә халыкларның теленә, гореф-гадәтләренә, тамырларына, мәдәниятенә хөрмәтнең һичшиксез зарурлыгы хакында, кешенең нәкъ менә шул югары кыйммәтләрне санга сукмавының конкрет территориядә вазгыятьне кискенләштерүе һәм амбициоз икътисади сәясәткә аны планетаның "кайнар нокта"сына әйләндерергә мөмкинлек бирүе хакында сөйләшәләр.

**Йомгаклау**

Йомгаклап әйткәндә, теләсә кайсы "кайнар нокта"ны да суытып була. Моның өчен кешелек тәҗрибәсе хәзинәсендә алым һәм ысуллар күп: хәрбиләре дә, сәясиләре дә, икътисадилары да җитәрлек. Кайчан да булса барыбер Балканда да, Гыйракта да, Көньяк Осетиядә дә, Днестр буенда да, Чечнядә дә тәртип урнаштырылачак – Конституция буенчамы, әллә башка юл беләнме, барысы да җайга салыначак, рәтләнәчәк. Әмма әлләни күзгә ташланмый торган бер проблема барыбер калачак –

ачу, үч белән йогышланган куркыныч, чирле хәтер. Нәкъ менә “кайнар нокта”ларда кеше хәтере (һәм халык хәтере дә дияргә җөрьәт итәм) шушы коточкыч бациллалар белән йогышлана. Кайвакыт ачу һәм үчлелек заманча террорчылык кебек явыз монстрга әверелә. Һәм, минем фикеремчә, нәкъ менә шул Төньяк Кавказдагы куркыныч яраның шулкадәр озак төзәлмәве сәбәпләреннән берсе булып тора.

Әйе, югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без Ренат Харисның чын дәүләт эшлеклесе һәм үз фикерен, үз сүзен кыю әйтүче сәясәтче, шагыйрь булуын күрәбез.

Ренат Харис шигырьләре – чынлап та тормыш күренешләренең олы мәгънәсен ачучы әсәрләр. Бу иҗат дөньясында фикер һәрвакыт тирәнгә, фәлсәфи катламнарга кереп китә, кешелек язмышы, җирдә тынычлык урнаштыру проблемаларына барып тоташа. Япь- яшь егетләребез хәрби хемәттән исән-имин әйләнеп кайтсыннар, аналары кайгы- хәсрәт күрмәсен. Ә Ренат Харис кебек шәхесләребез булганда киләчәгебез ышанычлы булыр дип уйлыйм, мин.

**Кулланылган әдәбият**

Дәүли Н. Ак янында кара. Әдәби тәнкыйть, публицистик мәкаләләр, очерклар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1974.

Фәйзуллин Р. Заманга иш иҗат. / Казан утлары. – 2001. №5. – 87-91б.

Харис Ренат. Тоткасыз ишек: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1999.

Харис Ренат. Хәл-әхвәл: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

Харис Ренат. Хисемнең исеме: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.

Хәсәнова Ф. Ренат Харис шигърияте. / Казан утлары. – 2000. №5. – 155-170б.

## Роль Зинатуллина Габдульхамита хазрата в воспитании подрастающего поколения нашего города

*МБОУ «Лицея №9 им.А.С.Пушкина ЗМР РТ»*

*Выполнила: Мухамедзянова Яна Эдуардовна ученица 10 Б класса*
*Руководитель: Габидуллина Дина Гаязтиновна,*
*Учитель татарского языка и литературы*

В этом году нашему городу исполняется **85** лет. Зеленодольск красив не только своей природой, различными заводами, инфраструктурой, но и людьми, прославившие свой город. Среди них мой герой- Зиннатуллин Габдульхамит хазрат.

Зиннатуллин Габдульхамит Рауфович родился 2 сентября 1954 года в г. Казань в многодетной татарской семье. Свои первые знания об исламе он получил от своего отца Рауфа Зиннатулловича, который тогда работал имамом в Азимовской мечети. Позднее Габдульхамид хазрат окончил известное медресе "Мир-Араб", был мусульманским преподавателем, имамом мечети, казыем (богословским судьей), региональным имамом-мухтасибом, в конце восьмидесятых годов возглавлял мусульман Татарстана. Сейчас Габдульхамид хазрат является членом Президиума Духовного управления мусульман Республики Татарстан и имамом-мухтасибом Зеленодольского района Татарстана.

Под его руководством в городе Зеленодольск работают три мечети, начальное медресе, летний мусульманский лагерь, благотворительный фонд. Дважды в месяц выходит мусульманская газета «Рассвет». В гимназии №5, школах №7 и №16 регулярно проходят занятия по мусульманской этике, в детских садах №21 и №23 работают специальные группы для детей из татарско-мусульманских семей. Ежегодно проходят благотворительные акции в помощь детским домам и домам престарелых.

Хазрат- частый гость нашей школы. Я считаю, что Габдульхамит хазрат, тот человек, который прославил свой народ, наш город. Поэтому, я решила сделать репортаж, показать, какой он разносторонний человек.

## Якташыбыз композитор Риф Гатауллин иҗаты

*Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы*
*Вахит тулы булмаган гомуми белем бирү учреждениесе*
*Эшне башкарды: 9 нче сыйныф укучысы*
*Гайфуллина Айсылу Илсур кызы*
*Җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Фәттахова Гөлназ Хәзби кызы*

**Төп өлеш**

Әйе, Югары Ослан ягы –Тау ягы үзенең матур табигате, күренекле шәхесләре белән данлыклы.

Туган як. Туган җир. Туган авыл. Йөрәккә якын һәм кадерле сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп аккан йөгерек чишмә буйлары, балыклы күлләр, куе әрәмәләр белән уратылган елга буйлары, туган ягыбызның кырлары, күңелләргә рәхәтлек биреп, туган илгә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли.

Кендек каны тамган изге җир. Әткәй-әнкәй, туганнар белән бергә гомер буе күңел түрендә торачак ул. Инде әткәй-әнкәйне кайгыртып, бер-бер яхшылык эшли алмасак та, без гомер буе туган як алдында бурычлы. Бер караганда, монда, шәһәрдә торып, туып-үскән төбәгебезгә нинди ярдәм күрсәтә алабыз инде?! Ныклап уйлап караганда, күрсәтә алабыз. Риф абый да күрсәтә. Ял, бәйрәм саен диярлек Югары Ослан районы Яңа Болгар авылында яшәүче әнисенең хәлен белергә кайта иде. (2016 нчы елда Әнисе Марзия апа бакый дөньяга күчте). Әнисенә багышлап, Госман Сәда сүзләренә “Укытучыма” һ.б. җырлар язуы тикмәгә түгелдер. Үзенең көләч йөзе, моңлы тавышы белән авылдашларын шатландыра, бәйрәм вакытларында, сабантуйларда сәхнәдән төшерми аны халык. Туган якның матурлыгы Риф абыйның җырларына да күчкән, шуңа күрә ул үзенең иң яхшы көйләрен туган якка багышлаган.

Гатауллин Риф Хоббул улы 1950 нче елның 25 нче февралендә Әтнә районында беренче бала булып дөньяга килсә дә, гомеренең күп өлешен Югары Ослан районы белән бәйли. Риф абый бала чактан ук бик шук һәм шаян була. Җитешмәгән җире, уйнамаган уены, эшләмәгән эше калмый. Җәен велосипедта йөрергә, кышын чаңгыда шуарга ярата. Әтисе һәр җәй саен улына бер велосипед алып бирергә мәҗбүр була. Авылдашларының бу чаклы да әрсез, тiктормас егеткә башта исләре китә. Клубта концертлар куйганда, оста итеп җырлаучы малайга озак итеп кул чабалар.

Әнисе бервакыт аңа гармун алып бирә. Бер-ике көн дә үтми, Риф абый гармунны икегә ярып ташлый. Әнисе: “Нигә алай эшләдең?”- дип сорагач: “Эчендәге кешеләрне күрәсем килде” , – дип җавап кайтарган.

Талантлы, энергиясе ташып торган егетнең авылда каласы киләме?.. Хыяллары аны калага дәшә. Ул Казан шәһәренә килә. Әтисе йогынтысы буенча Казанның химия-технология институтына укырга керә, чөнки әтисе гомер буе үзе механик булган, улын да инженер итәсе килә. Ләкин Риф абый институтта ел ярым гына укый. Әле студент вакытта ук аның сәләтен композитор Сара Садыкова күреп ала һәм үзе җитәкләгән “Чишмә” исемле вокаль-иструменталь ансамбленә килүен үтенә. Тиздән ул Казан шәһәрендә төрле фестивальләрдә катнаша башлый. Сара апа аңа: “Вакытыңны юкка исраф итмә”, - ди. Башта Риф абый музыка училищесына укырга керә. Аннан консерватория, вокал бүлеге. Берара җырчы булып йөри, аннары дәртле җырлар иҗат итә башлый.

Әнисе - Марзия апа – авыл укытучысы, гомеренең 34 елын балаларга белем бирүгә багышлады. Үз баласының тәрбияле булуын тели.

...Әнисе һәм авылдашлары әйткәнчә, көндәлек борчуларыннан аз гына арыну өчен, Риф Гатауллин Яңа Болгарга ашкына. Монда күңелле, саф һава... Ул кайтуга, өй артларындагы урманга юл тота. Күлмәк изүен ачып җибәрә, карашын еракка, бик еракка төбәп, тын гына әйләнә-тирәне күзәтә. Күңеленең кылдан нечкә тартылган андый минутларында ул сабый балага әйләнә. Йөгәнсез хыялына канат куя да, ашкынып, кабалана-кабалана, балачагы калган сукмакка йөгерә, үзе эченнән көйли-көйли өйгә йөгереп кайта да нота дәфтәрен алып көй язарга утыра. Шатлык та, кайгы да, сагыш та – барысы да кеше күңеленнән табигать кочагында түгелеп чыга бит.

Аның авыл табигатенә багышланган җырлары: Фәннур Сафин сүзләренә язылган “Безгә дөнья дәшә”, ”Без – Кояшның дуслары”, Рөстәм Ибраһимов сүзләренә "Минем серем", Фәнис Яруллин сүзләренә “Сөялдем сөяннәргә”, “Карауҗа авылы көе”, һ.б.

Риф абыйның һәр җырының үзенә генә хас аһәңе бар, аның һәр әсәре күңелнең нинди генә булса бер нечкә кылын чиертеп ала. Көйләрендә без шат күңелле яшьлек ашкынуларын да, юксыну, сагыну моңнарын да ишетәбез. Аның җырлары тыңлаучының күңелен күтәрә. Мәсәлән, Фәннүр Сафин сүзләренә язылган “Хушлашырга ашыкма!”, “Бир кулыңны”, ”Ялгыз көймә”, “Кал моңнарым булып”, “Безгә дөнья дәшә”, Мөдәррис Әгъләм сүзләренә “Серле йөрәк” , Г. Шакиров сүзләренә “Гармун алыйк әле, дуслар”, Н. Тукмачев сүзләренә “Торналар”, Э. Шарифуллина сүзләренә “Бергә чакларда”, Гөлшат Зәйнәшева сүзләренә “Вакытлыча түгел”, Равил Фәйзуллин сүзләренә “Нигә шулай?”, Ә.Зарипов сүзләренә “Ялгыз калып кара”, Ләйлә Дәүләтова сүзләренә “Гашыйк буласым килә” җырлары һ.б.

Күпләр Риф абыйны атаклы композитор буларак кына түгел, ә бик игътибарлы, тыйнак, ачык күңелле кеше булганга да хөрмәт итәләр.

Күбрәк композитор Риф Гатауллин шагыйрь Фәннүр Сафин, Равил Фәйзуллин, шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева, Эльмира Шәрифуллина һ.б. сүзләренә музыкалар иҗат итә.

Балалар өчен язылган җырларга килгәндә, Муса Җәлил, Бари Рәхмәт, Шәүкәт Галиев, Роберт Миннуллин, Габдулла Тукай иҗатларына өстенлек бирә. Композитор буларак, ул сабыйларга нинди әсәрләр кирәклеген, аларның эчке дөньясын, башкару мөмкинлекләрен дә яхшы белә. Габдулла Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигыренә, Роберт Миннуллинның “Өлкәннәр”, Күңелле тәнәфес” шигыренә, Эльмира Шәрифуллинаның “Җырланмаган җырым” шигыренә һ.б. музыка язган.

Сара апа оештырган хорга йөреп иҗади яктан рухланган Риф Гатауллин 1992 нче елларда Халык иҗаты һәм агарту эшләре буенча фәнни-методик үзәк каршында һәвәскәр композиторлар оешмасын оештыра, шулай ук 2002 нче елларда “Һәвәскәр композиторлар антологиясе”н төзеп чыга.

Соңгы елларда үткәрелгән “Дуслык моңы” , “Яшьләр дулкыны” һ.б. фестивальләрдә, җыр конкурсларында Риф Гатауллин жюри составында тора, хәйрия концертлары куеп йөри.

Күптән түгел композитор Риф Гатауллин җитәкчелендә “Пар алма” дигән җырлар җыентыгы дөнья күрде. Монда “Пар алма” җыры композитор Зөфәр Хәйретдиновның хәзерге көндә иң яратып җырлана торган җыр икәнлеге расланган. Шулай ук бу җыентыкта башка җырлар да урын алган.

Тиздән Риф Гатауллин җитәкчелегендә төзелгән һәвәскәр композиторларга багышланган китап чыгачак, анда 200 һәвәскәр иҗатчы, алар турында бай мәгълүмат тупланган.

**Йомгаклау**

Риф Хоббул улы иҗат уты белән янганда, дан турында да, мал турында да уйламый. Әйе, иҗатчы җырчымы ул, композитормы – иң беренче нәүбәттә кешеләр йөрәгенә иман, игелеклелек орлыклары салырга тиеш. Сәнгатьнең теләсә кайсы төренең иң югары күрсәткече – халык күңеленә юл таба алу. Мондый сәләткә ия кешеләр сирәк очраса да, нәкъ менә алар мәдәниятебезнең, җәмгыятебезнең яшәешен һәм үсешен билгели, халыкның рухи хәзинәсен баета. Тормышның һәр мизгелен, табигатьнең серле яшәешен, кешеләр күңелен нечкә йөрәгең аша үткәреп музыка телендә әйтә алу - ул зур бәхеттер. Композиторның кайсы гына җырын алма, алар табигыйлеге, аһәңле һәм моңлы булуы белән аерылып тора. Үзенә карата артык таләпчән, максатына ирешү өчен өзлексез иҗат утында янып, үзе сайлаган сәнгать юлында баручы тынгысыз кеше ул Риф Гатауллин.

Композитор Риф абый белән очрашканнан соң, әйткән сүзләре әле дә хәтеремдә саклана: “Әйе, гүзәл дә соң минем туган җирем! Чит илләрдән матурлык эзлисе дә түгел, ул үзебездә – Югары Осланыбызда. Урманнарда йөреп күңелгә рәхәтлек аласың, саф сулы чишмәләрдән салкын су эчеп сусауны басасың. Шуңа да кая гына барсам да, Яңа Болгар авылын сагынып кайтам. Дөньяда матур җирләр күп, әмма туган яктан да кадерлерәге юктыр. Ходай туган җирдән аермасын”, - дигән иде.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: һәркем үз язмышын үзе яза. Тәкъдирдә язылганны көтеп ятсаң, ихтимал, бәхет үзе сине эзләп килеп җитә алмас. Яшәү кыйбласын, тормышын сәнгать дөньясы белән аерылгысыз дип исәплидер Риф абый Гатауллин да. Аның өчен бәхет – җыр-музыка, газиз халкыңа хезмәт итү. Риф абый – чын мәгънәсендә милләтебезнең күренекле шәхесе, атаклы композиторы. Ял көннәрендә әнисе йортына кайту, эш вакытында Казан җирлегендә яшәп, шунда иҗат итеп, безне искиткеч моңлы җырлар белән сөендерә алуы – безнең өчен чиксез горурлык!

**Эзләнү чыганаклары**

1. Гатауллин Риф - Композиторы Татарстана. – М.: “Композитор”. – 2009, 70 – 71 нче битләр.
2. “Җырлап ачыла күңел” җыентыгы, 1996 нчы ел.
3. “Җыр бишеге янында”- Казан утлары журналы, 1980, №12
4. “Миңа көндәшлек хисе ят”- “Ватаным Татарстан” газетасы, 2010,  №47.
5. “Мәхәббәт сагыштан тора ул”-Шәһри  Казан, 2014, 15.03.
6. Риф Гатауллинның  гаилә архивыннан фотолар, аудиокассета, шагыйрьнең автобиографиясе.
7. Район газетасы “Волжская новь”. -2010, №68.
8. “Хәтер төпләрендә утлы күмер”- Казан утлары журналы, 2014, №1.

# СЕЛО АГЗЕГИТОВО В ИСТОРИИ СТАНОВЛЕНИЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ И ВОСПИТАТЕЛЬНОЙ СИСТЕМЫ ТАТАРСКОГО НАРОДА

*ГАОУ «Лицей Иннополис»*

*Выполнил: Вертячих Роман Максимович, ученик 10 класса*

*Руководитель: Гайнуллин Рамиль Рашитович,*

*Учитель татарского языка и литературы*

## Введение

Актуальность темы исследования обусловлена тем, что мы хотели изучить историю родного края через микроисторический подход и тем самым показать насколько сильна роль отдельных населенных пунктов, деревень или же исторических личностей в истории становления образовательной и воспитательной системы татарского народа.

Система образования татар берет свое начало с момента принятия Ислама. Начало создания сети мяктебе (начальных школ) и медресе Булгарии можно датировать XII в. В этих учебных заведениях получали образование ученые и религиозные деятели мусульманского мира.

Начиная с XVI в. особенности образовательной системы татар обуславливались тесной связью с православным Российским государством. В 1707 г. по инициативе митрополита Тихона в г. Казани была учреждена школа, в которой обучалось 32 мальчика, однако через два года из-за болезней детей она была закрыта.

В 1720 г. была открыта школа для 20 черемисских детей, а в 1724 г. в архиерейскую школу набрано было 14 татарских и черемисских мальчиков, обучавшихся русскому языку и Закону Божию вместе с детьми русских священнослужителей «в надежду священства»[11].

Во второй половине XVIII в. был сформулирован и реализован самостоятельный проект, опиравшийся на систему новокрещенских школ и соответствовавший стремлению правительства к массовой христианизации инородцев Казанского края: в 1734 г. архиепископ Иларион Рогалевский представил в Св. Синод предложения об учреждении в Казанской епархии четырех школ для обучения детей инородцев вне зависимости от их конфессиональной принадлежности. Они были высочайше утверждены указом от 26 февраля 1735 г.

В 1771 г. в Казани было открыто 2 медресе Ахуновское и Апанаевское, в 1780 г. было открыто медресе при доме Амирханова, а также в деревнях: Кышкар, Менгер, Саба и др. Это позволило не тратить время и денежные средства на поездку в Бухару, признанный центр мусульманской культуры и науки, соответственно, больше татарских молодых людей смогли получить духовное образование близко к дому.

Развитие образования в Татарстане связано так же и с именем М. В, Ломоносова, по инициативе которого в 1764 г. была создана кафедра восточных языков при Академии наук. Этот проект отражал политику правительства, заинтересованного в организации преподавания восточных языков в учебных заведениях, расположенных в городах с преобладанием мусульманского населения.

Главная роль в этом деле отводилась основанной в 1759 г. Казанской гимназии. Мысль о введении во вновь созданной в Казани гимназии преподавания татарского языка принадлежит первому ее директору М. И. Веревкину и относится к тому же 1759 г. Но получила свое реальное воплощение

[11] Можаровский А. Ф. Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев с 1552 по 1867 г. М., 1880. С. 39-40

лишь благодаря указу императрицы Екатерины II от 12 мая 1769 г.: «единожды навсегда» ввести класс татарского языка для практических целей - подготовки переводчиков с татарского языка[12]. Университет в Казани был открыт в ноябре 1804 г. В нем кроме татарского, преподавались персидский, арабский, монгольский и китайский языки.

Реформы эпохи Александра I затронули и инородческое образование, которое должно было осуществляться через систему сельских приходских училищ с опорой на родной язык учеников и широкое использование в качестве учебного и дидактического материала переводов вероучительных книг.

Благодаря реформам, инициированным Александром II, начался подъем образования всех российских народов, и национального образования в том числе. В системе образования татарского народа постепенно складывалось инновационное направление, которое вошло в историю под названием джадидизм. Происхождение термина связано с внедрением в обучение нового метода «усул джадид», возникшего благодаря реформе традиционного конфессионального образования при разработке звукового метода обучения.

Появление нового метода обучения в мусульманских медресе на территории Татарстана в XVII-XVIII вв. основным языком обучения в медресе был арабский. В основном изучалась арабская азбука, читали хафтияк на арабском языке
(одна седьмая часть Корана), книгу «Мухаммед-эфенди». У мусульман, как известно, существует особая наука «Теджвид», которая учит правильному чтению Корана, то есть фонетике арабского языка. В медресе основательно изучали арабскую морфологию (сарыф), синтаксис (наху), риторику (балагэт). Логика (мантык) так же была одной из главных дисциплин в медресе. В них так же преподавали основы счета, истории и географии. Кроме арабского языка, необходимого для понимания Корана, учили персидский, турецкий и другие языки[13].

Не существовало никакой гарантии, что окончив медресе, человек сможет объясняться на современном ему арабском языке или читать светскую литературу. Кадимистские школы основным методом обучения считали книжный. Обучение строилось на заучивании слов, фраз, аят и отрывков из книг наизусть. К тому же, в школах не существовало деления на классы или какой-либо стандартизации учебного процесса, что, безусловно, затрудняло познавательную деятельность и создавало в среде богословской интеллигенции прослойку преподавателей и мулл, которые так и не закончили обучение. Ученик, пришедший в медресе в восемь лет, мог оставаться в нем и до тридцати лет и далее.

В рамках же нового метода в учебные планы мусульманских медресе в противовес средневековой схоластике были включены светские культурологические и научные дисциплины. Школы-мяктебе стали делиться на классы. Существовали одноклассные мяктебе, двуклассные и четырехклассные. Появились стандартизированные программы обучения разным дисциплинам, ученики стали сдавать экзамены, что позволило достаточно адекватно оценивать их знания и контролировать весь процесс обучения.

Одним из подвижников осуществления таких реформ татарского образования был Каюм Насыри, ученик и последователь еще одного великого педагога, общественного и религиозного деятеля Ш. Марджани.

По совету инспектора В. В. Радлова, Каюм Насыри открыл начальную школу для татарских детей с преподаванием в ней русского языка, и 1871 г. стал важной вехой в развитии образования татар, началом этапа усовершенствования преподавания русского языка. Всесторонняя подготовка, хорошее знание традиций восточной культуры, с одной стороны, и европейской научной мысли, с другой, позволили ему сделать первые шаги для их интеграции.

**Было ли село Агзегитово центром новометодного образования?**

В 1913 г. В Казанской губернии всего насчитывалось 1938 мяктебе и 150 медресе. В двух чувашских уездах – Цивильском и Чебоксарском – в рапортах уездных полицейских управлений с

---

[12] Загоскин Н. П. История Императорского казанского Университета за первые сто лет его существования 1804 - 1904. Т. 1 (1804 - 1814). - Казань, 1902. С. 20

[13] Фукс Л. Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. - Казань, 1884.

1889 по 1905 гг. отмечается наличие 9 мяктебе (из них три в селе Агзегитово) и единственного медресе в селе Агзегитово.[14]

К 1909 году в селе Агзегитово проживало около трех тысяч человек. Село было поделено на три прихода. В первом приходе, действовавшем к этому времени более ста лет, проживало 514 мужчин и 469 женщин. Во втором приходе проживало 547 мужчин и 574 женщины. Приход был основан в 1891 году. В третьем приходе проживало 354 мужчины и 323 женщины. Этот приход был образован в 1902 году[15]. Таким образом, можно сделать вывод, что село было довольно крупным, однако не настолько, чтобы стать центром новометодного образования.

**Загидулла Шафигуллин – предприниматель и меценат**

Появление и успешная деятельность школ и медресе в селе Агзегитово связано с именем уроженца этого села Загидуллы Шафигуллина – предпринимателя и мецената. Он выстроил за свой счет целый ряд мечетей, медресе и мяктебе в Цивильском, Свияжском, Тетюшском уездах Казанской губернии. Именно благодаря ему были выстроены две новые мечети в селе Агзегитово, разрешение на строительство которых было достаточно сложно получить. С 1898 г. Шафигуллин одним из первых в Казанской губернии перевел обучение в медресе и мяктебе на новометодную систему.

Шафигуллин долгие годы лично контролировал процесс обучения в медресе и мяктебе для мальчиков, а так же очень серьезно относился к женскому образованию. При его попечительстве в селе Агзегитове было открыто женское медресе.

К 1913 году в мяктебе села Агзегитова обучались 300 мальчиков и 850 девочек.[16] Еще около сорока девочек обучалось женском медресе. Обычно девочки получали начальное образование в мяктебе, отдельно от мальчиков или ходили на индивидуальные занятия к женам мулл (остабикэ). Те обучали их арабскому алфавиту и чтению, письмо считалось ненужным. Девочки достаточно рано выходили замуж, поэтому на их образование родители не желали тратиться. Обучение в мяктебе не было полностью бесплатным, прихожане жертвовали определенную сумму на его содержание.

Революционное отношение З. Шафигуллина к образованию в целом и женскому образованию в частности, привело к тому, что он нанял для занятий с девочками специально подготовленную женщину-учителя М. Искандарову, которая окончила в 1910 году Ижбубинское медресе и получила звание мугаллими.

Основываясь на архивных данных мы можем сделать вывод, что учится в женском медресе села Агзегитова могли в некоторых случаях и замужние женщины, что было достаточно необычно.

З. Шафигуллин настаивал на том, чтобы в мяктебе и медресе были созданы русские классы, так как понимал необходимость давать подросткам не только классическое духовное образование, но и по возможности образование светское.

Однако, деятельность З. Шафигуллина не встречало поддержки у уездной и губернской администрации. Более того, администрация часто препятствовала развитию учебных заведений в селе Агзегитове.

З. Шафигуллину долго не давали разрешения на устройство русских классов при мяктебе и медресе. Мулла третьего прихода А. В. Абдул-Саттаров, который преподавал в медресе, даже был обвинен в неблагонадежности, отстранен от преподавания и уволен с должности муллы. Упомянутую выше М. Искандарову, обвинили в том, что она преподает без соответствующего разрешения и так же долго проверяли ее благонадежность.

Когда русские классы были все же открыты, возникла проблема с кадрами. З. Шафигуллин был против того, чтобы в них преподавали немусульмане, пусть по происхождению и татары. Администрация учебного округа же настойчиво предлагала православных учителей.

Если судить по архивным документам, то именно вероисповедание служило главным критерием отбора преподавателей. Так в 1912 г. Н. Тагиров был уволен с должности учителя русского языка из-за злоупотребления крепкими спиртными напитками. После чего в 1913 г. был вновь допущен до преподавания, несмотря на сопротивление со стороны З. Шафигуллина. Через некоторое

[14] Ф. 151, дд. 1078, 1430, 1438, 159, дд. 4846, 634, 713, 189

[15] Ф. 2. оп. 2, д. 8464 лл. 372-374

[16] Ф. 2. оп. 2, д. 8464 лл. 372-374

время Тагиров снова был уволен из-за пьянства, но заменен новой креатурой инспектора народных училищ. Ф. Сейфулиным.

**Заключение**

В конце XIX вв. Российская Империя вступила на путь бурного экономического развития. Это не могло не коснуться и Татарстана. Возникла острая необходимость в обучении и воспитании национальных кадров. Чувствовался серьезный недостаток в образованных людях, интеллигенции, грамотных чиновниках, предпринимателях.

К 1913 г. очень серьезно встал вопрос о недостаточном количестве двуклассных училищ. На весь Цивильский уезд с населением более 200 тыс. человек существовало всего три таких училища, в которых обучалось к первому января 1913 г. всего 112 учеников. Более того, несовершенная система обучения мешала своевременному переходу учеников во второй класс. Это свидетельствовало о том, что будущее несомненно было за новометодными школами. Такими, как были открыты в селе Агзегитово.

Новый метод обучения, хотя и продолжал делать упор на религиозное образование и воспитание в духе мусульманских ценностей, давал при этом возможность получить в медресе современное светское образование и продолжить его, при необходимости, в университете или ином другом учебном заведении. Из медресе выходили грамотные, знающие преподаватели, как мужчины, так и женщины. Таким образом, выполнение поставленных исследовательских задач позволило нам понять, что село Агзегитово стало одним из значимых центров распространения новометодного образования, центром подготовки улемов.

**Источники**

1. Архивный фонд Казанского губернского правления.

**Литература**

2. Владимиров В. Историческая записка о 1-й Казанской гимназии, ч. Ш. - Казань, 1867.
3. Гибб Х. А. Р. Арабская литература. Классический период. -М., 1960.
4. Горохов В. М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. - Казань: 1941.
5. Загоскин Н. П. История Императорского казанского Университета за первые сто лет его существования 1804 - 1904. Т. 1 (1804 - 1814). - Казань, 1902.
6. Ковалевский О. М. О знакомстве Европы с Азией. - Казань, 1837.
7. Можаровский А. Ф. Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев с 1552 по 1867 г. М., 1880.
8. Мухаметшин А. Г. Становление и развитие педагогической мысли в Волжской Булгарии (VIII-XIV вв). Дис. канд. пед. наук. - Казань, 1995.
9. Фукс Л. Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. - Казань, 1884.
10. Шарафутдинов Ш. З., Ханбиков Я. И. История Педагогики Татарстана. - Казань, 1998.

## Туган ягымның күренекле татарлары

*МБОУ «Макуловская средняя общеобразовательная школа» Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан*

*Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы “Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениес*

***Эшне башкаручы:*** *10нчы сыйныф укучысы Сибгатова Ландыш Роберт кызы.*

***Җитәкче:*** *югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Амутбаева Гөлзәр Абдулла кызы.*

**Кереш**

Җырлый-җырлый күтәреләм
Тормышның үрләренә
Шатлыгым да, хәсрәтем дә

Тик туган җирдә генә.
Хәкимҗан Халиков.

1. Туган як! Туган туфрак! Бу сүзләр кемнәрне генә дулкынландырмый икән! Нигә син шулкадәр йөрәккә якын, күкрәкләргә кысып сөярлек газиз икән?! Кеше кайда гына яшәмәсен, кем генә булып эшләмәсен, үзенең газиз туган ягын сагынып, иң олы хисләр белән искә ала. Кеше күңеле өчен туган як кирәк. Еракка китсә сагыныр өчен; картайса, балалыгына кайтыр өчен; дошман керсә, яклар өчен. Ерак җирләрдә йөргәндә, кеше читтәге матурлыкны әнә шул үзенең туган ягы белән чагыштыра. Туган ягы аңарга биеклеккә сикерү ноктасы, гүзәллек үрнәге булып хезмәт итә. Туган ягымда хезмәт сөючән, тырыш халык яши. Аларның һәрберсе аерым мактауга, ихтирамга лаек. Районыбыз кешеләре илебез тарихында үз эзен калдырды. Бүгенге көндә ,үткәннәрне барлаганда, аерылыбрак торган шәхесләрнең язмышын ил язмышы белән бәйләп, киләчәк буыннарга сөйлисе килә.Алар төбәгебез белән бәйләнгән кешеләрнең язмышын белергә, үткәннәне онытмаска тиеш. Халык күңелендә хәтер яшәргә тиеш. Бу-бүгенге көндә актуаль проблемаларның берсе булып тора.

Минем туган ягым –Югары Ослан районы. Ул табигатьнең иң гүзәл урынына - Идел елгасының уң як ярына урнашкан. Бездә зур, калын урманнар да, киң аланнар да, салкын сулы чишмәләр дә бихисап. Районыбызда күпчелек халык рус милләтеннән.. Татар авыллары да бар, ләкин алар бик аз күләмдә.

Мин бу эшемдә үземне кызыксындырган сорауга җавап эзләргә тырышып, безнең яктан да танылган шәхесләр чыкканмы икәнен ачыкларга керештем. Башта татар авылларының (алар бик аз санда) тарихы белән таныштым. Аларның район тарихында тоткан урыннарын билгеләдем. Берничәсе белән сезне дә таныштырып китәсем килә.

2. Кызыл Байрак авылы... Бу исем хәзер һәр татар кешесенең, алай гына да түгел, Сәйдәш моңын яраткан һәркемнең тел очында. Мәгърур Идел елгасы ярына урнашкан шушы авыл илаһи моң иясе Сәйдәшне шатлыклы вакытларында да, тормышның четерекле вә кыен чакларында да, үзенең назлы һәм җылы кочагына сыендырган, хәтәр җилләрдән дә саклап калган, әлбәттә, аңа иҗат рухы биргән. Югары Ослан районындагы Кызыл Байрак авылы барыбыз өчен дә якын һәм кадерле.

Кызыл Байрак авылы Иделнең уң як ярына – бакыр кәүсәле биек наратлар үскән, яшел ерымтылар, хәтфәдәй үлән белән капланган үрләр җәйрәп яткан урынга, табигатьнең иң гүзәл җиренә урнашкан. “Татар Швейцариясе” дип аталган Кызыл Байрак авылы турында ниләр беләбез соң? Авылга исемне татарның танылган әдибе Галимҗан Ибраһимов биргән, диләр. Ханнар яшәгән бу гүзәл җиргә язучы еш килә торган булган, ул биредә уйланырга, эшләргә, язарга яраткан.

Авылга нигез 1924нче салынган, нигез салучылар: Сәхипгәрәй Сәетгалиев һәм шул чордагы Тат ҮБК рәисе Гали Ганиев. Алар шул еллардагы күренекле шәхесләр – дәүләт җитәкчеләре белән киңәшеп, ерактагы, җиргә саран булган авыллардан татар гаиләләренең Иделнең уң як ярына күчеп килүләрен оештыралар. Нәкъ менә шул елларда Бөрек, Кызыл Байрак, Нариман, Бакчасарай авыллары калкып чыга да инде. Кызыл Байрак авылын оештыруда Гали Ганиевнең иң якын ярдәмчесе – танылган мәгърифәтче, нәшир, композитор Салих Сәйдәшевнең җизнәсе һәм тәрбиячесе Шиһаб Әхмәров бик актив эшли. Бу вакытта Шиһаб Әхмәров үзара кредит бирү җәмгыяте идарәсе әгъзасы була. Авылга күченеп килүче татар гаиләләренә ул саллы гына матди ярдәм күрсәтә, мәктәп төзү өчен җәмгыять аркылы акча туплый.

3. Социаль үзгәрешләр белән беррәттән, авыл кешеләренең рухи дөньясы да байый бара. Моның үзенә күрә сәбәпләре дә бар: Татарстанның күпчелек иҗат әһелләре, мәгариф . Шиһаб Әхмәров Кызыл Байракка Чүпрәле районында яшәгән туганы Хәйрулла Әхмәровны алып килә. Хәйрулла бик тә кешелекле, эшчән кеше була һәм авыл активистларының берсенә әверелә. Аның йорты гөжләп тора: кунакчыл гаиләгә, гадәттә, җәйге чорга Г.Ибраһимов кайта, аның янына бик күп башка язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, дәүләт җитәкчеләре һ.б. килә.Соңыннан бу йортка терәп, тагын бер йорт салына.Анда Шиһаб Әхмәров гаиләсе яши. Ел саен аларга Салих Сәйдәшев кайта. Шиһаб Әхмәров-аның җизнәсе, Салихның апасы Әминәнең ире. Бу йортка артистлар, музыкантлар, язучылар гаиләләре белән кунакка киләләр. Шулай итеп, җәйге айларда Кызыл Байрак Шәриф Камал (Гарәфи Хәсәнов йортында), Гадел Кутуй (Сафиннарда), Һади Такташ һәм башкалар озак-озак кунак булып, ял итеп китәләр.

Ул чактагы тормышның кызыклыгы! Өй саен кунак, авыл тормышына алар актив катнаша, дустату булып, гөрләшеп яшиләр. Урманда берничә урында ашъяулык җәелгән, самоварлар кайнап тора. Кунаклар да, авыл кешеләре дә бергә утырып, көлешә-көлешә, күмәкләшеп чәй эчәләр.Шунда ук җанлы әңгәмә башлана, уен-көлке, музыка-җыр. Кичләрен урман аланына яше-карты уенга чыга. Үзәктә-Салих ага Сәйдәшев. Бөтенесе аңа тартыла, мәзәкләр сөйләү, ихлас көлешүләр... Ул Кызыл Байрактан Казанга ял итеп, илһамланып кайта.

Кызганыч, 1930-1940нчы елларда илдә барган фаҗигале хәлләр Кызыл Байрак өчен дә эзсез узмый. Авылга кайтып ял итеп йөргән кешеләрнең бөтенесе диярлек, милләтчелектә һәм башка уйдырма җинаятьләрдә гаепләнеп, Сталин репрессиясе корбаннары булалар. Гали Ганиев тә, Шиһаб Әхмәров та шул корбаннар арасында...

Куркыныч давыл булып, ил өстенә сугыш килә. Авылның асыл ирләре сугышка алына, сугыш һәм тыл йөгенең бөтен авырлыгы, фаҗигасе картлар, хатын-кызлар, балалар җилкәсенә төшә. Авыл бушап, сүнеп кала. Шулай да элекке традицияләрне югалтмаска тырышалар. Эштән арып кайткан яшьләр әтиләре, абыйлары, татарның олы шәхесләре ял иткән урман аланына чыгып, еш кына күңел ачу оештыралар.

.Сугыштан бик аз кеше исән кайта. Алтмышынчы елларга кадәр –Кызыл Байрак тормышында яңа үзгәрешләр бара. Авыр еллар. Хәерчелек, илдә барган сәясәт кешеләрне бер-берсеннән аера, ераклаштыра. Салих Сәйдәшев Кызыл Байракка соңгы тапкыр 1954нче елда – Мәскәүгә китәр алдыннан ялга кайткан була. Шуннан соң Кызыл Байрак Сәйдәшсез кала.

## Төп өлеш

1.Сәйдәш моңын саклый Сәйдәш аланы

2000нче елда Идел елгасы буена урнашкан Кызыл Байрак авыл җиренә Сәйдәш истәлеге итеп Хәтер ташы куела, чөнки биредә мәшһүр композитор эзләре калган ямьле яр буйлары, ул ял иткән яшел алан, яшәгән, иҗат иткән йорт...Бу эшне оештыруда Галиаскәр Камал исемендәге театр коллективы җитәкчелеге район җитәкчелеге белән берлектә башлап йөриләр. Ел саен август аеның 3нче атнасында күренекле сәнгать әһелләре, артистлар, төрле кунаклар Сәйдәш аланына җыелалар. Алар 1920-1940нчы елларда җәй айларында монда яшәвен искәртеп, рухын саклап торган урында яңадан Салих ага Сәйдәшевнең үлемсезлеген искә төшерәләр. Театр коллективлары музыкаль әсәрләрен башкаралар, спектакльләрдән күренешләр күрсәтәләр, күренекле җырчыларыбыз, язучыларыбыз үзләренең чыгышларын Сәйдәш истәлегенә багышлыйлар.

"Әйе, бөек композитор һәм музыкант Салих Сәйдәшев – XXгасырның беренче яртысында татар халкының милли-мәдәни яңарышы күгендә балкып янган якты йолдыз. Ул –татар профессиональ музыкасына нигез салучы; дистә елларга алдан аның үсеш юнәлешләрен билгеләүче. Аның музыкаль даһилыгы гаҗәеп мелодизм, сулыш җиңеллеге, колачлы эчтәлеге, демократизмы һәм аңлаешлылыгы белән аерылып тора. Татар музыка мәдәниятендә Сәйдәшев кебек гадәттән тыш сәләтле шәхеснең булуы яңарыш үсеше юлына баскан татар милләтенең өлгергәнлеген раслый"- дип яза академик Мансур Хәсәнов.

"С.Сәйдәшев һәм татар әдәбияты. Аларны һич кенә дә аерып алып булмый. Бигрәк тә Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт кебек зур драматурглар белән Сәйдәшевнең иҗаты тыгыз үрелеп барды, -ди Фоат Галимуллин. Кызыл Байрак Сәйдәш өчен генә түгел, бәлки татар әдәбияты өчен дә бик кадерле урын, чөнки 30нчы елларда биредә татар әдәбиятының үзәге булган. Татар язучылары да үзләренең җәйге ялларын, иҗат чорларын биредә уздырганнар..."

Кызыл Байракта ел саен Сәйдәш рухын зурлау татар халкының милли йоласына әверелеп бара. Ул хәзер Кушлавыч, Кырлайлар кебек изге урынга әверелде. Кызыл Байракның үзеннән дә, Югары Ослан районы авылларыннан да халык агыла. Ә Казанны әйтәсе дә түгел, махсус теплоходка төялеп тә, автобусларга һәм исәпсез –хисапсыз җиңел машиналарга утырып та, XXI гасырның Моң Мәккәсе – Кызыл Байракка агылалар...

2013нче елның августында Сәйдәш аланында бәйрәмне Югары Ослан районы үз көче белән уздырды. Монда районның "Иделкәй", "Тамырлар" ансамбльләрен, Мәдәният йорты , шул ук вакытта һәвәскәр җырчыларны да күрергә була иде.Күп санлы татар теле укытучылары, район мәктәпләренең укучылары, төрле милләт халкы Сәйдәшне искә алырга килгәннәр. Сәнгать мәктәбе оркестры

башкарган “Совет Армиясе маршы” Идел елгасы буенча таралып, Сәйдәш, аның көйләре, җырлары халык күңелендә мәңге яшәр дип әйтәләр сыман..

2. Асия Хәсән кызы Хәйруллина – Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе, Татарстанның атказанган артисткасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, татар сәхнә теле укытучылары мәктәбен нигезләүче. Аның язмышы да Кызыл Байрак авылы белән бәйле. Үзенең “Ничек тиз узасың син, гомер” дигән китабында хәтирәләр - истәлекләр турында яза.

1921нче елда Апас районы Түбән Барыш авылында бүрекче Хәйрулла гаиләсендә бишенче бала булып туа. Бу елда бик каты ачлык булган. Яңа туган балалар ачлыктан үлә барганнар; авылда үлмичә Асия Хәйруллина, Карбай атлы эт һәм әтисе ягыннан туган кешенең Шәйхулла исемле улы гына кала. Әти-әниләренең тормышлары бик мул була. Аларның аты, сыеры, сарыклары, бозаулары, ишегалды тулы кош-кортлары булган. Шуның өстенә, янда гына таш кибет, тау башында –су тегермәне эшләгән. Ул елларда әтисенең ир туганнары Казанда яшәгән. Алар кулаклар турында начар хәбәр чыккач, абыйның да тормышы бик бай, сөргенгә җибәрүләре мөмкин дип, аңа авылдан тизрәк китәргә кушалар һәм Кызыл Байракка урнашырга тәкъдим итәләр.

Шулай итеп, Асия Хәйруллина кеше кулы тимәгән, бозмаган, таптамаган, гаҗәеп матур, әкиятләрдә генә сөйләнә торган чиста, гүзәл авылга килеп урнаша. “ Кызыл Байракта бер кеше капка бикләмәде, тәрәзәләрне япмады, әйберләрен яшермәде.Бөтен әйбер урамда,кешеләр курыкмыйча, рәхәтләнеп яши бирделәр”,- дип яза истәлекләрендә.

Тау башында Иделгә каршы урнашкан дүрт еллык мәктәптә белем ала. Аннары Кызыл Байрактан сигез чакрым ераклыкта урнашкан Берек авылында укый. Атна буе бу авылда торып укыганга күрә, буш вакытлары күп була. Аларны бушка уздырмый, мәктәптә оештырылган төрле түгәрәкләрдә катнаша. Аның өчен иң кызыгы, үзенә тартканы-драма түгәрәге була. Җиденче сыйныфта укыганда, укытучылар белән берлектә “Зәңгәр шәл” драмасын сәхнәгә куялар. Шул вакытта ук артистка булырга хыяллана. Берек мктәбен тәмамлагач, Спас педагогия училищесына укырга керә. Монда озак тормый, кечкенә Асияне чанага утыртып, толыпка төреп, Тәтеш педучилищесына укырга илтәләр. Бетереп кайткач, Нариман авылында укытучы булып эшли.Сугыш вакытында мәктәптә эшләү җиңел булмый. Асия Хәйруллина –директор да, завхоз да, идән юучы да, мичкә ягучы да, хәтта утын табучы-кисүче дә.Ул гына да түгел, авылда ирләре, туганнары сугышка киткән хатын-кызларны юатучы да, аларны солдатлар өчен оекбашлар бәйләргә кушучы да-барысы да аның бурычы була.Кич белән мәктәпкә хатын-кызларны чакырып җырлата, мандолинада уйный.

1944нче елда бу авылдан китә. Аннары Казанда, Мәскәүдә укый, артистка булып озак еллар Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында эшли. Туган ягына еш кайта, балачак һәм үсмер еллары узган Кызыл Байрак урамнарыннан үткәннәрне искә төшереп атлый.

Әйе, табигатьнең гүзәл кочагында урнашкан авыл олы шәхесләрнең рухын бүген дә саклый!

3. Кәфил Фәхрәзи улы Әмиров – Татарстан Республикасының элекке прокуроры 1949нчы елның 24нче маенда Югары Ослан районының Нариман авылында дөньяга килә. Бу авыл да Идел елгасының уң як ярында урнашкан, Кызыл Байрактан сигез чакрым ераклыкта урнашкан. Балачагы, үсмер еллары Идел елгасында су коенып. табигать кочагында хозурланып уза.

1972нче елда Харьковта юридик институтны тәмамлый, аннары 1972-1973нче елларда Сарман район прокуратурасында өлкән тикшерүче, 1973-1980нче елларда Татарстан Республикасының өлкән тикшерүчесе, 1980-1989нчы елларда Казанның Вахитов районында прокурор, 1989-1992нче елларда Казан прокурорының беренче урынбасары, 1997-2000нче елларда-Татарстан Республикасы прокурорының беренче урынбасары. 2000нче елның 29нчы июненнән Татарстан Республикасының прокуроры итеп сайлана. 2013нче елның 21нче сентябреннән ул лаеклы ялга китә.

4. Сафин Марат Габдрахман улы – Казан Дәүләт Ветеринария Академиясе профессоры 1935нче елның 3нче мартында Югары Ослан районының Макыл авылында укытучы гаиләсендә туа. Сугыш башланганда аңа 6яшь була. Бу көннән башлап күп балалы Сафиннар гаиләсе өчен коточкыч авыр көннәр башлана. Бөек Ватан сугышы башларында әтиләрен “халык дошманы” дип Себергә сөргенгә җибәрәләр, ә 15ел үткәч, гаепсез дип кире кайтаралар.

Бу авыр елларда әниләре 6 бала (өч кыз, өч малай) белән берүзе кала. Олысына 16яшь, ә иң кечесенә 6ай була. Әниләре белән апалары көне-төне .колхозда эшлиләр, ә калган балалар укый. .Кимсетүләр дә аз булмый, “халык дошманы” балаларының ипи паегын тартып алалар, гаиләгә зур

гына салымнар салалар. Даирәләрдән куркып, этисенең туганнары да аларга кереп йөрүдән баш тарталар. Әниләре балаларын ачлыктан коткарып калу өчен барысын да эшли: өйдәге барлык булган әйберләрне сата, бары тик агач сәкеләр белән урын-җир генә кала. Барысын да җиңәләр: ачлык та , үлем дә артта кала.

1943нче елда иске бишмәт, чабата кигән Марат 1нче сыйныфка укырга бара. Авылда башлангыч мәктәп кенә, ә җидееллыкны 6 чакрым ераклыкта урнашкан Улан авылында тәмамларга туры кирә. 1950нче елда 7сыйныфны бетерә, ә бердәнбер урта мәктәп район үзәгендә генә була. Район үзәге Макыл авылыннан 30 километр ераклыкта урнашкан. Укырга мөмкинлек булмый һәм 15 яшьлек Марат үзенең хезмәтен Югары Ослан районының "Алга" колхозында башлап җибәрә. Башта әнисе белән сарыклар фермасында эшли, ә 1951-1952нче елларда колхозның атлар көтүен көтә. Менә шул вакытта Марат Габдрахман улының хайваннарга карата кызыксынучанлыгы һәм мәхәббәте туа. Ул иң яхшы атта йөрүче булып санала һәм ел саен сабантуй ярышларында призлы урыннарны ала.

Укуга омтылыш аның беркайчан да сүнми һәм ул 1952нче елда Казанның 15номерлы кичке яшьләр мәктәбенең 8нче сыйныфына укырга керә. Мәктәп аны Казан механик заводына слесарь укучысы итеп җибәрә. Чит кешеләр почмагында яшәп, көндезләрен эшләү, кич белән уку аңа бик авырга туры килә. Марат Габдрахман улы бернәрсәне бик яхшы аңлый: аның башка юлы юк, ышанырлык, ярдәм күтәрлек кешесе юк." Заводта эшләгәнгә хезмәт хакы алгач, -дип искә төшерә Марат әфәнде, шунда ук 2 ипи һәм 1 килограмм маргарин мае сатып ала".Моны күреп, хуҗа хатын яшь аралаш "Ни өчен болай күп сатып алдың?-дигән сорауга: "Туйганчы ипи белән май ашыйсым килде"-, дип җавап биргән.

1955нче елда 10нчы сыйныфны тәмамлап, Казан ветеринария институтына укырга керә. Институтта уку дәверендә үзен бик сәләтле оештыручы итеп таныта, 5 ел буе ул комсомол комитеты әгъзасы булып тора, ә соңгы елларында сәркәтибе була. 1957нче елда яңа сөрү җирләрдән уңыш җыеп алуда катнашкан комсомол-яшьләр бригадасының җитәкчесе була. Яхшы эшләгәннәре өчен барлык бригада кешеләре Мактау кәгазе һәм ВЛКСМ ҮК ның значоклары белән бүләкләнәләр. Җитәкчесенә-шәхси бүләк, азкалиберлы ТОЗ-8 винтовкасы.

1958нче елда партия сафларына керә. 5 ел уку чоры бик тиз үтеп китә.Укуын тәмамлагач, институт юлламасы буенча "Татарстан" совхозында баш ветеринар табиб булып эшли. Шулай аның хезмәт юлы башлана. Аннары ул институт җитәкчелеге чакыруы буенча аспирантуранга укырга керә. Монда 1981нче елда докторлык диссертациясен яклый һәм үз эшен профессор буларак, төрле фән өлкәсендә эзләнүләре белән дәвам итә. Аның бик күп санлы фән өлкәсендә эшләнгән эшләре гамәли яктан кулланыла.

Бүгенге көндә ул лаеклы ялда, шуңа да карамастан ,озак еллар хезмәт иткән Казан Дәүләт Ветеринария Академиясе аның эшләгән эшләрен онытмый, Сафин Марат Габдрахман улы белән аралашып тора . Туган ягына да еш кайта, авылдашлары белән аралаша, үткәнннәре турында искә төшерә.. Без дә аңа нык сәламәтлек, озын гомер телибез.

5. Композитор Риф Хаббулла улы Гатауллин Россиянең һәм Татарстанның композиторлар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты

безнең районыбызның горурлыгы 1952нче елның 24нче маенда Яңа-Болгар авылының укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Бу авылның табигате дә аңа җырчы, композитор булып китәргә ярдәм иткәндер, чөнки кечкенә генә татар авылы урман уртасына урнашкан. Табигатьнең гүзәллегенә сокланып, кошлар сайравын тыңлап, Риф Гатауллин иҗат итү сәләтләрен үстергәндер.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан музыка училищесында укый. Аңа композитор булып китәргә татар халкының яраткан композиторы Сара апа Садыйкова зур этәргеч ясый. Риф Гатауллинның "Ялгыз көймә", "Хушлашырга ашыкма!" һ.б. җырлары халык күңеленә тирән кереп калды. Ул еш кына туган якларына кайта, район мәктәбе укучылары белән төрле очрашулар, иҗат кичәләре, фестивальләр үздыра. Без аны бик хөрмәт итәбез, яратабыз, безнең төбәктән чыгуы белән горурланабыз. Киләчәктә тагын да иҗат уңышлары телибез!

## III Йомгаклау.

Татар халкы шәхесләргә бик бай. Халык язмышы ил язмышы белән бәйләнгән. Рус милләтле районда татар авылларының булуы, анда яшәгән халыкның нинди генә тарихи вакыйгалар булуга карамастан

нык булуы, безне сокландыра. Язмыш күпме генә сынаса да, алар югалып калмыйлар, милләтнең гореф-гадәтләрен, телен саклап, бүгенге көнгә кадәр җиткергәннәр. Күренекле шәхесләрнең язмышында төбәгебез авылларының нинди урын тотуы бездә горурлык хисе тудыра. Бигрәк тә Салих Сәйдәшев яшәгән йорт янында Хәтер ташы куелу, ел саен татар халкының монда җыелып аны искә төшерү-безнең төбәгебез өчен шатлык та , горурлык та. Мондый шәхесләр булганда милләтебез яшәр, без моңа ышанабыз

Нәтиҗә: Югары Ослан җирлегенең күренекле шәхесләре һәм Кызыл Байрак авылының алар язмышында тоткан урыны турында өйрәнеп, мин түбәндәгеләрне аңладым:

1. Югары Ослан төбәге күренекле шәхесләргә бик бай;
2. Кызыл Байрак авылының тарихы ил тарихыннан аерылмый, ул үзендә мәшһүр композитор С.Сәйдәшев һәм башка бөек шәхесләрнең рухын саклый.
3. Башка авыллар тарихын һәм аннан чыккан күренекле шәхесләрнең тормыш юлын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк;

**Файдаланган әдәбият:**

1. Г.Ризванов, К.Әмиров “Сәйдәш аланында”
2. С.Сәйдәшевкә багышланган сайтларга сылтамалар.
3.Татар энциклопедиясе Казан 2008
4. «Татар иле» мәгълүмати –ресурслы татар социаль челтәре.

## Тукай эзләре буйлап.

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*“Субаш төп гомуми белем мәктәбе”*
*Эшләде : 9 нчы сыйныф укучысы Васильева Гөлинә Ильвир кызы.*
*Җитәкчеләр : югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары :*
*Васильева Гөлназ Фазил кызы,Галиева Раилә Мәсхүт кызы*

**I Кереш өлеш**.

Фәнни – тикшерү эшемнең темасы: Тукай эзләре буйлап. Максатым: Тукай тормышында билгеле бер эз калдырган Сосна Пүчинкәсе, Тукайның әнисе Бибимәмдүдәнең әлеге авылда яшәү чоры турында тулырак күзаллау булдыру. Максаттан чыгып түбәндәге бурычлар билгеләнде: Тукай эзләре буйлап сәяхәт итү, Бибимәмдүдәнең тормышын архив материаллары буенча җентекләп өйрәнү. Эшемнең актуальлеге: заманында төрле фикерләр кузгаткан Бибимәмдүдәнең Сосна Пүчинкәсендәге язмышы, Тукайның безнең яктагы тормышы турында тулырак мәгълүмат бирү. Әлеге хезмәтне тормышка ашыруда төп чыганак булып, Татарстан Республикасы Балтач районы “Халыклар дуслыгы” музеендагы документлар, архив материаллары, өлкән аксакаллар язып калдырган истәлекләр тора.

Тукай хакында сүз чыктымы, еш кына күңелгә бер сорау килә: ничек итеп гади генә бер авыл ятиме санаулы еллар эчендә күп гасырлык тарихы булган татар әдәбияты күгендә балкыр йолдызга әверелгән? Ничек итеп ул замандашларын һәм килер буыннарны үзенә берьюлы җәлеп итә алган? Каян шундый көч һәм бетмәс-төкәнмәс җегәр табылган? Шагыйрьләрнең җирдәге тормышы һәрвакыт кайгылы һәм еш кына кыска була. Аларның күнелләре сизгер, тиз җәрәхәтләнүчән була һәм ялгыз була – йөрәк әрнүләре гүзәл сүзләр булып ташып чыга.

Гомер юлы нибары 27 генә ел булса да, җисми яктан тормыштан китсә дә, Тукай шагыйрь буларак, бу дөньядан китмәде. Аның авазы һаман да яңгырый һәм халык күңлендә теләктәшлек таба.

Ул авазны яхшырак ишетергә омтылу бездә шагыйрь яшәгән урыннарга аеруча бер мөнәсәбәт тудыра. Ул урыннарда булган вакытта без, шагыйрьне чолгап алган табигать дөньясын, кайчандыр аныкы булган әйберләрне күреп, хыялыбыз белән үткәннәргә сәяхәт кылабыз, нәтиҗәләр ясыйбыз, бөек шагыйрьнең тормышын якыннанрак белергә, дөньяга аның күзләре белән карарга омтылабыз...

**II Төп өлеш.**

### II.1. Сосна Пүчинкәсе тарихы.

Эзләнү эшенә керешкәнче үз алдыма план – маршрут төземдем. Планның төп юнәлешләре: беренчедән, Тукай эзләре калган Сосна Пүчинкәсе авылы тарихы, Бибимәмдүдә язмышы белән тулырак танышу, икенчедән, Бибимәмдүдә каберенә зиярат, өченчедән, Арчадагы "Әдәбият һәм сәнгать" музеена сәяхәт, дүртенчедән, Кушлавыч авылына бару. Юлыбызны, әлбәттә, Сосна Пүчинкәсе авылыннан башлау бер дә гөнаһ булмастыр.(Сәяхәт фотосурәтләрдә бирелә).

«Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылымыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна нам карьянның имамына кияүгә чыкмыштыр» [1]

Без Тукайның "Исемдә калганнар" исемле истәлек – очеркыннан шушы юлларны, андагы шагыйрь әнисенең тиздән шушы авылда вафат булуы, шунда җирләнүе, кечкенә Габдулланың "яланаяк, яланбаш хәлендә, капка астыннан үкереп җылый – жылый йөгереп чыгып: "Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!" – дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганын укып үссәк тә, әле Сасна нам карьянның кайдалыгы, кабернең ни хәлдә саклануы турында киң җәмәгатьчелек бары Равил ага Фәхретдинның өзлексез эзләнүләре аша гына белә алды. Сосна Пүчинкәсе авылы Г.Тукай биографиясенә соңгы елларда килеп керде.

Г.Тукай турында басылган күп кенә хезмәтләрендә "Сасна нам карья"не (Сасна исемле авылны) Балтач районының Сосна авылы (Зур Сосна ) дип язып килделәр. Сасна авылы ничектер әдәбият белгечләре, Тукайчылар игътибарыннан читтә калды. Журналист Риф Якупов бу мәсьәләгә шактый әһәмиятле төгәллек кертте: республика Үзәк архивында һәм Балтач районы загс бүлегендә сакланган элекке документлар нигезендә, Тукайның әнисе Мәмдүдәнең Сосна Пүчинкәсе дигән авылның Мөхәммәтшакир атлы мулласына 1888 нче елның 22 нче декабрендә кияүгә чыкканлыгын һәм шул авылда 1890 нчы елның 18 нче январенда (яңа стиль белән 30 нчы январенда)
26 яшендә үлгәнлеген ачыклады. Кечкенә Габдулла исә Сосна Пүчинкәсенә
1889 нчы елның март – апрель айларында килеп, ягъни бер елга якын яшәгән.
Димәк, Тукай безнең авыл җирлегендә, аның чирәмле урамнарында, җиләкле тау буенда, саф һавалы йөзьяшәр наратлыгында үзенең илһамын, серле каләмен калдырган.

Сосна Пүчинкәсе (русча Починок Сосна – рәсми документларда шулай атала) үткән йөзнең урталарында Зур Сосна авылыннан күченеп утырган кечкенә генә авыл; баштарак Күчкән Сосна, Кече Сосна дип тә йөртелгән. Инеш буенда, яшеллеккә күмелеп утыручы, таза – таза йортлы, бүгенге көндә 37 хуҗалыктан торучы, бу матур авыл Балтач районының Г.Тукай исемле колхозы составына керә. Колхозга бу исем 1976 нчы елда, шагыйрьнең 90 еллык юбилее уңае белән, авыл халкының, колхозчыларның теләгеннән искә алып бирелә. Сосна Пүчинкәсе Казан артында Тукай тормышы белән бәйле булган, ул яшәгән дүртенче авыл ( вакыт ягыннан икенче: Кушлавыч – Сосна Пүчинкәсе – Өчиле Кырлай).

"Исемдә калганнар" исемле автобиографик әсәрендә: "Үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә", - дип искә алган. Фәкыйрә һәм мәнсез карчыктагы кадерсез көнкүрмештән соң, чынлап та, мәңге онытылмаслык җәннәт сые булгандар. Шунысы мөһим: Шакир мулланың умарталыгы, буыннан буынга күченеп, бүгенгесе көнгә кадәр саклана. Чәчәк исе, бал исе бәләкәй Апушның куанычлы көннәрен хәтерләтеп тора. Бу авылда ике генә вакыйганы - баллап ак күмәч ашавын һәм җылый – жылый әнисенең җәсәде артыннан йөгерүен хәтерли бит ул. Иң бәхетле һәм иң бәхетсез көннәрен! Мулла йорты күптән юк инде, урам якта ул утырткан карт тал гына аның истәлеген саклый. "Ризкы аз" ана белән бала да шушыннан үтеп йөргәннәрдер. Мәмдүдә абыстай үлгәч, Шакир хәзрәт Сосна авылыннан бер улы булган хатынга өйләнә. 1916 нчы елда, мулла үлгәннән соң, йортны шул үги малай үз авылларына күчереп салдыра. Истәлекле өй шунда бетә.

II.2. Бибимәмдүдәнең Сосна Пүчинкәсендә яшәү чоры тарихы.

Зиннәтулла кызы Мәмдүдәнең сабыен бер фәкыйрә карчыкка калдырып, Сосна Пүчинкәсенә кияүгә килү вакыйгасы кайберәүләрдә каршылыклы фикерләр кузгата. Ләкин бичара ананы аңлау өчен аның язмыш юлын һәркемгә
үзенә үтәргә кирәктер (тьфү – тьфү). Күңеленнән генә булса да! Үксез ана язмышы һәм шул үксезлек язмышы кабатланган бала язмышы...

Заманында Бибимәмдүдәнең Сосна Пүчинкәсе авылында яшәү чоры турында матбугатта күп кенә тавышлар, ямьсез “фараз”лар булды. Имеш, Шакир хәзрәт бик кырыс кеше булган, Мәмдүдәне кыйнап үтергән дигән сүзләр дә булды. Ләкин... Балтач районы архивында сакланган метрика кенәгәсендә Мәмдүдә абыстайның вафат булуы турындагы мәгълүматны Көшкәтбаш имамы Әсхетдин Ибраһимов теркәгән, үлү сәбәбен дә “эч китү” дип нәкъ ул язган. Ялган “фараз”ларга каршы кире каккысыз дәлил түгелме? Икенче дәлил булып, 1966 нчы елда Сосна Пүчинкәсе карты Галимов Гайнаннан язып алынган истәлек тора.

“Мин Габдулла Тукайдан өч яшькә кече, шунлыктан олылардан ишеткән кайбер нәрсәләрне әйтә алам. Беренчесе. Минем ишетүем буенча, Шакир мулла Мәмдүдә абыстайны җәберләп торган, хәтта аның үлүенә дә шул сәбәпче булган, дип язалар. Бу турыда минем Мәмдүдә абыстайда укыган, үзебезнең авылда туып үскән Вильдан кызы Гыйльмивафадан сораганым бар. Ул әлеге фикерне кире какты. Шакир мулла абыстайга (23 яшьлек) ишек алдына чыкканда да, перчатка кияргә куша иде, кулың ярылмасын, дип әйтә иде. Мулла абзый (69 яшьлек) аны бик ярата иде һәм тату яшиләр иде”,- диде.

Икенчесе. Минем әтиемнең энесе Мөхәммәтша Ибраһим улы, балалары булмау сәбәпле, хатыны белән сөйләшеп, Шакир хәзрәттән ятим калган Габдулланы үзенә балалыкка сораган, Ләкин мулла абзый: “Габдулланың бабасы да, әтисе дә муллалар булган, мин аны бабасына тапшырырга тиешмен”,- дигән. Шул ук Гайнан бабай һәм башка олы кешеләрдән, колхозның элекке председателе Х. Борһанов ишетүе буенча, Мәмдүдә абыстай бик чибәр булган, аны “матур абыстай” дип йөрткәннәр. Тукай үзе моңлы бала булып хәтердә калган, әнисе үлгәч тә, авылдан китәргә теләмәгән. Хәдичә апа Мөхәрләмова язып калдырган истәлекләр буенча, аның бабасы Нури Тукайны бик яхшы хәтерләгән, алай гына да түгел, Тукай шул авылда яшәгән елның җәй аен алар бергә уйнап уздырганнар. Нури олырак булса да, Габдулла аңа нык ияләшеп киткән, ә инде әнисе үлгәч: “Нури абый, мин сездә генә калыйм инде, әтиеңә әйт әле, зур үскәч, мин аның эшләрен дә эшләр идем”,- дигән. Димәк, Кушлавычның Шәрифә карчыкта кагылып – сугылып яшәвен онытмаган шушы үксез баланың каядыр кеше кулына барып керәсе килмәгәндер, күрәсең. Өчиледәге үги әбисенең “алты күгәрчене” арасында “бер чәүкә” булып кайтып керәсен сизгән диярсең... Нәни сабый Сосна Пүчинкәсендәге кебек бәхетле көннәрнең бүтән кабатланмаячагын йөрәге белән гүя сизгән диярсең....

Бибимәмдүдәнең Сосна Пүчинкәсендә яшәү чоры бары тик җылы истәлекләр белән генә телгә алына. Бәхетле көннәре бик аз гына булган шул. Аннан соңгы еллардагы Тукай язмышы күңелллләрдә бары тик авыр хатирәләр генә калдыра.

Тукайның әнисе белән аерылышу көннәрен болайрак күз алдына китерергә мөмкин булыр иде.

Каты авырып, Мәмдүдә урын өстендә, хәл әчендә ята, көннәр үткән саен хәле начарлана гына бара. Соңгы көннәре килеп җитүен сизенеп, әледән - әле Габдулланы янына чакыртып ала. Баласының башыннан сыйпап, көчсезләнгән куллары белән күкрәгенә кыса, күзләреннән үбә. Бала күңеле сизмәсен, дип күпме генә тырышса да, күз яшен яшерә алмый, күзләреннән мөлдерәп яшь ага... Булмады, бердәнбер баласын үзе үстерә алмады, нинди ятлар кулына гына калыр бу нарасый, сабый бала.... Соңгы күз яшьләре, соңгы үбү. Шушы үзәк өзгеч авыр вакыйганы Тукайның үз сүзләре белән тәмам итәсе килә: “...энкәмнең җиназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, үкереп елый – елый, йөгереп чыгып: “Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез! – дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (хәтерләвемне) язамын.

**II.3. Бибимәмдүдәнең каберенә зиярат .**

Тукай эзләре мине, ниһаять, әнкәсенең каберенә илтте. Яшь тирәкләр дә, йөзәр еллык мәһабәт агачлар да тынып калган. Йөрәк кенә гадәттәгедән катырак тибә шикелле. Каршымда Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә кабере. Өстенә зәвыклап эшләнгән биек кабер ташы куелган.Чак кына яндарак – кара кайгыдай кара таш. Анда Тукай шигыре уелган. Бибимәмдүдә абыстай, Тукайлар рухына дога кылып, баш иеп, күңелемнән кайбер хатирәләрне яңартам.

Бибимәмдүдәнең каберен ачыклау эшен якташ тарихчыбыз Равил Фәхретдинов, авыл картлары, хуҗалык җитәкчеләре башлап җибәрә. Авыл картлары Тукайның үги әтисе Мөхәммәтшакирның гаилә каберен, шул исәптән Мәмдүдәнең дә күмелгән җирен күрсәттеләр. Аларның сүзе тагын да олырак

булган картлардан язып алынган мәгълүматларга да туры килә. Тик, и ачы тәкъдир, бичара анага каберендә дә тыныч кына, догалар тыңлап кына ятарга язмаган икән. Әледән - әле гайбәт ишетеп тә борчыласы икән. Беренчедән, кабер тау өстендәге иске зиратта дигән фикер бар. Икенчедән, кабер авыл эчендәге зиратта дигән фикер бар. И Ходаем, "бу дөнья газап, кайгы, изү йорты" булу өстенә, мәгънәсез гайбәт йорты дамы әллә?"

Кабернең урынын ачыклап, таш куйдыру чорында биредәге Субаш авыл Советына Нурислам Газыймов җитәкчелек итә. Мин үземне кызыксындырган сорауларымны аңа бирдем."Ул елларда Сосна Пүчинкәсенең авыл тарихын әйбәт белгән берничә карты, мисалга, бик мөхтәрәм Гайнан абзый исән иде әле. Без алардан сорашып эшләдек. Мәмдүдә абыстайның кабере, һич бәхәссез, авыл эчендәге яңа зиратта",- диде ул миңа. Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтим: Г.Тукайның әнисенә мемориал проекты Махсус фәнни – реставрация мастерскоеның реставрация советында, Татарстан Язучылар союзы җитәкчеләре катнашында тикшерелә һәм бертавыштан кабул ителә. Мемориалның авторы – мастерскойның фәнни советы җитәкчесе, архитектор Рафик Билалов. Димәк, мөхтәрәм авыл картлары Мәмдүдә кабереңең яңа зиратта булуына тамчы да шикләнмиләр. Дәлилләре – мәгълүматлы Гайнан бабай сүзләре "Менә шушы ике кабер, һич хатасыз, Шакир хәзрәтнең ике җәмәгатенеке, кайсысы Мәмдүдә абыстайныкы икәнен генә әйтә алмыйм",- дигән ул. Киң җәмәгатьчелек истәлек ташын ике кабернең "яшьрәк" күренгәненә утырткaннар. Мәмдүдә абыстай җәсаде төп – төгәл шул таш турысында җирләнгәнме, әллә берәр карыш читтәме – рухына барып ирешсен өчен боларның бернинди аермасы юктыр, мөгаен. Догаларыбыз гына укылып торсын да рухын рәнҗетерлек сүзләребез генә ишетелә күрмәсен! Мәрхүмәнең изге рухы каршында тын гына баш ию – иң акыллы гамәлебез булыр, мөгаен.

Дөньяга бөек шагыйрьне биргән ана күмелгән һәм нигәдер югалып калган кабер минем өчен якын бер әйбер. Дөреслекнең тантана итүе күңелемә бер ышаныч, анага карата кадер – хөрмәт, заманында шагыйрь үзе куярга өлгерә алмый калган һәм гомеренең авыр бер чорында "Өзелгән өмид" исемле шигыренең соңгы юлларында кабер ташы турында тилмереп әйткән сүзләре тормышка ашты:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташың,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!"

**III. Йомгаклау**

Тикшерү эшемне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: мин бик бәхетле!. Беренчедән, минем авылым сукмагында нәни Апуш эзләре, Тукай илһамы калган. Икенчедән, бөек шагыйрьне тудырган ана кабере безнең якта. Өченчедән, һәр яз саен галиҗәнәп Шигырь бәйрәме безнең авылдан башлана. Дүртенчедән, Тукай рухы алдында баш иярге, Тукайны дөньяга бүләк иткән Изге Ана кабереңә зиярат кылырга, даһи Ана рухына изге догалар укырга күп кенә шагыйрьләр, язучылар, күренекле сәнгать осталары килә. Бишенчедән, Г.Тукай исемемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары безнең авылда игълан ителә. Алтынчыдан, шигъритебезне зурлау иманлы адәм балалары күңеленә һәр яз саен тагын бер яктылык, сафлык алып килә. Янәдән, Сосна Пүчинкәсендә кабаттан Мәмдүдә мәчете ачылды. Авыл өстен бар дөньяны яктыртып, пакьлап алтын ай балкый. Димәк, Бибимәмдүдә язмышында дөреслек тантана итә.

Г. Бәшировның "Җидегән чишмә" исемле әсәрендә "И Казан арты" дигән бүлек бар. Шунда әсәрнең герое язучы Камилнең туган авылына чираттагы кайтуында күргән – хәлләре, кичергән кичерешләре сөйләнә. Камил үзен озата килгән энекәшенә, еракта күренеп торган шәһәрчек уртасындагы күперне күрсәтеп, болай ди: "Янә дә килеп, әнә шул күпернең теге ягына, тауның иң биек урынына Тукай фигурасын куйдырыр идем. Яшь егет кыяфәтендә. Казанга барырга чыккан итеп"

Биредә Арча турында сүз бара. Тауны менгәч, күпер янында өч юл чаты бар. Берсе – Казанга, икенчесе Әтнә ягына китә, Кушлавыч яныннан уза, өченчсе Балтач һәм Кенәр якларына бара, - Кенәргә барганда Кырлай яныннан үтә. Балтачка борылсаң, Сосна Пүчинкәсенә илтә. Чыннан да, менә шул өч юл чатында, кулына кәрзинен тотып, Тукай басып торса? Ә һәйкәл куелган постаментта әлеге канатлы сүзләр дә язылган булса:

Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин....

Әлбәттә, минем юлым инде Тукай эзләре буйлап Арчага юнәлә. Гүя Тукай үзе дәшеп, чакыра сыман....

**Кулланылган әдәбият**
Тукай. Г. Исемдә калганнар.-Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1990 -3б.
Тукай Г. Әсәрләр, IV томда. Казан,1956 - 13б.
Исәнбәев С.Г. Тукайның замандашлары – Казан-1960-43б.
Р.Якупов -Казан утлары-1976-№3
Фәхретдинов Р. Бар күңелләрдән дә җылы...// Социалистик Татарстан – 1981 -16 июль.
Фәхретдинов Р. Үпкәнеңнән бирле, әнкәй...//Азат хатын-1982 №11-8-9 б.
Халит Г.Тукай үткән юл.//Тат. Кит. нәшр.-1962-228б.
Шәрәфиев Р. Ни сәбәптер, и Ходая, ризкы аз, гомре тәмам//Сөембикә2006

# ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА –
## татар милләтенең легендар шәхесе

*ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*
*ТҮБӘН УРЫСБАГА ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ*
*Эшне башкаручы: 8 сыйныфы укучысы Сиражиева Әдилә Илшат кызы*
*9 сыйныф укчысы Гимадиева Ләйлә Айрат кызы,*
*Җитәкче: Тарих укытучысы, китапханәче Фәсхетдинова Миннисa Нәҗип кызы.*

### I бүлек. Тема өйрәнүнең теоретик нигезләре
### 1.1Татар милләте тарихында Фәүзия Бәйрәмованың урыны

Фәүзия Бәйрәмова... Тарихчы, әдәбиятче - галимә, сәясәтче, нәфис сүз остасы, бөек демократ, җәмәгать эшлеклесе, милли хәрәкәт җитәкчесе, төрле милли оешмаларда оештыручы лидер, гаилә терәге, ике бала анасы...
Аның титулларын, исемнәрен санап, атап бетереп булмый.
Чынлап та, кем соң ул Фәүзия Бәйрәмова? Каян соң аның тамырлары?

Фәүзия Бәйрәмова 1950 елның 5 декабренда ТАССРның Саба районының Сабай авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, ул белемен башта Казанның театр училищесында, аннары Казан Дәүләт университетының филология факультетында дәвам итә (1983-1989)еллар. Профессиональ эшчәнлекне Фәүзия Бәйрәмова Казан телестудиясендә башлый. Соңрак ул китап нәшриятында эшли. Журналист һәм мөхәррир буларак, ул күп газета-журналларда яза.

1986 елда ул СССР язучылар берлегенә әгъза итеп алына.

1988 елда ул Татар иҗтимагый үзәгенең беренче корылтаенда катнаша, сәяси эшчәнлеккә кереп китә.

#### 1.1.1. Фәүзия әдибә

Фәүзия Бәйрәмова әдәбиятыбызга үткән гасырның сиксәненче еллар башында килеп керә. Аның беренче зур күләмле әсәре “Болын” “Казан утлары” журна-лында басылып чыга һәм укучыларда җылы кабул ителә. Әдәбиятыбыз аксакал-лары Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Фәрваз Миннуллиннар яшь язучының тәүге адымнарын хуплыйлар.

Бу китапка кереш сүзне язган әдәбиятебезнең олпат язучысы Әмирхан ага Еники менә ни ди:”..Фәүзия бик талантлы, һәм аның таланты гаять үзенчәлекле ... ул үзен һич аямыйча, гүя бөтен нервылары белән бик кабынып- кайнарланып яза... Көчле яза. Аны укыганда инде салкын, битараф калу мөмкин дә түгел. Килешәсеңме - килешмисеңме, яратасыңмы- яратмыйсыңнмы, ләкин барыбер аңардан аерыла алмыйсың. Укучы кәефенә җайлашып тормый ул! Күтәрелгән проблемасы һәм алган вакыйгасы белән дә ул, әйтергә кирәк, укучының йокысын калдыра... кыю керә тормышка. Бәйрәмова, һәр әсәрендә диярлек кеше язмышының фаҗигале якларын ача.. ул укучыны аяп тормыйча кешенең эчке җанына бик тирән үтеп керә” .

Ә Фәрваз Миннуллин:”Фәүзия Бәйрамова повестьларының һәркайсы мавыктыргыч һәм үзенчәлекле, һәркайсы үзенчә кызыклы. ”Болын” – “Битлек”кә, “Битлек”- “Чакырым баганалары”на охшамаган кебек, “Күл балыгы” әлеге өч повестьнең барысыннан да нык аерылып тора. Шул ук вакытта һәрберсе

дә Фәүзиячә кабынып-кайнарланып, дуамалланып язылган. Барысыннан да хис ташкыны бөркеп тора. Повестьларын укыганда, үзеңне әле кайнар җилләр искән ком чүлендә итеп сизәсең, әле бер-бер артлы ишелеп, тәгәрәшеп килгән диңгез дулкыннары уртасында калгандай буласың...”

Фәүзия Бәйрәмованың үз сүзендә нык тора белүе, халык тормышына битараф булмавы сәяси көрәшкә хәтле әсәрләрендә урын тапты. “Болын” повестендагы Алсуның Табигатькә – димәк, иркенлеккә, димәк Иреккә ни дәрәҗәдә гашыйк булуын күрсәтә. Болынны сукалап ташлаган Алмазга ни хәтле нәфрәт, ни кадәр ачу ташый яшүсмер Алсу йөрәгендә!

“Күл балыгы”н алсак, биредә инде тар даирәдә йомылып калу, түбән дәрәҗәдә мескенлек, коллык күренеше бик тә үтемле итеп тасвирланган.

Татар халкының бөек шагыйре Һади Такташ язмышына багышланган “Атылган йолдыз” драмасында да кешенең үз-үзенә хыянәте төп проблемпа итеп алына. Шагыйрь шәхесен шундый түбәнлеккә дучар итүчеләргә карата нәфрәт тудырыла.

Сәяси мәйданга, парламент трибуналарына чыкканчы Фәүзия Бәйрәмова иң элек үзенең әсәрләрендә көрәш тәҗрибәсе туплаган, үзенең һәм үзен тудырып үстергән татар милләтенең язмышына битараф булмавын әсәрләре аркылы күр-сәткән язучы була. Аның беренче китабы “Болын” 1986 елда дөнья күрә, ә инде 1991 елда “Моң” исемле икенче китабы басыла. Язучы Айдар Хәлим әйтүенчә ул әдәбиятка “символ” төшенчәсе алып килә.

Шул ук 80 елларда Фәүзия Бәйрәмова драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Аның “Аллалар ялгышы яки яңа матриархат”, “Һәркемгә бер кояш”, “Атылган йолдыз”, “Сандугач балалары”, “Безне онытмагыз” һ.б. драма әсәрләре языла. Бу әсәрләр Минзәлә татар дәүләт драма театрында, Казандагы яшьләр театрында һ.б. куела, Казан телевидениесеннән күрсәтелә. 1998 елда “Безне онытмагыз” дип аталган пьесалар җыентыгы Татартстан китап нәшриятендә дөнья күрә.

Фәүзия Бәйрәмова, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, шәхес культы елларының корбаннары булган татар хатын-кызларының язмышларын өйрәнә, бу хакта әдәби һәм документаль әсәрләр тудыра, «Кыңгырау» дигән повестен һәм «Безне онытмагыз» пьесасын иҗат итә, бу хакта дистәләгән публицистик мәкаләләр яза, телевизион тапшырулар эшли.

Фәүзия Бәйрәмованы әдәби тәнкыйтьче буларак билгеләп үтми булмый. Аның хезмәтләре нәтиҗәсендә Һади Такташ язмышы һәм рус тарихчысы Михаил Худяков хезмәтләре турында ул күләмле фәнни-публицистик һәм тирән эчтәлекле мәкаләләр язып чыгара.

Аның язмаларында татар халкының тарихи үткәне, бүгенге хәле һәм киләчәк язмышы ислам дине тәгълиматы күзлегеннән торып карала, кеше шәхесенең рухи дөньясы, чынбарлык белән даими бәйләнеше Коръән, шәригать канун-нарына таянып аңлатыла. Бу темага авторның махсус балаларга атап язган хезмәтләре дә бар. Мәктәп укучыларына ислам дине нигезләрен аңлаткан «Бәхет ачкычы» (2002) китабы, балаларны иманга, әхлакый сафлыкка чакырган «Алыплар илендә» (2002) исемле маҗаралы повесть әнә шундыйлардан. Ул шулай ук балаларны борынгы болгар-татар рухи һәм матди ядкәрләре белән таныштырган «Сәнгать дөньясына сәяхәт» (1989) исемле фәнни-популяр китап авторы буларак та билгеле.

1994-1995 елда “Аргамак” журналында бастырылган “Кара урман” әсәре өчен Фәүзия Бәйрәмова Сажидә Сөләйманова, ә 2001 елда шушы әсәре һәм «Соңгы намаз» романы Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек була.

Тарихи романнарны язучылар : Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Вахит Имамов һ.б. арасында ул бердәнбер хатын-кыз.

Язучылар берлеге идарәсе утырышларында берничә тапкыр аны Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим итә, ләкин аның кандидатурасы яшерен тавыш биргәндә төшеп кала торды. “ Фәүзия, горур шәхес буларак, андый бойкотларга исе китми, ялынып-вакланып йөрми — эшлисен эшли, язасын яза бирә. Мин аның язганнарын даими укып барам. (Даими укып барган язучыларым

биш-алтыдан узмый). Язганнарына бәям югары. Талантлы кызыбыз, чын көрәшче шәхес, кыйбласы төгәл билгеләнгән”- ди шул уңайдан Туфан Миннуллин.

### 1.1.2. Фәүзия сәясәтче

80 еллар ахырында Татарстан да, татар халкы да үзенең бәйсезлеге өчен көрәш башлагач кайнар йөрәкле иҗатчы Фәүзия Бәйрәмова бу көрәшнең үзәгендә кайный. Бер төркем мииләтпәрвәрләр белән бергә ул 1988 елда Татар иҗтима-гый үзәген оештыра һәм 1991 елга хәтле бу оешманың рәис-координаторлары-ның берсе була. Ә инде 1991 елда ул “Иттифак” милли бәйсезлек партиясенең рәисе итеп сайлана. 1994-1997 ел арасында ул Милли Мәҗлес рәисе булып эшли. Аның инициативасы белән “Татар кануны”, “Гаилә кодексы” кебек мил-ләт өчен мөһим булган зур хезмәтләр эшләнә һәм халыкка җиткерелә. Аны хәтта татарның “Җанна д, Арк»ы дип тә йөретәләр.

1990 елда Фәүзия Бәйрәмова Саба районыннан Татарстан Югары Советына депутат булып сайлана һәм 1995 елга хәтле республика парламентында тынгы-сыз эшчәнлек алып бара. 1991 елның җәендә Татарстанның мөстәкыйльлеге, суверенлыгы өчен көрәштә ул Татарстанда Рәсәй президентын сайлатмас өчен , ундүрт көнлек ачлыкта тора һәм аны халык массалары урындыгы белән күтәреп югары совет залына алып керәләр. Ельцин Татарстанда президент булып сай-ланмый кала. Ул шул еллардан башлап төрки-мөселман халыклары мәсъәлә-ләре буенча уздырыла торган зур халыкара корылтайларда, конгрессларда катнаша һәм чыгыш ясый.

1990 елда Германиядә, 1991 елда Бельгиядә һәм Голландидә, 1992 елда Америка Кушма Штатларында, 1991-1998 елларда Төркиядә, Кипрда, 1996 елда Даниядә уздырылган форумнарда делегатлар аның чыгышын тыңладылар.Ул хәзер дә Кавказ, Кырым, Себер, Алтай, Идел буе, Австралия төркиләре белән тыгыз элемтәдә. Ул бүген дә актив иҗади тормыш белән яши, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга катнаша, һаман да милләтебез мәнфәгатен кайгыртып йөри.

“Сөбханалла, кайларга гына барып чыкмаган ул. Әгәр дә Галимҗан Ибраһимов исән булса, теге заманда язган «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясен ертып ташлар да, бүгенге татар хатынының күргәннәрен исе китеп, сокланып язар иде. Мин үзем дә йөрим татар арасында, мин дә күрәм Фәүзия күргәннәрне, мин дә сөенәм, мин дә көенәм, ләкин язганнарым фәнни дәрәҗәгә күтәрелә алмый, күрәсең, мин тарихчы галим түгел. Фәүзия Бәйрәмова татар тормышын бүгенгесе һәм үткәне белән бәйләп карый, еш кына ул тарихка, тормышка галимнәр карашыннан күз сала. Бу аның күп укуын, тирән мәгълүматлы булуын раслый торган факт. Фәүзиягә тикшерү оешмаларыннан туктаусыз бәйләнеп торалар, ләкин гаепләрлек фактлар таба алмыйлар, чөнки аның һәр җөмләсе, һәр сүзе фактлар белән исбатланган була”- дип язган иде Туфан ага Миннуллин.

“Чигенергә хакыбыз юк, артыбызда милләт язмышы”- ди Фәүзия Бәйрәмова.

### 1.1.3. Фәүзия тарихчы.

Фәүзия Бәйрәмованың эшчәнлегенең төп эчтәлеген татар халкын уртак милли тормышка туплау мәсъәләсе алып тора һәм ул моңа тарихны тирән өйрәнү аша килә. Русның намуслы һәм затлы тарихчысы Михаил Худяков мирасын җентеклеп өйрәнеп, ул татар тарихын дөрес яктырткан өчен репрессияләнгән галимнең исемен яңадан фәнгә кайтара һәм аның турында “Михаил Худяков и итория татарского народа”, “Михаил Худяков и историко-культурное наследие народов Поволжья” дигән искиткеч тирән хезмәтләр язып бастырып чыгара. Кандидатлык диссертациясен дә ул Михаил Худяковның “Очерки по истории Казанского ханства” дигән атаклы, ләкин бүгенге көнгә хәтле бикләнеп торган хезмәтенә, тарихчының тормыш һәм иҗатына багышлый.Фәүзия Бәйрәмова туктаусыз хәрәкәттә, татар халкы тупланган өлкәләргә бара, милли активистлар белән очраша, музейларда өйрәнә, архивларда казына. Ул үзе җыйган мәгълүматлар һәм материаллар буенча фәнни хезмәтләр, китаплар яза һәм аның китаплары кызыксынып укыла.Аның бер урынга унар тапкыр да барганы бар. Өйрәнгән төбәкләре Себерне алсак, Тубыл, Төмән, Омск, Томск, Курган һәм Чиләбе өлкәләре, Пенза һәм Мордовия, Кыргызыстан һәм Башкортстан һ.б.

Татар халкының батыр улы Батырша турында “Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше” дигән басма 2005 елда Чаллыда бастырылды. “Ачылмаган татар тарихы” дигән китабы 2011 елда

бастырыла. Аның тарихи очеркы “Чәрдан ханлыгы”, 2008 елда бастырылган “Туран иле”, 2006 елда чыккан “Алтын Урда – Алтын илем”, 2014 елда чыккан “Сахалин утравы һәм татарлар” күләмле зур әсәрләр.

“Дала Атлантидасы” дигән китабы хезмәт ике телдә төсле фотолар белән басылган. Чиләбе өлкәсендәге атом катастрофасы турындагы китабы өч телдә: татар, рус һәм алман телләрендә дөнья күрде.

Күпсанлы сәяхәтләре һәм кызыклы тикшеренүләрен ике концепциягә нигезләп алып бара. Аларның берсе: “**Төбәк тарихы – милләт тарихы”** һәм икенчесе **– “Бөтен Русиягә сибелеп утырган татарлар һич тә диаспора түгел, алар һәр җирдә үзләренең борынгы ватаннарын дәвам итә”.**

### 1.1.4. Фәүзия мөслимә.

Фәүзия Бәйрәмова тормышының иң авыр вакытында Аллаһы Тәгаләгә юнәлә. Үзенең дингә килүен ул менә ничек тасвирлый: “Бөтен ишек ябылды, берәү генә ачылды – Аллаһы ишеге”, – дидем һәм намазга тезләндем. Яңадан яшәсәм дингә иртәрәк килер идем. Телләр өйрәнер идем. Дин Аллаһы белән аралашу өчен кирәк булса, тел дөнья белән аралашу өчен кирәк. Үземне-үзем оештырып йөрмәсәм, әллә кайчан беткән булыр идем. Аллаһы Тәгаләдән кешегә күпме энергия, күпме гомер, күпме гамәл салынган, ул чыгып бетәргә тиеш. Менә шул Аллаһыдан бирелгән көч-куәт чыга да миннән”.

Ул 1998 елда фарыз гамәл- хаж гамәлен үти. Һәм шуның нәтиҗәсе буларак “Казан утлары” журналының 10, 11 саннарында ул “Хаҗ көндәлеге”н бастырып чыгара. “Бу көндәлегемне халыкка җиткерүнең төп сәбәбе- башкаларны да Хаҗ белән кызыксындыру, күңелләрендә изге урыннарга карата мәхәббәт уяту, аларны Ислам диненә тарту, иманга чакыру...Аллаһы ризалыгына ирешү”- ди автор. Шушы тематика буенча ул “Соңгы намаз” (2000), "Ислам яшәү рәвеше." (2004) китапларын яза. Аның «Гасырларга тиң фаҗига», «Гасыр һәм кеше», «Заман. Милләт. Кеше.» трилогиясенә кергән «Заман кемнең заманы? », «Без нинди милләт? », «Коръән һәм кеше күңеле», «Хаҗ көндәлеге», «Сайлаган юлың дөресме?» дигән һәм вакытлы матбугатта дөнья күргән күп кенә бүтән әдәби-дини язмалары Фәүзия Бәйрәмованың татар әдәбиятында өр-яңа жанрга — рухани әдәбият жанрына нигез салуы турында сөйли.

“Юк, мин беркайчан да бәндәдән курыкмадым, үземнең хаклы икәнемне белсәм, беркайчан да чигенмәдем, хәзер дә шулай булып калам. Адәм баласы бары тик Аллаһтан гына куркырга һәм аның алдында гына башын иярgә тиеш!- ди Фәүзия апа.

### I.2 Татар милләтенең бүгенгесе һәм Фәүзия Бәйрәмова

Фәүзия Бәйрәмова, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе: бүгенге көндә дә тулы көч белән халыкка хезмәт итә. Ул хәзер дә актив, һәрвакыт халык арасында. Әле күптән түгел генә Чыңгыз Айтматовның әнисе турында “Ана” дип аталган китап язды һәм ул китапны тәкъдим итеп үзенең туган ягында, республикабыз районнарында очрашулар үткәрде.
Камал театрының кече сәхнәсендә “Калеб” яңа буын җыены кысаларында “Яңа дулкын” исемле яшь иҗатчыларның шигъри бәйгесендә жюри составында булган Фәүзия Бәйрәмова менә нәрсә диде:“Татар яшьләре шигырь язып, шигырь укырга җыелганнар икән, димәк, милләт бар, милләт яши! Менә бүгенге көнгә аларның иң зур савабы шушы булды! Милләт дигән бөек әйбер бар. Әгәр милләт турында шигырьләр белән без халыкны уята алмыйбыз икән, милләткә өлеш кертмибез икән, дөньяда безне танымаячаклар! Без дөньяда бары тик “татар” дигән йөз белән, татар милләтен генә күтәреп чыга алабыз! Бу очрашудан мин бик канәгать калдым”.

### Нәтиҗәләр.

Меңләгән ирләр эшли алмаган эшләрне хәзер дә Фәүзия Бәйрәмова башкарып килә, гәрчә аңа “милләт-милләт” дип тырышып йөргән көенә кайчак мәхкәмә буенда йөрергә туры килсә дә. Ул һаман иҗатта, ул һаман көрәштә. Фәүзия Бәйрамова һаман “Милләтем-милләтем”- дип кайгырта.

## II. бүлек. Тема өйрәнүнең практик нигезләре

Быел без конференциянең яңадан буласын белгәч, февраль ае буе Фәүзия Бәйрәмова иҗатын әдәби китаплары буенча, өлешчә аның фәнни эшчәнлеген язма басмаларыннан, сәяси эшчәнлеге турында мәгълүмәтне мәктәп китапханәсеннән, Түбән Урысбага мәдәният йортында урнашкан авыл китапханәсеннән, укытучыбызның шәхси китапханәсеннән, интернет челтәреннән алып фәнни эш әзерләдек һәм аны сезнең хөкемегезгә тапшырабыз. Әлеге хезмәтебезне әзерләгәндә, нигездә, анализлау һәм тикшерү методлар кулланылды.

**2.1.Эзләнү** юнәлешләре

Бу фәнни эш – язмабыз күмәк эш нәтиҗәсе. Теманы сайлагач материал җыйган вакытта иң баштан Татарстан тарихы буенча булган мәктәп китапханәсендәге дәреслекләрне барлап өлешчә материал тупладык. Мәктәп китапханәсендә булган журнал, газеталар барланды. 1997 елдан башлап сакланган “Казан утлары”, “Мирас” журналларыннан алып соңгы айларда чыккан газета “Татарстан яшьләре” журналлардан , китапханәдә булган Фәүзия Бәйрәмованың китаплары, шәхси китапханәләрдән алган китаплар - "Болын" "Моң", "Күңел карлыгачларым", "Ачылмаган татар тарихы" , “Соңгы намаз” кулланылды. Шулай ук шактый материал интернет челтәреннән алынды.

**2.2. Эзләнү нәтиҗәләре**

Эзләнү нәтиҗәләре буларак анализ ясап, системага салынган язма фәнни эш әзерләнде. Барысы “Казан утлары” журналының 17 санына, “Мирас” журналына анализ ясалды, интернет сайтлардан 22 язма файдаланылды. Хәтта телефонга ватсабка килгән хәбәрләрне дә кулланып теманы күбрәк ачарга тырыштык.

**2.3. Нәтиҗәләр**

Эзләнү нәтиҗәсендә шушы фәнни –эзләнү эшен язарлык һәм шушы эшне күрсәтерлек презентация һәм доклад әзерләнде.

**Йомгаклау**

Фәүзия Бәйрәмова әле һаман эзләнүдә. Күптән түгел генә ул “Соңгы Туранчы” дигән китабын язды һәм шул уңайдан менә нәрсә диде:”Әйе, Һади Атласи – ахырга хәтле татар халкының азатлыгы өчен көрәшкән, гомере буе төрки халыкларны берләштереп, бер бәйсез дәүләт төзү хыялы белән яшәгән, шуңа омтылган, шушы уй-гамәлләре өчен гомере белән түләгән соңгы туранчы ул..”

Бөтен Рәсәй җәмәгатьчелеген, матбугатын шаулаткан: Мордовиянең Белозерье мәктәбендә кыз балаларының яулыкларына бәйләнгән вакыйгага да ул үз фикерен белдерде: “Татар хатын-кызлары беркайчан да яулыксыз да йөрмәгән, чөнки чәч-башны каплау, гаурәтне каплау –Аллаһның әмере! ТНВ каналында күрсәтелгән провокацион сюжетның төп мәгънәсе шуңа кайтып калды - җәмәгать урыннарында дини киемнән йөрү дөрес түгел, шуңа күрә Белозерье мөслимәләре яулыкларын салырга тиеш икән. Татарстан, татар конгрессы, диния нәзәрәте бу очракта беръялгызлары көрәшүче милләттәшләребезгә ярдәм итәргә тиешләр.

**Кулланылган әдәбият.**

Әхмәтова Г. Фәүзия Бәйрәмова драмалары. Шәһри Казан. – 2004. – 13 авг
Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 1 т. Казан Татарстан китап нәшрияте, 2009
Әйди Т. Хакыйкатькә яңа адым. Казан утлары. – 1990. – № 10. – 139 б.
Әхмәдуллин Ш. Рәхмәт, Фәүзия сеңелем! Ш.Әхмәдуллин. Яңа гасырга атлаганда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 169–174 б.
Бәйрәмова Ф. Кыска хикәяләр. Казан утлары.1997, -№- 1. 130-135 б.
Бәйрәмова Ф. Тәгәри китте йомгагым. Казан утлары.1998, №9,127-145б.
Бәйрәмова Ф.Тәгәри китте йомгагым. Казан утлары.1998, №10,132-148 б
Бәйрәмова Ф. Караболак. Казан утлары.- 2005, -№- 11. 10-59 б.
Бәйрәмова Ф. Соңгы Туранчы Казан утлары.- 2016, -№- 8.
Бәйрәмова Ф. Болын. 1986,
Бәйрәмова Б . Моң. 1991,
Бәйрәмова Ф. Ачылмаган татар тарихы. 2011.
Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы. Казан утлары. 2016 ел, № 8
Вәлиев М. Фәүзия Бәйрәмова белән әңгәмә. М.Вәлиев. Тукайлар рухы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 61–74 б.
Дәүләтшина Л. Киләчәккә күз төбәп. Казан утлары. 2005. № 9.154–158 б.

Дунай Ф. Сөюнең сынаулары бар. Казан утлары. 1987. № 5. 151–155 б.
Закирҗанов Ә. Онытырга хакыбыз юк. Казан утлары.2000. № 8.137–141б
Ихсанова В. Таралып яткан Татар Иле .Шәһри Казан. – 2004. – 25 июнь
Исхакова К. Кырык сырт»ны кичкән татарлар. Татар иле. 2006. – № 11.
Миначев М. Талант фаҗигасе – милләт фаҗигасе Идел. 2003. № 2. 78 б.
Сверигин Р. Гасырлар чатында. Казан утлары. –2002. – № 4. 150–152 б.
Хәлим А. Бирегез мәйдан! Мирас. – 2003. – № 2. – 13–20 б
Хәлим А. Гаделлек сагында Мирас. – 2000. – № 12. – 49–53 б.
Хисамов Н. Милләт гаме белән янып. Казан утлары.2015, № 12.143-145 б
Хисмәтуллин Р. Саф дин җилләре. Шәһри Казан. – 2002. – 12 апр
Интернет ресурслар.

# «Оборванная пулей песня…»
# (Жизнь и творчество выдающегося татарского композитора Фарида Яруллина)

*МБОУ«Нурлатская СОШ Зеленодольского муниципального района РТ»*
*Выполнила: Хайруллина Инзиля Рамисовна ученица 10 А класса*
*Научные руководители: Ягудина Р.И., учитель русского языка,*
*Абзалова С.С., учитель обществознания*

## Глава 1.Путь к большой музыке

Каждый человек рождается для того, чтобы оставить в жизни свой след, а в народе - добрую память.

Композиторы Яруллины вошли в историю татарской национальной музыки как яркие и талантливые личности. Отец - Загидулла Яруллин (1888-1964) - был народным музыкантом-самоучкой. Оба его сына тоже стали известными композиторами.

Фарид Яруллин родился 1 января 1914 года в Казани. Мальчик рос среди музыки, с детства впитывая звучание народной песни. Изредка на свои выступления его отец, Загидулла Яруллин, брал с собою сына. Эти вечера оказывали сильное эмоциональное воздействие на мальчика и определили его дальнейшую судьбу. Глядя на отца, он тоже мечтает стать музыкантом.

Мирсаид Загидуллович Яруллин (1938 года рождения), младший брат Фарида, окончил Казанскую консерваторию, аспирантуру при консерватории. Он известный композитор, педагог, заслуженный деятель искусств РСФСР, Каракалпакской АССР и Татарской АССР, директор Дома композиторов республик, Поволжья и Приуралья. В 1977-1989 годах - председатель союза композиторов ТАССР. Мирсаид Яруллин - учредитель музея Фарида Яруллина в селе Малая Сунь Мамадышского района.

В 1923-1930 годах семья Яруллиных проживала в Уфе. С ранних лет Фарид тянулся к музыке. Отец научил его играть на мандолине, скрипке, в десять лет мальчик сел и за пианино. Уже тогда он мечтал стать композитором, все серьезнее занимается музыкой самостоятельно.

Фарид Яруллин в Уфе учился в татарско-башкирской школе, где большое внимание уделялось литературе, пению, рисованию. Из ее стен вышло много замечательных деятелей культуры и искусства, среди которых балетмейстер Гаскаров, писатели А. Файзи и Р.Саттар, артистка З.Бикбулатова, художник Р. Гумер. В этой школе преподавал известный татарский писатель Н. Исанбет.

В 1930 году Фарид поступил в Казанский музыкальный техникум по классу виолончели к Р. Л. Полякову и параллельно занимался по классу фортепьяно у М. А. Пятницкой, которые считались лучшими педагогами в Татарстане.

Через два года (1933 год) Рувим Львович Поляков, разглядевший выдающиеся способности Ф. Яруллина, отправляет его в Москву для учебы в консерватории. В Москве талантливый юноша продолжает образование сначала на рабфаке при Московской консерватории (1933—1934 гг.) в классе сочинения Б. Шехтера, затем в Татарской оперной студии (1934—1939 гг.) и в Московской консерватории (1939—1940 гг.) в классе композиции профессора Г. Литинского, который стал для молодого композитора наставником и другом.

Фарид быстро овладевает профессиональным композиторским мастерством. В годы учебы сочиняет песни, романсы и инструментальные миниатюры и крупные произведения: сонату для виолончели и фортепьяно, струнный квартет, симфонию. Работа над различными по жанру произведениями способствует интенсивному творческому росту композитора. Уже тогда начал определяться его яркий творческий облик как композитора.

***«Мне очень близок стиль композиторов - романтиков, но истоки этой музыки – в Татарии, в творчестве моего народа»,*** - говорил он.
Прекрасно зная и чувствуя народную татарскую музыку, Фарид Яруллин сумел выработать на ее основе своеобразный и самобытный музыкальный язык.
В это время он пишет две симфонии, на слова А.С.Пушкина создает романсы «Цыган» и «Не пой, ты, моя милая», романс «Почему» на стихи Х. Такташа, а также начинает работать над оперой «Зульхабира».

Сохранились 15 песен Фарида Яруллина, среди них «Комсомолка-партизанка», «Годы 20-е», «Летчик», «Марш Тельмана», «На смертный бой» на слова Мусы Джалиля и др. Но главный труд композитора в период учебы – это балет «Шурале». Мысль о воплощении в музыке поэтической сказки "Шурале" Г.Тукая родилась у него в 1937-1938 годы.

Ф. Яруллин хорошо знал и любил поэзию Г. Тукая, в ней черпал вдохновение для своего творчества. Оставив недоработанной оперу «Зульхабира», композитор увлеченно берется за создание первого татарского балета «Шурале» на либретто классика татарской поэзии Г. Тукая.

«Шурале» - сказочный балет, повествующий о девушке – птице Сююмбике, попавшей в логово Шурале, и юноше Былтыре, спасшем ее от лесного чудища. В произведении выражена традиционная для сказочного сюжета идея борьбы человека с темными силами природы, и воспевается всепобеждающая сила любви, преодолевающей все препятствия.

«***Сколько там прелести, искренности, правдивости, кажется само «волшебство» влечет нас к этому удивительному сочинению, ставшему лебединой песней композитора»,*** - писал музыкант Д. Садрижиганов.

## Глава 2. Оборванная пулей песня

Просмотр законченного варианта балета «Шурале» был назначен на 22 июня 1941 года, которому не суждено было состояться: за несколько минут до представления в кулуарах театра из репродуктора прозвучало сообщение о том, что началась война. Мечта автора балета осталась неосуществленной. Война перевернула все его планы, замыслы, всю молодую жизнь. Фарид Яруллин — восходящая звезда татарского искусства так не увидел своего шедевра.

В первые дни войны Ф. Яруллин создает яркую песню, призывающую народ на борьбу с врагом. «В смертный бой» называется эта последняя «лебединая» песня композитора-патриота, написанная на стихи поэта-героя Мусы Джалиля. Уже 13 июля 1941 года она была опубликована в газете «Красная Татария».

24 июля 1941 года композитор получает повестку из военкомата. Двадцатисемилетний Ф.Яруллин становится солдатом Советской Армии. В письме к отцу он признается: ***«…Я бы желал лишь только одного – быть полезным Родине в её борьбе против озверелого фашизма».***

Молодая жена Фарида, Галина Сачек, и маленькая дочь Наиля больше никогда не увидят своего самого родного человека.

Военные дороги сначала привели Фарида в Ульяновское пехотное училище. После четырех месяцев обучения его направили на фронт командиром пулеметной роты.

В Министерстве обороны СССР личное дело Фарида Загидулловича Яруллина не сохранилось. О его боевом пути можно было судить только по письмам к жене и дочери.

Письма от Фарида приходили редко: два-три в 1941, около 8 — в 1942 году. В одном из них, датированном октябрем 1942 года, Фарид называет свое местонахождение «самой горячей точкой» фронта. Это была оборона Сталинграда.

В феврале 1943 года он в своих письмах упоминал город Орел, в марте того же года — Курскую дугу, деревню Альховка. После письма, датированного 31 июля 1943 года, связь Фарида Яруллина с семьей оборвалась.

Композитор служил в 250-м стрелковом полку 82-йстрелковой дивизии в должности командира пулемётной роты. Ф. Яруллин был участником Курской битвы. В письме к жене 31 июля 1943 года, после завершения Курской битвы, он писал: ***«Прочь… иллюзии о музе! Настоящая музыка была здесь, когда шестнадцатиголосая контрапункция «Катюши» в ансамбле с «Лука – Лукичом» и «Марфушей» в общей симфонии рёва воздушных и наземных богатырей подняли вверх тормашками всех головорезов Гитлера. Такую симфонию я ещё не встречал ни в одной музыкальной литературе мира!»***

Находясь в самом пекле войны, Фарид Яруллин продолжал мечтать о постановке своего любимого детища, балета «Шурале», на сцене театра. В письме супруге из Ульяновска от 3 сентября композитор спрашивает, готовится ли балет к премьере. По-видимому, от нее получил ответ, что постановка состоится 20 сентября, т.к. в письме от 7 сентября он просит ее прислать рецензии на премьеру балета. По содержанию следующего письма от 3 октября выясняется, что премьера не состоялась. Причину определить довольно трудно. Композитор пишет: «***Я очень расстроен, что со II действием произошла такая неприятность***».

Балет Ф.Яруллина "Шурале" впервые был поставлен 12 марта 1945 года и поныне продолжается его постановка на сценах театров мира.

Через год в письме от 5 ноября 1942 года Ф. Яруллин пишет, что заболел тифом и 4 месяца лежал в госпитале в г. Куйбышеве, где он встретился с балетмейстером П. Гусевым. В этом же письме сообщает, что командование военной части предоставило ему 2-дневный отпуск, чтобы поехать в Саратов, куда была эвакуирована Московская консерватория.

Основная причина поездки – увидеться со своим любимым профессором Г.И. Литинским. В своих воспоминаниях Г.И. Литинский очень тепло пишет о Ф. Яруллине. Он обратился к руководителю военного факультета Московской консерватории комбригу А.Е. Гутору помочь отозвать Ф. Яруллина из фронтовой военной части. А.Е. Гутор тут же связался с командованием части, где служил Ф. Яруллин, и получил согласие на его перевод на военный факультет консерватории.

Для оформления бумаг понадобилось две недели. Однако композитору не суждено было дождаться перевода: он был отправлен на передовую фронта.

По воспоминаниям его однополчанина Дмитрия Самойлова, они летом 1943 года приняли участие в самых огненных боях под Курском. После освобождения Курска их дороги разошлись. «Наш корпус, – вспоминал Д. Соколов, – отправили эшелоном на юг, в Ново-Фоминск». В боях у Перекопа он был ранен, и после ампутации руки его комиссовали, а Ф. Яруллин ушел с 16 танковым корпусом на запад, где через два месяца погиб в бою.

Дмитрий Сергеевич Соколов, доктор технических наук, зав. кафедрой одного из Московских институтов, приезжал в 1984 г. в Казань на празднование 70-летия Ф. Яруллина. «Я впервые встретился с ним в марте 1943 года, – вспоминал Д.С. Соколов в своем выступлении. Он остался в моей памяти открытым человеком и очень смелым как командир взвода. Однако в отличие от других бойцов отличался интеллигентностью. Однажды я застал его сидящим на пеньке, а на другом пеньке он перебирал быстро пальцами. На мой вопрос, зачем он это делает, ответил, что он музыкант. Поскольку для нас слово «музыкант» ограничивалось понятием «гармонист»,- вспоминал Д. Соколов,- мы тут же нашли гармонь и принесли ему. Фарид улыбнулся и покачал головой, сказав, что он композитор. Этот его ответ мы тогда толком и не поняли.

Как-то, будучи студентом,- продолжал рассказывать Д. Соколов, – я увидел в Москве афишу Большого театра о постановке балета «Шурале» композитора Фарида Яруллина. Вспомнил младшего лейтенанта роты, которой я командовал. Однако тогда решил, что он тезка композитору, т.к., во-первых, я уже знал, что лейтенант погиб в 1943 г., а балет был поставлен в 1950 г., во-вторых, я подумать даже не мог, что автора такого выдающегося произведения могли отправить на фронт».

Дмитрий Сергеевич во время выступления повернулся к президиуму и с горечью воскликнул: «Как вы могли отправить на фронт такого гениального композитора!»

Удивительно, что композитор и на фронте не оставлял свое творчество.

Г.И. Литинский вспоминал, что при встрече Ф. Яруллин сыграл ему фрагменты из сюиты для симфонического оркестра, отдельные номера кантаты на собственный текст, посвященной Великой Победе. Рассказал ему о планах написать инструментальные концерты для скрипки, виолончели, детские песни для доченьки Наили.

Нет сомнения в том, что фашизм был бы побежден и без участия младшего лейтенанта Ф. Яруллина, а вот татарское музыкальное искусство в лице композитора такого яркого дарования очень многое потеряло.

Для того, чтобы оценить талант Фарида Яруллина, достаточно посмотреть балет «Шурале», послушать его задушевные песни. А вот, чтобы понять, каким он был человеком и гражданином, надо всего лишь прочитать его письма с фронта. Сколько в этих наспех набросанных строках нежности, доброты, трогательной заботы об отце, жене, дочке и друзьях, сколько патриотизма, мужества и веры в победу!

Мужественный воин-патриот, готовый отдать жизнь за Родину, любящий сын, муж и отец — таким предстает в них Фарид Яруллин. Фронтовые письма поведали о том, как тосковал он по своим родным — отцу, жене Галине и Наилюшечке — так ласково называл он свою дочурку. Из писем мы узнаем, что и на фронте Фарида Яруллина не оставляли мысли о судьбе своего балета «Шурале». ***«Как бы мне хотелось увидеть его на сцене. Хотя бы одним глазком… Музыка его во мне и всегда со мной»,*** — признавался Фарид в одном из последних писем к жене.

***«...Гроза, нависшая над нашим существованием, требует от нас всех максимального напряжения. В нашей победе не сомневайся.»*** (из письма к жене 1943 г.) ***«…еду на фронт бить заклятого врага***.» (из письма к отцу 1941 г.). ***«…Я бы желал лишь только одного – быть полезным Родине в ее борьбе против озверелого фашизма».*** (из письма к отцу 1942г.)

Жена, балерина Галина Сачек, и дочь Наиля не знали ни дня смерти, ни места гибели Фарида Яруллина.

Поисками места гибели композитора занимались его родные и близкие, а также земляки, участник освобождения Беларусии- И.Б.Хасанов и заслуженный работник культуры Татарской АССР Т. Ш. Шайхиев. Они и решили «пройтись» по боевому пути тех воинских подразделений, где служил Фарид Яруллин.

Воины 250-го стрелкового полка 82-й стрелковой дивизии принимали участие в освобождении Смоленской и Витебской областей. Именно здесь и служил Фарид Яруллин. Они и нашли его имя в списках офицеров, погибших в районе небольшого белорусского городка Дубровно на Витебщине. Стало известно, что похоронен Фарид Яруллин на кладбище деревни Новая Тухинь 17 октября 1943 года. На этом месте позже установили мемориальный комплекс "Рыленки". Композитору было всего 29 лет, когда оборвалась его жизнь, оборвалась его песня…

Так было найдено место последнего пристанища молодого, но уже известного композитора Татарстана.

В июле 1985 года жена и дочь Фарида Яруллина приезжали в далекую Беларусь, чтобы поклониться праху своего мужа и отца. В Рыленках, где захоронены его останки, они рассыпали пригоршню земли с родины композитора. И такую же пригоршню с мемориального комплекса «Рыленки» они привезли в Татарстан.

Имя великого татарского композитора Фарида Яруллина не забыто. В 1958 году ему за балет "Шурале" была присуждена Государственная премия Татарстана им. Г.Тукая. Известный художник и скульптор Баки Урманче создал скульптурный портрет композитора. В Казани именем Фарида Яруллина названа одна из городских улиц в Кировском районе, рядом с Молодежным центром "Ак Барс" возведен Монумент в честь Ф. З. Яруллина.

В Альметьевске музыкальный колледж носит имя Ф. З. Яруллина, в Национальном музее Республики Татарстан хранятся уникальные экспонаты, связанные с жизнью и творчеством замечательной семьи Ярулиных.

В 1969 году Ф. Ахметовым написана симфоническая «Поэма памяти Фарида Яруллина». Именем композиторов Ф. Яруллиных названа Мамадышская школа искусств. Открыты музеи Яруллиных в Мамадышской школе искусств и в деревне Малые Суни.

Помнят Фарида Яруллина и в Белоруссии. Там установлена мемориальная доска в честь павшего воина Фарида Яруллина. Как в Татарстане, так и в Белоруссии, проходят мероприятия, посвященные композитору, автору балета «Шурале» Ф. Яруллину, погибшему, обороняя Беларусию и похороненного на белорусской земле.

## Заключение

Трудно найти во всей мировой музыкальной культуре другого известного композитора с такой же короткой жизненной и творческой судьбой, как у Фарида Яруллина. Из 29 лет, прожитых Фаридом Яруллиным, на творчество было отпущено очень мало. Ему было всего 27 лет, когда прервалась его творческая работа, а в 29 он погиб. Однако исключительная природная одаренность его столь богата и столь плодотворен короткий творческий путь, что и сегодня он воспринимается как живой и творчески активный зрелый композитор.

Ф.Яруллин занял особое место в истории татарской музыкальной культуры, благодаря тому, что сумел выразить наиболее характерные черты своего народа, его нравственные идеалы. В историю музыкального искусства он вошел как автор первого татарского балета «Шурале» и стал известен народам нашей страны и других стран.

Уникальность, неповторимость, феномен… Эти слова можно с полным правом отнести и к Фариду Яруллину, чье творчество принесло татарской музыкальной культуре первое широкое мировое признание.

Жизнь и творчество талантливого композитора оказались короткими, но балет «Шурале» сделал имя Ф. Яруллина бессмертным. Это музыкально-сценическое произведение вошло в золотой фонд отечественной классики и положило начало становлению татарского хореографического искусства. Известные марши Ф. Яруллина исполняли духовые оркестры во время парадов на Красной площади в Москве, а его балет «Шурале» видели во многих странах мира.

## Использованная литература:


1. Композиторы Советского Татарстана. – Казань: Таткнигоиздат, 1957.
2. Алмазова А. А. Фарид Яруллин и татарский балет. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1987.
3. Низамиев Р. М. Фарид Яруллин: Роман – хроника. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1990.
4. Садрижиганов Д. В мире музыки. – Казань, 1990.- с. 88-91,
5. Юнусова Г. «Я по-новому спою…»: О некоторых страницах жизни и творчества Фарида Яруллина. // Казань. – 2004. - №4. – с.84-88
